Безнең МИРАС

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

10
октябрь 2020
ISSN:2500-011X

КЫЗЫКЛЫ ТАБЫШЛАР ● КАДЕРЛЕ ИСТӘЛЕКЛӘР ● ГЫЙБРӘТЛЕ ЯЗМЫШЛАР

Батулла музее

100 бит

Татар хатыны ниләр күрми: кыйналган Зөбәйдә «Эш»е

20 бит

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдемәнд

Безнең Мирас
12 +
10
(322)
октябрь 2020

Фәнни-популяр, әдәби-нәфис
һәм документаль журнал

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ (Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-92)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин (Фирдәвес Зариф)
(843) 222-09-83 (17-92)

Киңәшче идарә

Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Айрат Зарипов
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Айдар Сәлимгәрәев
(«Татмедиа» Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)

Редколлегия

Альберт Борһанов
Разил Вәлиев
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Хатыйп Миңнегулов
Ким Миңнуллин
Григорий Родионов (Гәрәй Рәхим)
Данил Салихов
Индус Таһиров
Ирек Шәрипов
Илдар Шәфыйков

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89196911406

Дизайнер һәм биткә салучы
Ләйлә Лерон
(843) 222-09-83 (17-93)

Мөхәррир
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-91)

Сайт мөхәррире һәм корректор
Энже Хөсәенова
(843) 222-09-83 (17-92)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта: **yanamiras@mail.ru**
Сайт: **beznenmiras.ru**

«Безнең мирас» (Наше наследие)
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском и русском языках)

Эчтәлек

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 Гаяз Исхакый

ТАРИХИ МИРАС

4 «Зөләйха» һәм миссионер Малов. *Л.Гайнанова*
10 Солтангалиев кем ул? *И.Таһиров*
20 Татар хатыны ниләр күрми: кыйналган Зөбәйдә «Эш»е. *Г.Хисамиев*
24 Туймазы Шәкүре. *Ә.Сафуанов*
29 Төмәнәкне кемнәр нигезләгән? *И.Шиһапов*
34 «Чулпан» газетасы. *Л.Гобәйдуллин, Р.Шәрәфиева*
38 Борһанеддин Мәрҗанинең кабер ташы. *А.Гайнетдинов*

ТАТАР ГАМЕ

40 Фәнир Галимов: «Авыллар, һичшиксез, яшәячәк!»
46 Илкәем бар – дөньям түгәрәк!

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны һәм фотоларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм «Татар-информ»нан, Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, җиде томлык «Татар тарихы»ннан алынган фотосурәтләр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

ДИНИ МИРАС

50 Ислам дөньясы. *Габдерәшит Ибраһимов*

ӘДӘБИ МИРАС

56 Фин илендә Кәрәкәшле кызы. *Х.Миңнегулов*
60 Гәүһәр Туганай шигырьләре
62 Шайтанлы чишмәсе буенда. *Г.Кашшаф*
69 «Күңелгә җылы хис тулып тамды». *Г.Тажетдинова*

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН...

74 Мөдәррис Әгъләм вафаты. *Л.Лерон*

ТУГАНДАШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЫ

80 Таш батыр турында риваять. *А.Сарманбәтов*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

90 Кара тәкъдир. *Р.Батулла*
96 Зөлфәт. *Р.Туфитуллова*
100 Батулла музее. *Л.Лерон*
102 Халык иҗаты хәзинәләре
104 Истә, һаман да истә!

СӘНГАТИ МИРАС

106 Борынгы татар милли музыка уен кораллары. *Р.Гыйләҗев*
110 Татар дәүләт филармониясе 100 еллык ТАССР тарихында. *З.Гыйльметдинова*

ФИКЕР ДӘРЬЯСЫ

112 Милләт. *Р.Садриев*

ШАЯН МИРАС

114 Көлке куа килә...

116 «Безнең мирас» хәбәрләре
118 Мирасворд
119 «Безнең мирас» елъязмасы. *Октябрь*

Заказ №А-2512. Тираж – 2167 данә. Формат 70x100 1/16
Басарга кул куелды: 28.09.2020. Чыгу көне: 01.10.2020.
Айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

«Татмедиа» Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән әзерләнде.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Тышлыкның беренче битендә: Гази Кашшаф энесе Фәтхелбаян һәм картинәсе (әбисе) Хәдичә белән.

Әүвәл әхлак бозыла, икенче дин бетә,
өченчедән, ул халык үзе бетә.

Гаяз Исхакый

Гаяз Исхакый кызы Сәгадәт белән. Истанбул, 1926

Гаяз Исхакый

(23.02.1878-22.07.1954)



***

Уйна да көл, исәплә дә бел.

***

Сабак укыган – сума җыйган, дөнья көткән – дан җуйган.

***

Ярлылык иман китерә, азгынлык иман бетерә.

***

Болгар музыкасы Яурупа музыкасыннан бөтенләй башка, Яурупа музыкасы калебнең бер ягыннан чыкса, болгар музыкасы икенче ягыннан чыга, Яурупа музыкасы күңелгә бер яктан рәхәт бирсә, болгар музыкасы икенче яктан рәхәт бирә. «Болар кайсы гали?» – дигән сүзгә мин җавап бирә алмыйм, минемчә, болар икесе дә гали, икесе бер-берсеннән башка ярты гына, икесе дә бер-берсен камилли.

***

Музыкага, көйгә чынлап карарга, аның милли тормышыбыздагы урынын, җирен тәгаен әйтер вакыт җитте.

***

Әдәби тел мәсьәләсе бетә башлагач, инде язу турында бәхәсләшү башланды. Кемдер, ничек ишетелә, шулай язылсын, иске язу кагыйдәләренә буйсынмыйк, ди, кемдер, иске әдәбияттан килгән байлык югалмасын, ул вакытта әдәбиятыбыз бернигә дә ярамаячак, шуның өчен иске язуга якынлашырга кирәк, ди.

***

Һәр милләтнең яртысы – хатыннар, һәр милләтнең рухын саклаучылар – хатыннар, һәммә милләтнең теленең, хосусый тәләффызларын (әйтелешен), шивәсен саклаучылар – хатыннар, киләчәктәге ата булачак ирләрне, ана булачак кызларны тәрбия кылучылар хатыннар идеке һәркемгә мәгълүм.

*Текстны журналга **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

«Зөләйха» һәм миссионер Малов

Лена Гайнанова



Г.Исхакый «Зөләйха». – Мәскәү: «Шәрык» матбагасы. 1918 ел

Гаяз Исхакыйның «Зөләйха» драмасы Мәскәүдә әдипнең үз наширлегендә «Шәрык» матбагасында 1918 елда аерым китап булып басылып чыккан. Титул битендә: *«Беренче мәртәбә языла башлады 1907 нче елда Чистай төрмәсендә, икенче мәртәбә Истанбулда Кандилледә 1911 нче елда. Язылып бетте Петроградта 1912 нче елда гыйнвар башында»,* – дип язылган. *«Вакыйга алтмышынчы елларда»,* – дип өстәп куелган.

Исхакый: «Оригиналын кызларга бирүемнән мәмнун идем»

XIX гасырның икенче яртысында милли һәм дини басымның көчәюе аркасында чукындырылган татарларның күпләп кире мөселманлыкка чыгулары күзәтелә. Мондый мөселманнарны «мәкруһлар» яисә «отпавшие» дип йөртәләр. Үзләрен христиан диненә хыянәт итүчеләр дип санап, аларны аеруча зур газапларга дучар итәләр: монастырьларга ябып тотып, каравыл астында тәүбә иттерәләр, христиан йолаларын үтәтәләр, балаларын, тартып алып, чиркәү мәктәпләренә бирәләр. Кәләй (хәзерге Яуширмә авылы) халкының да бер өлеше чукындырыла һәм соңыннан керәшеннәр кире мөселманлыкка кайталар. Авылдан ерак түгел иске керәшен зираты да бар. Г.Исхакый үз авылы, төбәге тарихын бик яхшы белгән һәм пьесасына алынган вакыйгалар аңа таныш булган, әлбәттә.

Күренгәнчә, үзенең бу әсәрен автор 6-7 ел дәвамында кайта-кайта язган һәм аны җаны кебек саклаган. Сөргеннән качып киткәч, Г.Исхакый Төркиядә – ике мәртәбә, Петербургта өч мәртәбә яшәп ала. Шул өченче килүендә ул пьесаны дус-ишләренә укый. *«Темасы белән бу әсәремне бик мөһим бер әсәр дип санаганга, тикшерүгә куярга теләдем»,* – ди. Г.Исхакый «Зөләйха» пьесасын укырга дип килешенгән урыннар турында болай дип яза: *«Беренче мәҗлес генерал Шәех Галинең хатыны*

Финляндиянең Тампере шәһәре үзешчәннәре «Зөләйха»ны сәхнәләштергәч. 1937 ел

*Гөлсем ханымның өендә булачак, икенчесе Заһид Шамил өендә булачак... «Зөләйха»ны уку мәҗлесенә мин үзем белән бергә Балкан сугышы вакытында Төркиягә шәфкать туташы буларак килгән университет студентларыннан Гөлсем (Г.Исхакыйның якташы, Чистай кызы Өммегөлсем Камалова. **– Л.Г.**) һәм Мәрьям (Якупова) исемле кызларны китердем».* Яшьләр җыелган җирдә бик саклык белән генә пьесаны беренче тапкыр ничек укуы, тыңлаучыларда ул нинди тәэсирләр калдыруы турында Г.Исхакый «Бер тоткарның саташуы» исемле повестенда бик җентекләп сөйли. Менә тоталар, менә кулга алалар дип куркып яшәгән әдип, мәҗлес тәмамланганнан соң, «Зөләйха»ны, икенче урында булачак мәҗлескә алып килерсез, дип, таныш кызларына биреп җибәрә. Шулай итеп «Зөләйха»ны эзсез югалудан коткарып кала. Чөнки әдип икенче көнне үк кулга алына. Димәк, Заһид Шамил өендә җыелып драманы икенче тапкыр уку бөтенләй булмый кала. «Тәрҗемәи хәлем»ендә Г.Исхакый, полиция кулына эләккәч: *«Кичә «Зөләйха»ның оригиналын кызларга бирүемнән мәмнун (шат) идем»,* – ди.

> **«Зөләйха» – шул чорда татар әдәбиятында татарларны көчләп чукындыру турында язылган бердәнбер әсәр.**

«Зөләйха» – шул чорда татар әдәбиятында татарларны көчләп чукындыру турында язылган бердәнбер әсәр. 1914 елда аның «Ил» матбагасында басыла башлавы хәбәр ителә. Димәк, әсәрне Петербургта бастыру ният ителгән булган. Ләкин китап басылмый кала («Ил», 2014, 21 август). Февраль революциясеннән соң, цензура бетерелгәч кенә, «Сәйяр» труппасы спектакльне беренче тапкыр Казанда Зур театрда 1917 елның 17 мартында Габдулла Кариевның бенефисы уңае белән куя. Спектакльгә музыканы Солтан Габәши язган. «Зөләйха» Казанда атнасына 3 мәртәбә уйнала. Ул Бөтенрусия мөселманнарының Мәскәүдә уздырылган Беренче корылтае (1-14 май) делегатларына күрсәтелә. Г.Исхакый үзе дә спектакльне «Сәйяр» уйнавында Мәскәүдә дә, Казанга да кайтып карый. Зал тулы халык Г.Исхакыйны алкышларга күмә.

Малов: «Тагын көтәргә кирәкмидер ич инде...»

Бу урында бераз чигенеш ясап, миссионер Евфимий Малов көндәлекләрендәге кайбер фикерләрне китереп үтик: *«...Әмма һәр очракта да безнең максат – татарларга христиан динен кертү белән бергә, мөселманнарны урыс тормышы гореф-гадәтләренә, урыс теленә, урыс киеменә күнектерү-өйрәтү дә»* (1893, 13 февраль). Миссионерларның татардан урыс ясау хыялы әлегә зурдан. Әмма 20 нче йөз башында инде Малов бу хыялны гамәлгә ашыруга акрын барабыз дип борчыла: *«Без, урыслар, татарлар өстеннән идарә итүче класс буларак, дистәләгән, йөзләгән еллар яшибез. Казанны яулап алганга өч йөз елдан артык вакыт үтсә дә, күпмесен генә урыслаштыра алдык икән? Өч-дүрт йөз ел тагын көтәргә кирәкмидер ич инде...»; «Протоиерей Ал.См.Миропольский атакай һәм Я.Д.Коблов бик тә авыр хәбәр ишеткәннәр: имеш, 1903 елның язына Мамадыш өязендәге барлык керәшеннәр дә мөселман диненә кайтачак. Алла сакласын!»* Малов бу сүзләрне 1903-1904 нче елларда язган.

Ә 1917 елның 23 ноябрендә инде ул болай ди: *«Кояш» гәзитәсенең бүгенге санында иртәгә Зур театрда (Зур Проломный урамында) «Зөләйха» драмасы куелачагы хакында игълан бар. Бу драма хакында миңа кабат улым Сергей Малов хәбәр итте (гәзитәне ул алып килгән иде). Мөселманнарның драмасы куелачагын белеп алгач, бу хакта миссионерлар курсына хәбәр иттем һәм курсист, чукынган татар Анисим Макаровка бу тамашага һичшиксез барырга куштым. Акчам юк, бара алмыйм, дип әйткәч, акча бирдем. Тагын бер курсистны, татар телен яхшы белгән чукынган чуашны да тамашага барырга кодаладым. Тамашаны бик дикъкать белән карарга, күргәннәрен, ишеткәннәрен өлгерә алган кадәр язып барырга куштым. Әлеге драма керәшен татарлары тормышыннан бит, безгә, миссионерларга, татар мөселманнарының керәшеннәрне ничек күз алларына китерүләре белән, һичшиксез, танышырга кирәк».*

Уртада – «рәхмәт фәрештәсе», ягъни Зөләйха образын башкаручы Разыя Хәйретдин. Тампере, 1937 ел

Инде февраль революциясе булган, цензура бетерелгән. Миссионерларга шул татарлардагы күтәрелешне күзәтеп торырга гына кала... (Көндәлектән өзекләр «Идел» журналының 1993 елгы 8 нче, 1994 елгы 9 нчы, 1996 елгы 1 нче саннарыннан алынды.)

Сальмушев: «Тәрәзәләрнең шыртлап ватылулары ишетелә»

Спектакль куелу уңае белән матбугатта басылган рецензияләрдән, шулай ук беренче спектакльне үз күзләре белән күргән кешеләрнең сөйләүләреннән аңлашылганча, «Зөләйха» фаҗигасе тамашачыларга көтмәгәндә шартлап күк күкрәп, ярылып яшен яшьнәгән кебек тәэсир итә. Хәзерге Качалов исемендәге театр залы елау-иңрәүләр белән тула, сәхнәдә барган коточкыч көчләү күренешләреннән кайберәүләр аңын җуеп егыла.

1993 елның 10 февралендә 95 яшьлек укытучы-пенсионер Хаҗи Сальмушев безгә болай дип сөйләгән иде: *«Залда утыру түгел, басып торырга да урын юк иде. Кешеләр сәхнәгә терәлеп үк тыгызланган, тәрәзә төпләренә менеп баскан. Бераздан тәрәзәләрнең берәм-берәм шыртлап ватылулары ишетелә иде. Әмма тамашачыларның дикъкатен башка берни били алмый: сәхнәдә коточкыч фаҗига, көчләп чукындыру. Бөтен кеше олы фаҗигане үзенең йөрәгеннән кичерә иде».*

Ф.Әмирхан пьесага бәя биреп болай дип яза: *«Зөләйха», иске хөкүмәткә каршы гаять куәтле бер обвинительный акт булуы белән бергә, милләтемезнең үз кодсияте (изгелеге) юлында һичбертөрле фидаилектән кире тормас дәрәҗәдә куәтле рухка ия шәхесләре барлыгын күрсәтә вә бөтенлегемезне саклауда исламның нинди шәрәфле бер роль уйнаганлыгын исбат итә торган бер дәлилдер»* («Кояш», 1917, 19 март).

Рецензентларның берсе Шәһид Әхмәдиев: *«Бу әсәрне сәхнәдә күрерлек хөррият дөньясына ирештек микәнни дигән сүз һәрбер кешенең күңеленә килерлектер»,* – ди («Йолдыз», 1917, 22 март).

Г.Исхакый «Зөләйха»ны уйнау хокукын өч елга «Сәйяр» труппасы җитәкчесе Габдулла Кариевка тапшыра. Кариев «Зөләйха»ны куяр өчен 1918 елның җәендә Идел буе, Кавказ һәм Төркестанга гастрольләргә чыгарга планлаштыра. («Ил», 1917, 28 май). Ләкин, дөньялар үзгәреп китеп, ул бу зур планын тормышка ашыра алмый. Шулай да Октябрь революциясеннән соң «Сәйяр» труппасы «Зөләйха»ны 1917 елның 19 ноябрендә сәхнәгә куеп кала. Спектакль З.Солтанов режиссерлыгында Әстерхан театрында уйнала.

Мөхсинов: «Татар буржуазиясе акылдан шаша»

Илдә совет хакимияте урнашкач, Г.Исхакыйга караш үзгәрә. «Зөләйха», русларга каршы юнәлдерелгән, ислам динен пропагандалаган пьеса, дип, репертуардан төшерелә һәм татар әдәбиятында иң реакцион әсәр итеп карала башлый.

Матбугатта «Зөләйха»ның тыелу вакытын күрсәткән кызыклы мәгълүмат бар. «Татарстан хәбәрләре» газетасының 1922 елгы 20 нче март санында мондый белдерү укыйбыз: *«Җомга көн, 24 мартта, Казандагы бөтен татар артист, җырчы, музыкант, әдип, шагыйрьләре, бөтен сәхнә һәвәскәрләре, педагогия техникумы, партия мәктәбе, хәрби-сәяси курслар, команда курслары каршындагы*

Г.Исхакый «Зөләйха» спектаклендә уйнаучылар белән. Токио, 1934 ел

сәхнә көчләре катнашы белән шәһәрдә салына торган татар театры файдасына тантаналы кичә ясалачак. Программада: 1. «Зөләйха». Г.Исхакый. «Туй» пәрдәсе; 2. «Таһир-Зөһрә». Ф.Борнаш. «Гөлләр бакчасы» пәрдәсе; 3. Концерт».

Гәзитә чыккан көнне үк «хата»ны күреп алалар һәм 21 нче март санында бирелгән шул ук игъланда «Зөләйха»ны программадан төшереп калдыралар, аның урынына Г.Рәхимнең «Бүз егет»ен куялар.

1930 елда Казанда басылып чыккан «Татар дәүләт академия театры» исемле китабында Зәки Мөхсинов «Зөләйха»ны Г.Исхакыйның иң кабахәт әсәрләреннән дип атый. *«Казанда ул әсәр аерым югарыдан кушу буенча көн-төн уйнала, иртән дә «Зөләйха», кич тә «Зөләйха», «Зөләйха» белән татар буржуазиясе акылдан шаша»,* – ди.

Шулай итеп, «Зөләйха» сәхнәдән төшсә дә, аны русларга, хәтта коммунистларга каршы котыртып язылган әсәр дип бәяләү узган гасырның 90 нчы елларынача дәвам итте.

«Зөләйха» чит илләрдә

«Зөләйха» драмасы, төрекчәгә тәрҗемә ителеп, Төркиядә «Төрек йорты» журналында 1926 елда басыла. Г.Исхакый 1951 елда үз кулы белән төзегән төрекчә исемлектә «Зөләйха»ның рус һәм поляк телләренә дә тәрҗемә ителүе күрсәтелә. Ләкин тәрҗемәләрнең кульязмалары турында да, басылып чыгулары хакында да әлегә мәгълүматлар юк.

Чит илләрдә «Зөләйха» эмигрант татарлар оештырган үзешчән драма коллективлары тарафыннан, мәсәлән, Кытайда – Харбин (1921), Японииядә – Токио (1933), Финляндиядә Тампере (1937) шәһәрләрендә уйнала. Харбинда куелган спектакльнең игъланы да сакланган:

«Иртәгә гаиде шәрифнең икенче көнендә (17 июнь, 1921 ел) Харбин Мөселман төрек-татар яшьләре түгәрәге тарафыннан мәшһүр мөхәррирләремездән Гаяз әфәнде Исхакыйның бик зур муаффәкыять берлән язылган 5 пәрдәлек драмасы – «Зөләйха» куелачак.

Русия дәүләте кул астында ясалган тарихымызның иң фаҗигале сәхифәләрен тасвир итүче бу әсәрне карау һәркемгә тиешле. Кичәдән килгән файда бу көндә Парижда эчке Русия вә Себер мөселман төрек-татарларының вәкиле сыйфаты берлән эшләп яткан Гаяз әфәнде Исхакыйга йибәреләчәктер. Кичә башланыр нәкъ сәгать сигездә. Күрергә ашыгыгыз! Бу мәүсимдә (сезонда) өченче мәртәбә сәхнәдә уйнала».

Токиода яшьләр «Зөләйха»ны, Г.Исхакыйның килүе уңае белән, 1933 елның сентябрь аенда куялар.

> **«Гади бер хатын-кыз язмышы аша бөтен бер халыкның фаҗигасен тасвирлаган киң масштаблы «Зөләйха» әсәре шактый озын: 5 пәрдәдән тора. Безнең театрлар аның 3 пәрдәсен генә сәхнәләштергән. Әмма революциягә кадәр һәм чит илләрдә дә пьеса тулысынча куелган, тамашачы спектакльне төн буе карап утырган.**

«Зөләйха» тулысынча кайчан сәхнәгә куелыр?

Узган гасыр ахырында матбугатта Г.Исхакый турында бәхәсләр башлангач та, Казандагы татар театрларының икесендә дә аның әсәрләре белән кызыксыну уянган. Хәзерге язуга күчерелгән ун пьесаны бездән соратып та алганнар иде. Әмма «Зөләйха»ны сәхнәгә куярга театр коллективлары базмый торды. Димәк, бу әсәрне сәхнәдә күрерлек «хөррият дөньясы»на ирешмәгән идек әле.

Ниһаять, 1991 елда Г.Исхакыйның без төзегән әсәрләр җыентыгы «Зиндан» басылып чыкты. Ул җыентыкта «Зөләйха» драмасы да бар иде. Һәм, беренче тапкыр куелуына 75 ел вакыт узгач, 1992 елда татар тамашачысына «Зөләйха»ны сәхнәдә Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Празат Исәнбәт режиссерлыгында яңадан күрү насыйп булды. Бу факт шулкадәр мөһимдер ки, хәзерге «Зөләйха» спектакле, февраль революциясеннән соң куелган «Зөләйха» кебек үк, татар халкының үзен һичкемнән кимсеттерми, горур булып, үз кадерен үзе белеп яшәргә омтылышы дәрәҗәсен дә, шулай ук киләчәктә чын мөстәкыйльлеккә, бәйсезлеккә ышаныч дәрәҗәсен дә билгеләүче бер барометр булып тора, дияргә мөмкин.

«Зөләйха» драмасын Башкортстандагы «Нур» Татар дәүләт театры да сәхнәләштерде (1994, режиссеры – Байрас Ибраһимов). 2004 елда драма буенча нәфис фильм да төшерелде (сценарий авторлары – Юныс Сафиуллин һәм Рамил Төхфәтуллин, режиссеры – Р.Төхфәтуллин).

Гади бер хатын-кыз язмышы аша бөтен бер халыкның фаҗигасен тасвирлаган киң масштаблы «Зөләйха» әсәре шактый озын: 5 пәрдәдән тора. Безнең театрлар аның 3 пәрдәсен генә сәхнәләштергән. Әмма революциягә кадәр һәм чит илләрдә дә пьеса тулысынча куелган, тамашачы спектакльне төн буе карап утырган. Пьесадагы 4 нче пәрдә исә әсәрнең резюмесе, йомгагы булып тора. Үләр алдыннан Зөләйханың күзенә күренгән фәрештәләр, аларның бу бөек рухлы мөселман хатынының аякларындагы богауланып йөрүдән барлыкка килгән яраларын юулары, Зөләйханы изгеләрдән санаулары – гаделлек, тугрылык, ихласлылык тантана итәчәгенә ышаныч белдерүче бер символик күренеш булып тора. «Зөләйха» драмасын тулысынча сәхнәләштерү һәм укып чыгу Г.Исхакыйның бу әсәргә салган идеясен тирәнрәк аңларга ярдәм итәчәк. ■

Солтангалиев кем ул?

Индус Таһиров, тарих фәннәре докторы, академик

Мирсәет Солтангалиев (уртада утыра) Шәрык халыклары коммунистик оешмаларының икенче Бөтенроссия корылтаенда. Мәскәү, 1919 елның 15 декабре

М.Солтангалиев хатыны Фатыйма Ерзин белән. 1919 ел

Мирсәет Солтангалиев исеме күп еллар буе буржуаз милләтчелек символы булып торды. Ни кызганыч, хәзергәчә аның исемен ниндидер аңлашылмастай күләгә каплап килә. Аңа һәйкәл дә, исемен йөрткән мәйдан да, урам да юк.

Ә бит Солтангалиев – Ленин үзе исән чагында ук марксизм-ленинизмның үзәген тәшкил иткән пролетариат диктатурасы тәгълиматының да ялгыш икәнлеген исбатлаган шәхес.

Ул, Ленин һәм ленинчылардан аермалы буларак, дөньякүләм революциянең булмаячагын, аның урынына, куәтле фактор рәвешендә, колониаль Шәрыкның уяначагын фаразлаган, 1919 елда ук «Жизнь национальностей» журналында коммунистларның Көнбатышка йөз тотуларын өметсез гамәл дип бәяләгән[1].

Ул шулай ук Ленинның колониаль һәм ярым колониаль илләрнең, капитализм фазасын үтмәстән, турыдан-туры социализмга керәчәкләр дигән фаразының да дөрес түгеллеген исбатлый алган. Юлбашчының «Имперализм как высшая стадия капитализма» исемле әсәрен пыр туздырып, империализмның капитализмның кайбер стадияләренә генә түгел, ә барлык стадияләренә дә, хәтта социализмга да хас сыйфат икәнлеген күрсәтеп язган.

Солтангалиев гениаль рәвештә Шәрык илләренең социализмга түгел, ә милли азатлык революциясенә йөз тотачакларын, шуның нәтиҗәсендә өченче дөнья барлыкка киләчәген дә фаразлаган.

[1] Мирсаид Султангалиев. Избранные труды. – сс. 200-201.

Аның тәгълиматына Сен-Катаяма, Мао Цзедун, Лю Шао Ци, Хо Ши Мин кебек шәхесләр дә битараф булмаганнар. Аларны шушы тәгълиматны гамәлгә ашыручылар дип атасак, һич кенә дә ялгышмабыз.

«

Солтангаливнең портретлары юкка гына Мисыр Президенты Гамаль Габдел Насернең, Алжир революциясе лидеры Әхмәт Бен Белланың кабинетларын бизәмәгәндер.

Солтангаливнең портретлары юкка гына Мисыр Президенты Гамаль Габдел Насернең, Алжир революциясе лидеры Әхмәт Бен Белланың кабинетларын бизәмәгәндер. Моның сәбәбе – шушы бөек шәхесләрнең Солтангалиевне үзләренә юл күрсәтүче итеп санауларында. Солтангалиевнең 100 еллык юбилее көннәрендә Әхмәт Бен Белланың, аның хезмәтенә зур бәя һәм рәхмәтләр белдереп, Казанга телеграмма җибәрүе шул хакта сөйли.

Солтангалиевнең марксизм-ленинизм тәгълиматын шик астына куйган беренче шәхес икәнлеге Баруна Деның 1999 елда ЮНЕСКО оештырган зур конференциясендә дә ачык әйтелде[2]. Япон тарихчысы Ямамучи, инглизле М.Родинсон, француз галимәсе Александра Беннигсен үзләренең шушы бөек шәхескә багышланган хезмәтләрендә Солтангалиевнең көрәзәчелегенә зур бәя бирәләр һәм аның өченче дөньяның идеологы икәнлеген документаль рәвештә раслыйлар.

Ерак татар авылыннан чыккан шушы кешенең дөньякүләм биеклеккә күтәрелүен могҗиза дип карарга да ярый. Ләкин бу феноменны XIX белән XX гасырлар чигендә өч йөз елдан артык коллыкта яшәгән татарның, өстеннән кабер туфрагын кагып төшереп, горур рәвештә тарих мәйданына чыгуының җимеше дип билгеләсәк, бик дөрес булыр. Күренекле башкорт тарихчысы Билал Юлдашбаев язганча, татарның мисали рәвештәге ислам милләтенә әверелүе, әдәбият мәйданына Тукай, Дәрдемәнд, Мәҗит Гафури, Сәгыйть Сүнчәләй, Гаяз Исхакый, Галимҗан Ибраһимов, Шәриф Камал, Галиәсгар Камал кебек бөек язучыларыбыз чыккан, дистәләгән газет-журнал, миллионлаган тираж белән китаплар чыгарыла башлаган, татарның театры, музыкаль сәнгате барлыкка килгән гүзәл үзгәрешләр чоры бу.

Солтангалиев феномены – әнә шул гүзәл алгарышның бер җимеше, татар акылының дөньякүләм тантана итүенең якты күренеше.

Әйе, шәхесләрне чор үзе тудыра, тарих мәйданына да үзе чыгара. Бу – Россияне революция чорнап алган, халыкларының йокыдан уянган еллары. *«Уяндык без бишенче елның бер таңында»*, – дип язган Тукаебыз. Солтангалиевне дә, бик күп зыялыларыбыз кебек үк, шушы революциянең якты таңы уята, аны милли азатлык көрәше мәйданына чакыра.

Бер яктан караганда, Солтангалиев феномены очраклы хәл генә булып күренергә мөмкин. Ләкин андый очраклылык әзерлекле кешеләргә генә насыйп була. Моны һич кенә дә онытырга ярамый.

Солтангалиевкә табигать зирәк акыл биргән. Искиткеч милли җанлы атасы – халык укытучысы Хәйдәргали ага, аңа милли рух сеңдереп, акылын камилләштерүгә юл ачкан, китап сөяргә, бертуктаусыз белемен арттырырга өйрәткән. Мирсәетнең өйләрендәге бай китапханәдә дә, Бәләбәй земствосы китапханәсендә дә укымаган китабы калмаган. Ул Көнчыгыш һәм Көнбатыш авторларының, рус классикларының

[2] Всемирный доклад по социальным наукам. – Издательство ЮНЕСКО, Издательский дом МАГИСТР-ПРЕСС, 2002. – с. 53.

әсәрләре белән шул вакытта ук таныша башлый. Үз халкының тарихы белән ныклап кызыксына, аны коллыктан ирекккә чыгару хыялы белән яши.

Мирсәет Казан укытучылар мәктәбендә (Казанская учительская школа) укый башлагач, җирле социалистлар белән танышып, тыелган әдәбиятны өйрәнергә керешә.

Ул чорда күп яшьләр социализм идеясе белән мавыгалар. Ләкин Мирсәет өчен бу ниндидер мавыгу гына булмый. Ул шушы тәгълиматтан капитализм тарафыннан сытылган дөньяны коткару ачкычын эзли. Һәм акрынлап изелгән дөньяның көнбатыш пролетариаты, бигрәк тә колониаль Шәрык һәм андагы мөселман халыклары икәнлегенә төшенә башлый. Әлбәттә, аның өчен беренче нәүбәттә үз кавеме – татар халкы була.

Ул, социализмның азатлык идеяләренә таянып, акрынлап дөньяга үз карашын тудыра. Большевикларның калкып чыгуы аңарда коллыкта яшәгән халыкларга ирек бирү өметен уята. Һәм шушы өмет аны алар сафына китерә.

Бу яктан караганда, аны, мөгаен, большевикларның вакытлы юлдашы гына итеп карарга кирәктер. Социализмның төрле агымнарында катнашкан татар революционерларының күбесе милли идеяне социализм һәм коммунизм идеясенә буйсындырып эш иткәннәр. Алар социализмның халыкларга азатлык китерүенә инаналар. Күбесенең күңелләрендә социализм һәм милләтчелек идеяләре янәшә урнашкан була. Күренекле тарихчы Һади Атласи андыйларны ярым социалист, ярым милләтчеләр дип атаган.

Солтангалиев, бик күп милли каһарманнар кебек үк, революция дулкынына чума. 1917 елда Казанда, Мулланур Вахитовның якын көрәштәше буларак, Мөселман социалистлары комитетын төзүдә катнаша. Бу комитетта эсерлар да, большевиклар да кулга-кул тотынышып эшлиләр. Монда эсер Фуат Туктаров та, большевик Камил Якубов та һәм башка бик күп милли азатлык каһарманнары бергә булалар. Комитетның Мулланур Вахитов нәшер иткән «Кызыл Байрак» газетасы, Фуат Туктаровның «Корылтай»ы, Уфадагы большевистик «Алга», Галимҗан Ибраһимовның «Ирек» газеталары милли азатлык проблемасын беренче урынга куялар.

Дөрес, бу социалистлар арасында аермалыклар да була. Әйтик, үзен кызыл панисламист дип санаган Мулланур Вахитов сыйнфыйлыкка артыграк игътибар биргән булса, Фуат Туктаров һәм башка татар эсерлары халыкның барлык катламнарын да милли бердәмлеккә өндиләр. Тик аларның барысына, социализмга караганда, үз кавемнәре газизрәк булган.

1918 елда Мулланур Вахитовның фаҗигале үлеменнән соң, моңарчы аңа йөкләнгән Үзәк мөселман комиссариатына, Үзәк мөселман хәрби коллегиясенә Мирсәет Солтангалиев җитәкчелек итә башлый.

> **«Солтангалиев, бик күп милли каһарманнар кебек үк, революция дулкынына чума. 1917 елда Казанда, Мулланур Вахитовның якын көрәштәше буларак, Мөселман социалистлары комитетын төзүдә катнаша.**

Әгәр дә без шушы урында Солтангалиевнең хаталары турында бер сүз дә әйтмәсәк, дөреслеккә хилафлык булыр иде. Аларның иң зурысы 1918 елның февраленә туры килә. Һәм аның сәбәбе большевикларга кергәннән артык ышану була.

Мәгълүм ки, 1918 елның гыйнварында Уфада җыелган Милли мәҗлес Идел-Урал штатын төзү карарын

кабул итә. Аны тормышка ашыру өчен, махсус коллегия төзелә һәм ул Казанга килә. Штатны Казанда җыелган Бөтенроссия хәрби шурасының рәисе Ильяс Алкин җитәкчелегендәге Мөселман хәрбиләренең II съезды игълан итәргә тиеш була. Моны 28 февральгә билгелиләр.

Ләкин съездның большевиклар фракциясе, аның иң йогынтылы әгъзаларыннан булган Мирсәет Солтангалиев, Шамил Усманов һәм Сәхибгәрәй Сәетгалиев моңа каршы төшәләр. Һәм төнлә Хәсән Урманов җитәкчелегендәге кораллы гаскәриләр хәрби съездның җитәкчелеген, шул исәптән Ильяс Алкинны да кулга алалар. Шуның аркасында Штат гамәлгә ашырылмыйча кала. Ә бит Казанда ул көннәрдә татарларга каршы торырдай бернинди көч тә булмый. Әкрәм Биглов җитәкчелегендәге татар һәм башкортлардан торган 95 нче полк солдатлары аны сакларга һәм якларга атлыгып торган булалар. Ни кызганыч, бу мөмкинлек файдаланылмый кала. Идел-Урал штаты барлыкка килгән булса, бәлки, бүгенге вазгыятъ тә бөтенләй башка төс алган булыр иде.

Солтангалиев һәм Усманов соңыннан моңа бик нык үкенәләр. Ләкин, күпме теләсәң дә, терсәкне тешләп булмый шул – инде соң була.

Күпмедер дәрәҗәдә хаталарын төзәтү максатыннан, алар Гражданнар сугышы елларында Кызыл Армия составындагы татар частьләрен төзү эшләрен җәелдереп җибәрәләр. Нәтиҗәдә, Мөселман хәрби курслары, ике татар бригадасы барлыкка килә.

Мирсәет Солтангалиев шушы вакытта татар-башкорт мөнәсәбәтләрен җайга салуга да зур өлеш кертә. Ул ике халыкны да якын күрә һәм киләчәктә аларның бердәм республикалары булачагына инана. М.Солтангалиев 1917 елның декабрендә игълан ителгән Башкорт Республикасын Совет хөкүмәте тарафыннан танытуга үз өлешен кертә. Ул, башкортлар белән якын мөнәсәбәттә булганлыктан, арадашлык вазыйфасын башкара. Нәтиҗәдә, моңарчы Колчак ягындагы башкорт гаскәре кызылларның Солтангалиев реввоенсоветы әгъзасы булган 2 нче армиясенә килеп кушыла. 1919 елның 20 мартында Совет һәм башкорт хөкүмәтләре тарафыннан килешү төзелеп, Башкортстан Республикасы танылa.

Бу вакытта махсус темаларның берсе Татар-Башкорт Республикасы була. Аны төзү турындагы карарны Совет хөкүмәте махсус рәвештә Идел-Урал проектын кире кагу максатыннан кабул итә. Баштарак моңа Зәки Вәлиди каршы килә. Татарстан Республикасын төзү мәсьәләсе калкып чыккач, башкортлар «Зур Башкортстан» проблемасын күтәрәләр. Ләкин моның барып чыкмаячагын аңлагач һәм Башкортстанны Татарстаннан Уфа губернасы бүлеп торачагы ачыклангач, Вәлиди Татар-Башкорт Республикасына ризалык бирә. Ләкин инде соң була. РКП(б) Үзәк комитеты, Н.Крестинский тәкъдиме нигезендә, Татар-Башкорт Республикасы өчен агитация алып баруны тыя. Аңлашу һәм бердәмлек иртәрәк барлыкка килгән булса, Үзәк комитет, бәлки, бу теманы җиңел генә яба алмаган булыр иде.

Солтангалиев, Милләтләр эшләре Халык Комиссариатының җаваплы хезмәткәре рәвешендә һәм Төньяк Кавказ Республикаларын оештыру комиссиясенең рәисе буларак, тау халыкларының дәүләтчелекләрен булдыру эшенә зур өлеш кертә, аларга күбрәк хокук бирү өчен зур тырышлык куя.

Аның СССРны төзү елларындагы эшчәнлегенә әлегәчә тиешле бәя бирелгәне юк. Ә бит ул – бу илнең иректле һәм тигез хокуклы халыклар берлеге рәвешендә формалашуын алга сөрүчеләрнең беренчесе, аларның юлбашчысы.

СССР төзүне хәл иткән РСФСР Советларының X съездында кискен бәрелешләр була. Аның милли секциясендә, Солтангалиев башлангычы белән, яңа дәүләтнең тигез хокуклы республикалар Союзы булуын таләп иткән мөрәҗәгать кабул ителә.

Республика вәкилләренең имзаларын Шамил Усманов җыя. Съездның милли фракциясендә татарлардан – М.Солтангалиев һәм К.Мохтаров, башкортлардан – М.Халиков, казакълардан – Мендишев, үзбәкләрдән Хидыргалиев чыгыш ясый. Алар СССРга барлык республикаларның да, тигез хокуклы рәвештә, яңа дәүләтнең оештыручылары буларак керүләрен таләп итәләр.

Солтангалиев республикаларның СССРга РСФСР составында керүләрен кирәксез гамәл, аларга карата үги балаларга булган караш дип бәяли.

Хәер, ул инде 1919 елның апрелендә булып үткән РКП(б) ның VIII съезды делегатларының милли үзбилгеләнү хокукына карата мөнәсәбәтләрен белдергән сүзләрен үз колаклары белән ишеткән була. Аларның берсе – Г.Б.Пятаковның бу хокукны кайбер вакытта мәҗбүри рәвештә уйналырга тиешле дипломатик уен гына һәм аңа һич кенә дә җитди караш булырга тиеш түгел, икенчесе – А.М.Томскийның аны вакытлы рәвештә кулланыла торган котылгысыз чара гына дигән сүзләре аны ачындыра-көендерә дә. Ләкин ул әле Ленин һәм Сталинның да шушы фикердә булуына тулысы белән ышанып бетми.

Ә бит милли мәсьәлә чынында юлбашчылар өчен сәяси уен гына була. Ә Пятаков, Томский кебекләр аларның җырын җырлаучылар буларак кына чыгыш ясыйлар. Моңа Сталинның үлем түшәгендә яткан Ленинга 1922 елның 22 сентябрендә язган хаты бәхәссез дәлил. Ул шушы хатында: *«Без, дүрт ел дәвам иткән Гражданнар сугышы чорында милли мәсьәләдә йомшаклык күрсәтеп, аның милли бәйсезлеккә ихластан ышанган тарафдарларын үстердек»,* – дип яза. Һәм юлбашчыдан бу уенны туктатуга рөхсәт сорый. Аны, әгәр дә без бу уенны вакытында туктатмасак, соң булачак, дип куркыта.

Әлбәттә, Солтангалиев әлеге хат турында бернәрсә дә белми. Ләкин ул милли сәясәтнең кайсы юнәлешкә борылганын сизенә, чөнки шушы алдауларны үзе аша үткәрә. Ул башкорт автономиясен тану турындагы килешүнең берьяклы рәвештә юкка чыгарылуына бик нык борчыла. Бу аның өчен көтелмәгән хәл була. Аның якташы Зәки Вәлидигә бигрәк тә авырга килә. Ул, истәлекләрендә язганча, шушы хәбәрне ишетүгә, Ленин янына керә. Моның сәбәбен сорый. Ленин исә, бер дә исе китмичә генә, башкорт автономиясен тану турындагы килешүне беркем өчен дә мәҗбүри булмаган кәгаз кисәге генә дип атый.

Ә бит ул моңа кадәр Ленин һәм Сталинга нык ышана. Аның хәтта, Сталин мотоциклына утырып, бергәләп Мәскәү урамнарын әйләнгән чаклары да була. Әмма моннан соң аның совет җитәкчеләренә булган ышанычы юкка чыга. Ул, алар белән араны өзеп, илдән чыгып китәргә мәҗбүр була. Солтангалиев исә Вәлиди белән элемтәне өзми, зур кыенлыклар белән булса да, аның белән хәбәрләшеп тора. Әлбәттә, конспирация ысулларын да куллана.

Партия һәм ил җитәкчеләре Солтангаливкә беркайчан да тулы ышаныч белән карамаганнар. Аларга аның тирән акылы гына кирәк булган. Әйтик, 1920 елны Татарстан Республикасы формалашкан чагында, аның Халык Комиссарлары Советы рәисе итеп билгеләү тәкъдимен Сталин катгый рәвештә кире кага. Солтангалиев урынына бу постка Сәхибгәрәй Сәетгалиев билгеләнә.

Шундый ук хәл 1922 елны да кабатлана. Башкортстан Советлары съездында Совнарком рәисе урынына – Солтангалиев, ә БашЦИК рәисе постына Муса Мортазин кандидатуралары тәкъдим ителә. Ләкин әлеге тәкъдим үтми кала. Чөнки бу Солтангалиевнең Татарстанны һәм Башкортстанны союздаш республикалар дәрәҗәсенә күтәрү өчен көрәшендәге позициясенең ныгуына китерәчәген Сталин бик яхшы аңлаган. Аңа Солтангалиевнең милли республика

башында торуы һәм шул сыйфатта Советларның X съездында Татарстан яки Башкортстан исеменнән чыгыш ясау мөмкинлегенә ия булуы һич кенә дә кирәкмәгән.

Шулай да Солтангалиев съезд алдыннан зур активлык күрсәтә. Казахстан Республикасы Совнаркомы председателе Мендышевның «Париж» кунакханәсендәге бүлмәсендә съездга милли республикалардан сайланган делегатларның фракция утырышы була. Анда Татарстаннан – К.Мохтаров, Г.Мансуров, Р.Сабиров, Ш.Усманов, Башкортстаннан – М.Мортазин, М.Халиков һәм Кушаев, Казахстаннан – Мендышев һәм Морзагалиев, Төркестаннан шул вакыттагы Үзәк Башкарма комитеты рәисе Хадыралиев катнаша.

Солтангалиев үз чыгышында съездда бергәләшеп, оешкан төстә хәрәкәт итәргә чакыра. Утырышта партия Үзәк комитеты исеменә милли республикаларны һәм өлкәләрне СССР составына союздаш республикалар рәвешендә кертүне сорап мөрәҗәгать юлларга дигән карар кабул ителә. Делегатлар чыгышларында да шушы фикер яңгырарга тиеш була.

Мөрәҗәгатькә имзаларны Шамил Усманов җыя. Съездның фракция утырышында шушы таләп Солтангалиевнең үзенең, К.Мохтаровның, М.Халиковның, Мендышев һәм Хадыралиевнең чыгышларында яңгырый. Ләкин Сталин аны, бу Россияне таркатуга юнәтелгән таләп, дип, кире кага.

Партиянең 1923 елның апрелендә булып үткән XII съездында СССРның шушы рәвештә төзелүенә каршы чын мәгънәсендәге фетнә пәйда була.

Солтангалиев съезд алдыннан зур әзерлек эше алып бара. Ул Казахстанның Мәскәүдәге вәкиле Морзагалиев, Башкортстан вәкиле Абдулла Адигамов белән элемтәгә керә. Солтангалиев, съездга ныклап әзерләнүләрен сорап, Азәрбайҗанга, Төркестанга, Татарстанга, Кырым һәм Башкортстанга хатлар җибәрә.

Съезд барышында Татарстан, Казахстан, Төркестан, Азәрбайҗан, Грузия һәм Дагстан үз вәкилләреннән Үзәк комитетка каршы оппозицион төркем төзи. Төркемнең платформасы барлык милли республикаларны да СССРга тигез хокуклы рәвештә кабул итү, үзәкләштерү сәясәтен йомшату, милли республикаларның үз хәрби көчләрен булдыру тәкъдимнәреннән тора. Ләкин кайбер делегатларның, куркып, моннан чигенүләре аркасында, платформа гамәлгә ашырылмыйча кала.

Шулай да, миллиләрнең оешуы тиешле рәвештә булмаса да, съездда оппозицион тәкъдимнәр шактый нык яңгырый. Л.Д.Троцкий да Үзәк комитетның милли сәясәтен бик каты тәнкыйтьли. Украина һәм Грузия делегатлары СССРның барлыкка килүен республикаларның хокукларын кысу, аларны авызлыклау дип бәялиләр.

Бу көннәрдә Солтангалиев казакъ Турар Рыскулов, грузин Б.Мдивани, азәрбайҗан Н.Наримановлар белән бик нык аралаша. Нәтиҗәдә, күп нәрсәләрне күрә һәм ишетә. Һәм коммунистларның милли проблеманы хәл итәргә җыенмауларына, аңа хакимият өчен көрәштәге уен коралы гына итеп караганлыкларына төшенә.

Съездан соң оппозициядәге миллиләрне Сталин тарафыннан эзәрлекләү куркынычы тугач, Солтангалиев, Троцкий белән очрашып, аңардан ярдәм сорый. Троцкий исә баштарак Мирсәеткә: «Бу ничек килеп чыкты соң әле?.. Син бит әле күптән түгел генә Наркомнацта аның урынбасары идең», – ди. Ләкин Солтангалиев, эш безнең шәхси мөнәсәбәтләребездә түгел, ә илдә һәм бигрәк тә милли республикаларда рус милләтчелегенең үсүендә һәм партиянең моңа берниндидә каршылык күрсәтмәвендә, дигәч, Троцкийның йөзе үзгәрә һәм:

– Минем үземне дә революциядән читләштерергә тырышалар. Тик бу барып чыкмас, – ди[3].

Ләкин барып чыга һәм ахыр чиктә ул илне ташлап китәргә мәҗбүр була. Тик анда да Сталиннан котыла алмый. 1940 елның 20 августында Мехико шәһәрендә яшәгән Троцкийны испанлы НКВД агенты Радо Меркадер боз балтасы белән башына сугып үтерә.

Монысы әле соңрак була. Ә 20 нче еллар башында Троцкий үзен шундый фаҗигале киләчәк көткәнен күз алдына да китерә алмый. Бу вакыт әле аның үз мөмкинлекләренә ныклап ышанган чагы була. Ә менә Солтангалиевнең язмышы инде кыл өстендә тора.

Мәгълүм органнарда аңа карата компромат артканнан-арта бара. Ул күптән инде күзәтү астына алынган була. Аның һәрбер язган хаты алар кулына керә тора. Солтангалиевкә досье булдырыла.

Бу досье Солтангалиевнең СССР төзү вакытында Сталин карашларына каршы булуы турындагы хисабына тагын да байый төшә.

Нәтиҗәдә, ул партиядән чыгарыла, эшеннән азат ителә һәм кулга алына… Солтангалиевнең эше РКП(б) Үзәк Комитетының милли оешмалар белән уздырылган (махсус рәвештә җыелган) IV Киңәшмәсендә карала. Анда аны яклап чыгучылар булса да, Сталин үзенекендә тора. Киңәшмәдә Солтангалиевне буржуаз милләтчелектә гаепләү фикере тантана итә. Алдарак язуымча, аны партиядән чыгаралар, эшеннән алалар.

К.Мохтаров, Р.Сабиров кебек көрәштәшләре аңа, хаталарын танып, партия сафларында торгызуны сорап, Сталинга хат язарга киңәш итәләр. Алар, әлбәттә, Солтангалиевнең, партиягә кайтып, ниндидер югары постка билгеләнәчәгеннән, милләткә күбрәк файда китерә алачагыннан чыгып эш иткәннәр.

1926 елның март-апрелендә Сталин аны ике мәртәбә үз янына чакыра. Ул, аңардан күпме генә шикләнсә дә, аның акылына һәм эшчәнлегенә мохтаҗ була. Очрашу вакытында Сталин, Солтангалиевнең, хаталарын танып, үзен партиядә калдыруны сорап матбугатта чыгарга әзерлеген белгәч, аңа: «Моны эшләү Сезгә кыен булмасмы? Карагыз, уйлагыз! Миңа калса, Сезнең өчен хаталарыгызны тану җиңел булмас кебек», – дигән. Чыннан да, моны эшләү аның өчен җиңел булмас иде. Бәлки, Сталин, аның партиягә кайтуын теләмәгәнгә күрә, күңеленә махсус рәвештә шик салгандыр. Кем белә, Сталин мәкерлеләрнең дә мәкерлесе булган бит.

Дөрестерме-юктырмы, ләкин 1938 елны Черек Күл төрмәсендә биргән күрсәтмәләрендә Солтангалиев берәү аркылы Мостафа Кемальнең бу турыдагы фикере белән кызыксынуын әйткән. Төркия җитәкчесе аңа, имештер, матбугат аша тәүбә хаты язарга тәкъдим иткән. Ул да аның партиягә кайтуы милли эшләр өчен файдалы булыр дип уйлаган. Әлбәттә, бу бик шикле мәгълүмат. Гомумән, аның 1938 елгы ике томнан торган язмаларында чынбарлык һәм дөрес булмаган мәгълүматлар бергә үрелгән. Аларны бер-берсеннән аеру җиңел түгел.

Ләкин бу очракта шунысы гына бәхәссез. Мостафа Кемаль Ататөрек Солтангалиевнең эшчәнлеге, гомумән, СССРдагы төрки халыкларның язмышы белән даими кызыксынып торган.

Тик менә ничек кенә булмасын, Солтангалиев тәүбә хаты язмаган, мөртәтлек юлына басмаган. Ул бирешми дә, кимсенми дә. «Охотсоюз» дигән оешмада эшли

---

[3] ЦГА ИПД, ф.109, оп.5, д.55, тт.2, Л.369.

башлый. Ачлы-туклы яшәвенә дә карамастан, үз тирәсенә тарафдарлар туплый. Бик еш кына Татарстанда, Башкортстанда була.

Совет властеның милли проблеманы беркайчан да уңай хәл итәргә җыенмавына инанганнан соң, ул аңа каршы коралды восстание оештыру турында уйлана башлый. Чөнки инде ул бу вакытта Россиянең СССР рәвешендә озак яши алмаячагына тулысы белән ышанган була.

Бу аның 1924 елны язылган «Об основах экономического, политического и культурного развития тюркских народов» исемле хезмәтендә тулы чагылыш таба. Әлеге хезмәтне гениаль әсәр дип билгеләү һич кенә дә ялгыш булмастыр. Чөнки ул, беренчедән, методологик яктан төгәл. Икенчедән, дөньякүләм үзгәрешләрне җентекләп тасвирлаган, капитализмга тулы бәя биргән хезмәт. Аның бәяләмәләре марксизмга капма-каршы. Автор бу хезмәтендә Шәрык дөньясының бүгенгесен генә түгел, аның иртәгесе көнен дә билгели. Алай гына да түгел, һәр Шәрык иленең язмышын фаразлый.

Солтангалиев яңа барлыкка килгән СССРга да бәяне әнә шул күзлектән чыгып бирә. Ул Мәскәүнең төрки халыкларны бүлгәләп, аларны таркату сәясәтенә аерым басым ясый һәм ахыр чиктә моның илне таркатуга китерәчәген дәлилли. *«Россия, күп милләтле рус дәүләте буларак, үзенең таркалуына йөз тота. Монда властька кайсы гына сыйныф килсә дә, аларның берсе дә аның элеккеге бөеклеген торгыза алмас. Панрусистлар, СССРны төзеп, бердәм һәм бүленмәс Россияне күпме генә торгызырга, башка халыклар өстеннән великоруслар гегемониясен урнаштырырга, республикаларның хокукларын гади провинция хокуклары белән тәңгәлләштерергә тырышсалар да, бу кире нәтиҗәләргә китерәчәк... Бүгенге СССР рәвешендә торгызылган Россиянең гомере кыска булыр. Ул таркалыр»*. Бу минем ирекле тәрҗемәм генә. Аның русчасы күпкә көчлерәк һәм үтемлерәк.

Әлеге хезмәттәге фикерләр Солтангалиевнең көрәштәшләре тарафыннан кат-кат тикшерелә һәм шактый кайнар бәхәсләр дә уята. Кайберәүләр бу фикерләрне тулысынча кире кагалар, хәтта аның белән мөнәсәбәтләрен дә өзәргә әзер булалар.

1926 елны Мәскәү шәһәрендә бер татар сәүдәгәренең фатирында бик кызыклы очрашу була. Анда Солтангалиев, Көнчыгыш институты директоры Габдулла Гыйсмәти һәм күренекле тарихчы Һади Атласи катнаша. Болар арасында төп сүз татар һәм аның дәүләтчелеге турында бара.

Солтангалиев Һади Атласидан, Сез тарихчы буларак, татар халкының киләчәгенә ничек карыйсыз, дип сорый. Атласи бу сорауга, мин хәзер бу мәсьәләгә пессимистик караштa торам, дип җавап бирә. Һәм сәбәбен илдә пролетариат диктатурасы тантана итүе белән аңлата. Әгәр дә бу шулай дәвам итсә, татарлар һәм башка вак халыклар юкка чыгачак, аларны эрерәк милләтләр йотып бетерәчәк, ди ул.

– Ә республикалар, аларның әһәмиятен нәрсәдә күрәсез? – бу сорауны Солтангалиев бирә һәм мондый җавап ала:

– Алар ярым коммунист, ярым милләтче татарларның халыкны, аның культурасын коткару максатыннан төзелгән паллиативны яки аңа үлем алдыннан бирелә торган очсыз даруларны гына хәтерләтәләр.

Моны Солтангалиев һәм Гыйсмәти Совет власте шартларында татарларның киләчәге юк дигән рәвештә аңлыйлар.

Солтангалиевнең тормышындагы шушы эпизод турында Черек Күл төрмәсендә түзә алмаслык җәзалаулар нәтиҗәсендә язган икәнлеген онытырга ярамый. Аннан Һ.Атласи турында мөмкин булган кадәр үзләре ишетәсе килгән мәгълүмат алырга тырышканнар. Ә бит шушы милләтпәрвәр тарихчы бу көннәрне үзе дә зинданда була, аны да шушы рәвештә каты җәзалыйлар.

Солтангалиевтән Галимҗан Ибраһимовның бу мәсьәләгә нинди караштa торганлыгы хакында да сораганнар булса кирәк. Чөнки бу авыру язучыны Кырымнан алып кайтып Пләтән төрмәсенә китереп ташлаган вакытка туры килә. Шунлыктан әдипкә карата да аны пычратырдай мәгълүматлар кирәк булгандыр. Г.Ибраһимовны да бертуктаусыз үтерердәй итеп кыйныйлар. Һәм, чыннан да, ул Яңа ел алдыннан шунда үлә дә.

Дөрестерме-юктырмы – язучы, имештер, төрмә диварына: «Юкка гына хезмәт иттем сез дуңгызларга», – дип язып калдырган.

Ә Солтангалиевтән 1919 елда Галимҗан Ибраһимовның да Совет властена карата әйткән сүзләрен исенә төшерткәннәр. Язучы шулвакыт пролетариат диктатурасы һәм милли культура, милли бәйсезлек бер-берсенә капма-каршы төшенчәләр, дигән, имеш.

Г.Гыйсмәти шушы әңгәмә вакытында Совет властеның татарларның үсеш процессына комачау түгел икәнлеген исбатларга тырышкан.

Ә Солтангалиев исә, Атласинең автономиягә пессимистик карашы белән килешмәстән, автономиянең төрки-татарларның бәйсез дәүләтләрен аякка бастыру өчен кадрлар әзерләү мәктәбе икәнлеген исбат итәргә тырышкан. Бу нәкъ Ленинча. Заманында Ленин да автономиягә бәйсезлеккә әзерлек мәктәбе дип караган. Һәм шунлыктан аңа каршы булган[4].

Солтангалиев белән Һади Атласи арасында да зур уртаклык барлыкка килгән булган. Бу бигрәк тә аларның 1926 елның яз ахырындагы Солтангалиевнең Мәскәүдәге фатирындагы очрашуы вакытында ачык күренә. Солтангалиев тарихчыны үзенең «Об основах экономического, политического и культурного развития тюркских народов» исемле мәгълүм тезислары белән таныштыра, аның төп моментларын, бигрәк тә марксизм-ленинизмны тәнкыйтьләгән урыннарын җентекләп шәрехли. Атласи моны зур кызыксыну белән кабул итә. Ул тик Кытайның милли азатлыкка ясаячак йогынтысы турында язылган урыннар белән генә килешеп бетми. Аныңча, Кытай төрки халыкларның милли азатлык көрәшендә таяныч була алмый. Атласи, озак йокыдан уянган Кытай аларны, бик тиз генә йотып, ашказанында кайнатып юк итәчәк, ди. Шунлыктан, аның фикеренчә, Әфганстан, Персия (Иран) кебек илләрнең Кытай уянганчыга кадәр үк империализм богавыннан котылулары зарур. Димәк, Кытайны уяту мәсьәләсендә ашыгырга кирәкми, ә менә төрки халыкларының милли азатлык өчен көрәшләрен ашыктырырга кирәк.

Бу сүзләрдән соң Солтангалиев тагын да ачыла төшә. Ул үзенең Совет властена каршы, төрки халыкларның азатлыгы өчен көрәш планнары турында сөйли. Шуннан соң Атласи, бик тиз генә урыныннан торып, бүлмә буйлап йөри башлый һәм:

– Мин синең кайнар һәм саксыз икәнлегеңне беләм, тагын да 1923 елдагы кебек эләгүең бар, – ди.

Солтангалиев аны тынычландыра. Шуннан соң Атласи да аңа Казан мулласы Апанаев кебек берничә татар милләтчесе белән берлектә Татар-Башкорт Республикасына каршы чыгулары һәм сул эсерлардан большевикларга күчкән, соңрак җир эшләре буенча халык комиссары постын биләгән Якубов, Г.Баимбәтов һәм Г.Әминевләрнең алар белән бергә көрәш алып барганлыклары турында сөйли. Көрәшнең максаты дәүләтчелекне торгызу инициативасын Советлар кулыннан алып, үз кулларына төшерү икәнлеген аңлата.

Тәҗрибәле тарихчы хаклы була. Солтангалиев тагын саксызлык күрсәтә. 1928 елны ул янә кулга алына һәм шул елның ахырыннан башлап 1931 елның 1 мартына кадәр

---
[4] В.И.Ленин. Полн.собр.соч., т.30. с.42.

Мирсәет Солтангалиевнең тоткынлыкта төшкән фотосы. 1928 елның 14 декабре

«1938 елны Солтангалиев, янә кулга алынып, Казанның Черек Күл подвалында газап чигә.

төрмәдә ялгыз камерада утыра. Аны үлем җәзасына хөкем итәләр. Бу карар 10 еллык сөргенгә җибәрү карары белән алмаштырыла. Һәм ул 1934 елга кадәр Соловкида сөргендә була. Солтангалиев монда да тик ятмый, көрәшен дәвам итә. Ул Кашшаф Мохтаров, Борһан Мансуров, кырымлы Дерен Аерлы һәм башка сөрелгәннәрне үз тирәсенә туплый.

Һади Атласи да бу язмыштан котыла алмый. Соңгы тапкыр сөргенлек язмышы аны Солтангалиев белән Соловкида очраштыра. 1933 елны саулыгы какшау аркасында ирекка чыгарылган галимне 1936 елның 28 июлендә янә төрмәгә утырталар. Шул елның августыннан башлап 1937 елның маена кадәр аннан 16 мәртәбә сорау алалар, әллә кемнәр белән күзгә-күз очраштыралар, газаплыйлар. «Атласов эше» барлыкка килә. Шуның нәтиҗәсендә 26 кеше кулга алына. Аларның тугызына, шул исәптән Һади Атласиның үзенә дә үлем карары чыгарыла. 1938 елның 15 февралендә ул гамәлгә ашырыла. Солтангалиевнең дә соңгы көннәре якынлаша…

Ул да, амнистияләнеп, ирекка чыга. Яшәү урыны итеп Саратов шәһәре билгеләнә. Ул монда, Казандагы Атласи кебек үк, эшсезлектән интегә, мохтаҗлыкта яши, өзлексез махсус күзәтү астында була. Шымчылар аның һәрбер адымын, һәр әйткән сүзен тиешле органнарга җиткереп торалар.

1938 елны Солтангалиев, янә кулга алынып, Казанның Черек Күл подвалында газап чигә. Аннан бертуктаусыз сорау алалар, күз алдына да китерә алмастай җәзаларга тарталар. Моңа шаһит булган тоткыннар, аның шул газапларга чыдый алмыйча кычкыруы бөтен төрмәгә яңгырап торды, дип сөйләгәннәр.

Рәсми документларга караганда, ул 1940 елның 8 декабрендә үлем җәзасына хөкем ителә. Бу карар тормышка ашырылганмы-юкмы – анысы билгеле түгел. Солтангалиевнең моннан соң поездга утырып киткәнлеген дә күрүчеләр булган, дип тә сөйләгәннәр.

Сталин аны үз янына алып, башка эшкә тарткан дигән хәбәрләр дә юк түгел. Солтангалиев турында тагын әллә нинди имеш-мимешләр бар. Боларны әле тулысы белән ачыкларга кирәк.

Ләкин ничек кенә булмасын, аның идеяләре бүген дә үзенең дөреслеген раслап килә. Нәкъ ул фаразлаганча, СССР таркалды. Ул әйткәнчә үк, Көнчыгыш, уянып, дөньяда яшәүнең үрнәк мисалларын тудыра, зур тизлек белән алга бара. Солтангалиев идеяләренең кояшы һаман да дөнья күгендә балкый.

Солтангалиев кем ул?

Бу сорауга без, ул – бөек шәхес, дип җавап бирәбез. Солтангалиев безнең милли горурлыгыбыз, аны оныту һич кенә дә мөмкин түгел! ■

Безнең мирас №10 октябрь 2020

Татар хатыны ниләр күрми: кыйналган Зөбәйдә «Эш»е

Галим Хисамиев

Белгәнебезчә, Әби патша – Екатерина II фәрманы буенча Россия империясендә төрки халыкларны, беренче чиратта, татарларны буйсындырып, күзәтү астында тоту максатында 1788 елны Оренбург Мөселман диния нәзарәте – «Мәхкәмәи шәргыя Ырынбургия» оештырыла[1]. Аның белән идарә итү, Ш.Мәрҗани хәзрәтләре язганча[2], куштан-ялагай, Россия патшаларына лояль мөфтиләргә йөкләнә. Шулай да мондый оешманың булуы Идел буе мөселманнарына күпмедер дәрәҗәдә дин иреген тәэмин итә. Моннан тыш, гаиләдә кыерсытылган кайбер татар хатын-кызлары, үз хокукларын яклап, Диния нәзарәте казыйларына мөрәҗәгать итә башлыйлар.

Архив материаллары арасында Кама аръягындагы, төгәлрәге, Татарстанның хәзерге Алексеевск һәм Чистай районнарына кергән авылларында яшәүче татар хатын-кызларының язмышына, ягъни Гөләйза-Пелагея һәм Зөләйхаларның замандашларына кагылышлы дистәләрчә «Эш» саклана. Мәсәлән, З.Бәширова (Коры Көрнәле, 1828), З.Зәйнетдинова (Чулпан, 1835), Х.Нуретдинова (Әшнәк, 1835), Х.Габделхәкимова (Ямбакты, 1837), М.Ильясова (Коры Көрнәле, 1846), М.Мөхетдинова (Коры Көрнәле, 1852), М.Габденнасыйрова (Урта Тигәнәле, 1852), Б.Исланова (Кыр Шонталасы, 1859), С.Госманова (Түбән Тигәнәле, 1862), балигъ булмыйча кияүгә бирелгән Мөхәммәтҗанова (Урта Тигәнәле, 1870), агуланган Б.Гайнетдинова (Яуширмә, 1873), Ф.Сәгадәтдинова (Әшнәк, 1875), М.Әхмәдиева (Әшнәк, 1877), М.Миңнеголова (Мөслим, 1888), Ш.Мөхәммәтдинова (Яуширмә, 1891), Ш.Ибраһимова (Ямбакты, 1901), Б.Габделлатыйпова (Чирүле Шонталасы, 1902), С.Фәтхуллина (Түбән Тигәнәле, 1904), Х.Вафина (Кыр Шонталасы, 1908), Б.Вәлиева (Коры Көрнәле, 1908), Н.Хөснуллина (Урманасты Шонталасы, 1911), С.Шәмсетдинова (Урта Тигәнәле, 1912), М.Мөхәммәтфатыйхова (Әшнәк, 1912), Н.Галимова (Урманасты Шонталасы, 1914), С.Галимуллина (Урта Тигәнәле, 1915), Б.Хәсәншина (Урта Тигәнәле, 1916) һәм башкаларның, ир-атлар тарафыннан хокуклары кысылу сәбәпле, аерылышу яки никахның дөреслеге турындагы мөрәҗәгатьләре һәм тикшерү документлары бар.

Бу хезмәтне язганда Башкортстан Республикасы Үзәк тарих архивы (И-295 нче фонд), Татарстан Республикасы Милли архивындагы Казан губерна идарәсе (2 нче фонд) документлары, Кыр Шонталасы авылына кагылышлы IX һәм X ревизия материаллары (3 нче фонд) һәм метрика кенәгәләре (204 нче фонд) файдаланылды.

Аңлашылганча, без аны бернинди эмоциягә, артык субъектив фикерләргә бирелмичә, кемне дә булса кимсетү яки гаепләү максаты белән түгел, ә коры архив документлары нигезендә яздык. Аларда күптән бакый дөньяга күчкән әбиләребезнең нинди шартларда гомер итүе, катлаулы язмышы ачык чагылыш таба.

[1] Татарское национальное движение в 1860-1905 гг.: монография / И.К.Загидуллин. – Казань: Тат.кн.изд-во, 2014. – с. 423.

[2] Шиһабетдин Мәрҗани. Мөстәфадел-әхбар фи әхвәли Казан вә Болгар. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1989. – 415 б.

* * *

Төрле язмышлар белән таныштыру алдыннан, текстлар аңлашылсын өчен, кайбер шәргый һәм этнографик төшенчәләргә аңлатма биреп китү дә муафыйк булыр дип уйлыйм.

Шәригать кануннары буенча, хатын-кыз, иреннән аерылган очракта, аның йортында 4 ай һәм 10 көн яшәгәннән соң гына китә алган. Бу вакыт **гыйдәтт** дип аталган һәм ул хатын-кызның йөкле (көмәнле) булуын билгеләү өчен кирәк булган. Мәгълүм ки, шушы вакыт килеп җиткәч, карында яралган сабыйга җан өрелә.

Калым (яки калын) – кияү тарафыннан кәләшнең әти-әнисенә яки туганнарына никахка кадәр бирелә торган түләү, йолым, мал яки акча. Алда каралачак «Эш»ләрдә русча калым диеп язылса да, сүз күп очракта мәһәр турында барган.

Мәһәр (яки бирнә) – кияү тарафыннан кәләшкә никахлашканда бирелә торган милек, мал, әйбер, акча. Никах турындагы килешүдә шаһитлар катнашында аның күләме тәгаенләнгән һәм метрика кенәгәсенә теркәп куелган. Мәсәлән, 1866 елның 27 мартында әниемнең бабасы – 24 яшьлек Хисмәтулла Габделхәким улы Әбекәев 23 яшьлек Миңлеҗамал Хөснетдин кызы Сәйфетдиновага өйләнгән. Кыз ризалыгы шаһитлары – Мөхәммәдәмин Динмөхәммәд улы белән Мифтахетдин Сәйфулла улы. Мәһәр 300 сум тәшкил иткән. Әлеге сумма ул заманда дистәләрчә ат бәясе! Әтием ягыннан бабам Госман Исәнәли углы әбием Нәзифә белән никахлашканда, мәһәр 150 сум билгеләнгән. Кыз ризалыгы шаһитлары бабамның бабасы Габделкайсар Биктимер улы һәм Хисаметдин Габделхәким улы булган. Никах Кыр Шонталасы авылының указлы мулласы Хуҗахан Яһүдин тарафыннан метрика кенәгәсенә теркәлгән. Шаһитлар аңа үзләренең тамгаларын куйганнар.

Никах хатын гаебе белән өзелгән очракта, мәһәр иргә кире кайтарылган. Никах, җенси мөнәсәбәтләргә кермичә, ир гаебе белән өзелгәндә, хатын-кыз мәһәрнең яртысына гына хаклы булган.

Талак – бу сүз гарәпчә ирекле булуны аңлата, аерылышуның бер төре. Ир-ат тарафыннан «талак» сүзе өч кат әйтелгән очракта, аерылышу үз көченә керә. Шуннан соң хатын кеше иренә җәмәгать була алмый. Ир аңа янәдән, башка кешегә кияүгә чыгып, аннан аерылган очракта гына өйләнә алган. Талак әйтеп аерылышкан очракта, ир-ат мәһәрен кире кайтара алмый.

Хулла (гарәпчә «хулун» – бушлык, буш урын) яки хлюг мөселманнар арасында таралган аерылышу алымы – татулык белән килешүдән гыйбарәт. Ул, гадәттә, хатын тарафыннан тәкъдим ителсә дә, аңа ир-атның ризалыгы да кирәк булган. Бу очракта хатын-кыз үзенә бирелгән мәһәрдән яки аның өлешеннән баш тарту, аны иренә кире кайтару хисабына ирек алган. Андый төрдәге аерылышуны хатын-кызның җәмәгатеннән ирек сатып алуы дип тә бәяләргә мөмкиндер.

Алда тәкъдим ителә торган хатын-кызлар язмышы XIX гасырдагы татар кешесенең шәргый һәм дөньяви хокукы тарихын өйрәнү өчен дә кызыклы чыганаклар булыр дип уйлыйм.

Зөбәйдә Бәширова тарихы

Бу **«Эш»** Спас өязенең Коры Көрнәле авылыннан Зөбәйдә Бәшир кызы турында.

1828 елның февралендә язылган үтенеч хатында: *«Мин Коры Көрнәле авылыннан, ирем йомышлы татар Хәбибулла Рәхмәтуллин белән гомер кичерәм. Кияүгә чыкканнан бирле, инде менә дүрт ел, ирем мине төрлечә җәберли: сәбәпсез әрли,*



Килешүнең 1 нче бите

Килешүнең 2 нче бите



Текстны Рәйсә Шәрәфиева укыды

Копия хат хәлегъдән

(Аерылышу хакындагы килешүнең күчермәсе)

1828 нче елда июльнең 29 нчы яумендә *(көнендә)* Спас округы Керәнле волос[т]е шул ук Керәнле волосенең бән *(мин)*, Хәбибулла Рәхмәтулла углы һичкемнән икраһ *(көчләү)* вә иҗбарсез *(мәҗбүриләүсез)* кәнд *(үз)* ризалыгым илә хәлегъ кылдым *(аерылдым)*. Үземнең тәхет никахымда улган *(булган)* Зәбирә Бәшир кызын туксан сумлык әшьяләр *(әйберләр)* тәкабеленә *(бәя бәрабәренә)* үзләрен охшашлы кыйммәтләре илән гадат *(йола буенча)* нәфәкасенә *(матди тәэмин итү)* вә һәм сәкәнә *(бергә яшәү)* хакын сакыйт итмәк *(бетерү)* шарты берлә, исбат вә тәхкыйк *(раслау)* өчен, шаһитлар хозурында бән, Хәбибулла Рәхмәтулла углы мәзкүр *(әлеге)* әшьяләрне *(әйберләрне биреп)* кабз кылыб *(килешеп)* тамга салдым.

Вә янә бән, Зәбирә хатын Бәшир кызы бу зәүҗем *(ирем)* Хәбибулла Рәхмәтулла углындан садир улнан *(чыгучы)* иҗабе хәлегъне *(аерылышу ризалыгын)* кабул кылыб, мәзкүр *(әлеге)* әшьяләрне *(әйберләрне)* төрле кыйммәтләр илә йәдән бил йәд *(кулдан кулга)* карз *(бирүне бурыч)* кылдырдым. Баләдә *(югарыда)* мәктүб *(язылган)* шаһитлар хозурында түшәк вә йә сандык – 20 сум, камзул – 25 сум, бурлат күлмәк – 12 сум, сары кыйтат тун – 23 сум, ике сарык, өч бәрәннәр илә – ун сум.

Хазир *(янда булучы)* шаһитлар: Хәбибулла Мәрсәли углы шаһит булыб тамгам салам ..., Сәйфулла Җәлал углы шаһит булыб тамгам салам ... вә янә Иске Хыяллы иленең Зәбир Нәдир углы күрә белеб тамгам салам ..., Хәбибулла Сәйфулла углы шаһит булыб тамгам салам ..., Салих Сәйфулла углы шаһит булыб тамгам салам ..., Рәхимкол Сәлихҗан углы шаһит булыб тамгам салам ...

Имам вә мөдәррис мелла Габдессаттар мелла Шәфи углы.

кыйный, әшәке сүзләр әйтеп хурлый, намазда чагымда астымнан намазлыгымны алып ташлап, әдәпсез сүзләр әйтә. Шул сәбәпле, Диния нәзарәтенең мине үз канаты астына алып яклавын, Спас өязенең Иске Ургар авылының мәртәбәле имамы һәм мөдәррисе Габдессаттар Шәфиев аша тикшерүләр үткәрүне, аның буенча тиешле карар чыгарганчы, миңа Спас өязе Иске Чаллы авылындагы әтием Бәшир Измайлов йортында торырга фатыйха бирүен үтенеп калам. 1828 елның феврале. Үтенеч хаты губерна регистраторы Сергей Иванов тарафыннан язылды, Зөбәйдә шушындый тамгасын куйды», – диелә.

Зөбәйдәнең үтенече Диния нәзарәтендә 10 март утырышында (журналда 11 нче сан белән теркәлгән) тыңланган һәм, дәгъвачының теләген искә алып, тикшерүләрне Спас өязе Иске Ургар авылы имамы һәм мөдәррисе Габдессаттар Шәфиевкә тапшырырга дигән карар чыгарылган. Аңа шәригать кануннары буенча гадел тикшерү үткәрергә, ир белән хатынны тыныч юл белән килештерергә, килешмәгән очракта, ике яктан да җәлеп ителгән медиаторлар (арадашчы шаһитлар) катнашында тиешле билгеләмә язып, алар имзалаганнан соң, Диния нәзарәтенә тапшырырга, Зөбәйдәне, иреннән аерып, әтисенә тапшырудан тыш, башка гамәл кылмаска киңәш ителә.

Утырыш беркетмәсенә мөфти Габдессәлам Габдерәхимов (1765-1840; 1825 елдан Мөселманнар диния нәзарәте мөфтие), утырышчы муллалар – Әмин Дәминев, Габдешәкүр Габдерәхимов, Габденнасыйр Әлмөхәммәтов, теркәүче сәркатип Благовещенский, повытчик Львовский имза куйганнар. Диния нәзарәтенең указы (№522) 1828 елның 20 июнендә имамга җибәрелгән.

Диния нәзарәтенә караган имам Габдессаттар Шәфиев рапортыннан (№4, 29 ноябрь, 1828 ел) күренгәнчә, ул, ике яктан да арадашчы шаһитлар җәлеп итеп, эшне тикшергән. Нәтиҗәдә, Хәбибулла Рәхмәтуллин хатыны Зөбәйдә Бәширова белән аерылышкан. Алар үзара килешү төзегәннәр. Шаһитлар (медиаторлар) имзалаган килешү кәгазе Диния нәзарәтенә юлланган. Утырышта имамның рапорты тыңланганнан соң, аерылышуны раслау, ә герблы кәгазь урынына илле тиенлек 5 бит гади кәгазь кулланган өчен Зөбәйдәдән Спас земствосы суды аша 2 сум 50 тиен акча түләттерү, эшнең тәмамлануы һәм аны архивка тапшыру турында карар чыгарыла. Указ 1829 елның 25 апрелендә тиешле адресатына (земство мәхкәмәсенә – №427, казна палатасына – №428) юлланган.


№ 1120
26 Ноября 1829
М. В. Д.

Октября 24.
1829 года
№ 3292

Земство суды карары. 1829 ел, 26 ноябрь

Спас земствосы мәхкәмәсеннән килгән хатта (№3292, 24 октябрь, 1929 ел): *«Зөбәйдәдән 2 сум 50 тиен түләттерү өчен мәхкәмә утырышчысы Сәйфетдинов җибәрелгән иде. Коры Көрнәле авылы старостасы Госман Хөсәенов аңа бу авылда Зөбәйдә Бәширова исемле кешенең тормавын хәбәр иткән. Шул сәбәпле, Диния нәзарәтенең карарын тормышка ашырып булмый. Старостаның күрсәтмәсен Сезнең карамакка җибәрәбез»*, – дип язылган. Шуның белән эш тәмамланган. Ә Зөбәйдә, иреннән аерылып, Иске Чаллы авылында яшәүче әтисе янына кайтып киткәндер дип уйларга мөмкин. ■

Туймазы Шәкүре

Әнәс Сафуанов*

Беренче Бөтендөнья сугышы ветераннарын бик сирәк искә алабыз. Йөз ел элек булган хәлләрне, шул чор батырларының гомер юлын өйрәнеп, мәгълүматны яшь буынга тапшыру нияте белән, туган авылым Кәкребашта һәм күрше-тирә авылларда яшәгән Беренче Бөтендөнья сугышы ветераннары турында истәлекләр, хатирәләр тупладым. Аларның кайберләре Гражданнар сугышында һәм хәтта Бөек Ватан сугышында да катнашкан. Арада батырларча һәлак булганнары да, Җиңү белән әйләнеп кайтып, илне тергезүдә фидакяр хезмәт куйганнары да бар. Мин үзем малай чакта аларның күбесенең сугыш маҗараларын тыңлап үстем. Бу мәкаләдә сүз шундый батырларның берсе – Шәкүр Хәбиров турында барачак.

Махсус гаскәрләрдән – фронтка

Аблай авылында яшәгән Шәкүр Хәбиров 1910 елда 22 яшендә солдатка алына. Гәүдәгә таза егет патша Николай IIнең махсус гаскәрләрендә хезмәт итә. 1913 елда туган авылына кайта һәм 1914 елда, Беренче Бөтендөнья сугышы башлангач, ул янә махсус гаскәрләргә чакыртыла. Шәкүр карт Краков һәм Варшава өчен барган сугышларда ике медальгә лаек була. Аның: «Миңа 1916 елда Николай II үзе орден

*** Әнәс Сафуанов** – озак еллар буе Башкортстан Республикасының Туймазы районындагы Кәкребаш авыл советы рәисе булып эшләгән. Хәзерге вакытта – төбәкне өйрәнүче, имам-хатыйб, 17 китап авторы. Туган авылы Кәкребашта яши.

бирде», – дип сөйләгәне әле дә хәтердә. Ул вакытта «тәре» дигән сүзне әйтү юк иде. Соңрак кына әлеге орденның зур батырлыклар күрсәткән сугышчыларга гына бирелә торган «Георгиевский крест» икәнен белдем.

«Ватан сугышы чорында хатын-кызлардан торган бригада оештырып, күл буендагы ләмне салам белән бутап, саман кирпечләр суга. Шуннан үзенә эш бинасы төзи.

Сугышта Шәкүр авыр яралана. Краков госпиталендә аның аягын кисәләр.Тик ярасы төзәлми, гангрена башлана. Варшава госпиталендә тагын ике операция кичергәннән соң, Шәкүрне Мәскәүгә күчерәләр. Шулай итеп, ул авылга култык таягы белән кайта. Үзе әйтүенчә, 1916 елда, бәрәңге утырткач, Мәскәүгә протез ясатырга китә. Заказ биргәч, ярасы төзәлеп беткәнгә кадәр авылда тора һәм печәнгә төшкәндә, яңадан барып, протез куйдыртып кайта.

Инвалид солдат җир җимертеп дөнья көтә

Шәкүр 1918 елда Миңлеҗиһан исемле кызга өйләнә. Хөр күңелле, җор телле солдат «агач аяк» булуыннан кимсенми, инвалидлыгына да әһәмият бирми, сау-сәламәт авылдашларыннан калышмый дөнья көтә. Аның кулыннан килмәгән эше булмый. Бик тә оста, теләгәненә ирешә торган үҗәт кеше була ул. Итек-читек тегәргә өйрәнә. Ул вакытта иң кирәкле һөнәр – аяк киемнәрен төзәтү эшенә керешә, киез итекләргә олтан сала башлый. Аның янына якын-тирә авыллардан үтенеч белән килүчеләрнең саны көннән-көн арта.

Колхоз төзелгәч, Шәкүр сбруйчы эшенә тәгаенләнә: арба, фурманнар ясый, дугалар бөгә, йөгән, камыт, сбруйлар ремонтлый. Ватан сугышы чорында хатын-кызлардан торган бригада оештырып, күл буендагы ләмне салам белән бутап, саман кирпечләр суга. Шуннан үзенә эш бинасы төзи. Соңрак оста мичче буларак даны таралган Шәкүрне эшкә тирә-як авыллардан ат белән килеп тә алганнар. Шулай итеп, икенче төркем инвалид буларак пенсия алмаса да, ул мохтаҗлык кичерми.

Медальләрен җиргә күмгән

Шәкүр карт 1946 елда, ятып калганчы, атып кал, дип, хәрби комиссариатта эшләүче авылдашы янына киңәшкә бара. Тегесе исә патша гаскәрләре составында Империалистик сугышта катнашучыларга пенсия юллау мөмкин булмавын әйтә. Орден һәм медальләрен яшерергә, бу турыда беркемгә дә белдермәскә киңәш итә. Солдат кушканны үти: кайту белән орден һәм медальләрен, документларын җиргә күмә. Улы Риф әйтүенчә, иске өйләрен сүткәч, әлеге истәлекләрне эзләп карыйлар. Кызганыч, фоторәсемнәр дә, документлар да, орден һәм медальләр дә табылмый.

«Нигә миңа пенсия? Эшләп алганым башкаларныкыннан ким түгел. Ник бирешергә? Мин бит патша солдаты! Махсус гаскәр солдаты! Ярты Европаны сугышып үттем, Николай патшаның үз кулыннан орден алдым!» – мич чыгарганнан соң, чәйләп-мәйләп алгач әйтә торган сүзләре шушы була батыр солдатның.

Шәкүр Хәбиров 1974 елда 86 яшендә вафат була.

Ат тугрылыгы яисә Шәкүр карт маҗарасы

Шәкүр абзыйның шушы маҗарасы хәтергә уелып калган. Ул аны 1947 елда бездә мич чыгарганда сөйләгән иде.

***

«1918 елның җәе. Илдә Гражданнар сугышы бара. Көн-таң атса, үзгәрешләр. Аклар чигенсә, авылга кызыллар килеп тула яки, киресенчә, яңадан аклар пәйда була.

Беркөн шулай авыл зираты артында, Ык буенда качкыннар ятарлык озын гына чокырсу урында – кызыллар, елганың икенче ярында, Татарстанның Кара Зирек авылы ягында аклар кара-каршы атыша башлады. Сугыш, имеш, тик атакага бару да, «Ур-ра!» кычкыру да юк. Тиккә атып яткан кебек: үлүче дә, яраланучы да юк, шарт-шорт аталар да аталар. Без инде ата-ата идек тә, атакага ташлана идек. Йә инде тегеләр ташланса, штык белән каршы сугыша башлыйбыз. Тфү, болар ни тудый, ни судый. Авылга зыян булмасын дип шөбһәләнәбез. Ярый әле пушкадан эснәрәт атулар юк.

Шулай ике көн атышып яткач, ахыр чиктә кызыллар Түбән Зәет ягына юнәлде. Аклар кире Кара Зиреккә таба чигенде.

Шул чокырдан ерак түгел бер уйсулык, шәп, сусыл үләнле тугай бар. Без шунда күрше Хөснетдин белән атларны бәйли идек. Гел бергә ашап-утлап дигәндәй йөргән атлар бер-берсен шулкадәр якын итә. Бер минутка гына аерылсалар да, юксынып эзләнә, хәбәр биреп, җавап көтеп кешни башлыйлар. Һич аерам димә. Кешеләрдә андый дуслык юк дияргә була.

Кара-каршы басып, тешләре белән бер-берсенең ял төпләрен, сыртын кашыйлар. Үзләре, сөйләшкәндәй, фыр-фыр киләләр. Берәребез атны алдарак алып китсәк, кешнәп, ыргылып, бауны өзәрдәй кыланалар. Җитәкле ат та, туктап, борылып карап кешни, кайтыр якны өнәмәгәндәй, тискәреләнеп, иптәшен калдырып киткәнгә ризасызлык белдерә. Нәкъ ике гашыйк кебек.

Теге көнне кызыллар юл уңаена минем атны да алып киткәннәр. Бәхеткә, Хөснетдин атын алдарак алып кайтып киткән булган. Югыйсә ул да атсыз калыр иде.

Моны ишетү белән чыгып йөгердем. Агач аяк белән йөгерүне үзегез беләсез инде, йөгерү, дисәң, хәтерең калыр. Бәхеткә, күршем Хөснетдин җигүле аты белән кайтып килә иде. Аны туктатып: «Тукта әле, Хөснетдин, – дидем. – Минем атны кызыллар алып киткән. Тиз генә артларыннан куа китәргә исәп. Атыңны биреп тор инде». «Һи-и-и, юләр баш, тинтәкләнмә. Атылып үләсең киләмени? Йөрмә-йөрмә. Шундый вакыт: кеше башы нипачум, шарт и гатавай мәрхүм», – дип үгетли Хөснетдин. Атын да бирәсе килми инде. Күрә торып…

«Атмаслар, мин утны-суны кичкән царски солдат бит әле», – дидем. «Ярый, Ходай уң кылсын», – дип, бик авырсынып та, мине жәлләп тә атын бирде бу.

Безнең тирәдә йә аклар җиңеп, йә кызыллар чигендереп, солдатлар тук-

> **«Безнең тирәдә йә аклар җиңеп, йә кызыллар чигендереп, солдатлар туктап ял итеп, үтеп киткәлиләр иде. Аклар яки кызылларның мирный кешене атып үтерүе яки яралавы кебек хәлләр булмады.**

тап ял итеп, үтеп киткәлиләр иде. Аклар яки кызылларның мирный кешене атып үтерүе яки яралавы кебек хәлләр булмады. Яшь егетләрне үзләре белән войскага солдат итеп алып китүләр булгалап торды анысы. Шуңа инде туп тавышлары, атулар ишетелсә, солдатка ярардайлар базгамы, урмангамы качу ягын карый. Шуңадыр да атып үтерүләр турында уйлау булмады. Кызып, чәмләнеп атны куалыйм, куып җитәсе килә и вчү, бетте-китте. Үз атымны ничек давайлап алу турында уйламыйм, башыма да китермим. Авыл кешесе атсыз – ике кулсыз. Бар эшкә кеше яллауга каласың. Ни сөрергә, ни чәчәргә рәт булмаячак.

Куам атны тегеләр эзеннән. Авылларда туктап, сорашып-белешәм: «Кайсы якка киттеләр? Күптәнме?»

Шаран районы авыллары аша барам, ярсып, атымны куалыйм. Тархан авылында тегеләрнең привалына тап булдым. Солдатлар, әфисәрләр ыгы-зыгы килә, шул тирәдә кайсы бәйле, кайсы җигүле атлар. Алар күп, минеке күренми. Чуртым да табарлык түгел. Туктап, аптырап карап торам. Напрасны килдем, димен. Ишшу, җитмәсә, бу атны да тартып алсалар…

Шулчак атым, арт аякларына басып, ачы бер чинау тавышы чыгарып кешнәп алга ыргылды. Арбадан чак тәгәрәп төшмәдем. Чалкай китеп, агач аягымны мылтык кебек тегеләргә төбәп, арбада ятам. Әллә берәрсе атка сыдырдымы, аттымы дип уйлыйм. Карасам, кызылармеец атланган икенче ат та, арт аякларына басып, безгә таба ыргылды. Минем аткаем икән! Җайдак тыя алмый. Кая ул! Исәнләшкәндәй, кара-каршы килеп туктадылар. Ышансаң – ышан, ышанмасаң – юк, берсенең муенына икенчесе башын куеп, пуф-пуф килеп, гыргылдыклар чыгарып торалар. Пошкыргандай итәләр, ыңгырашкандай итеп, башларын ышкыйлар. Нәкъ ике гашыйк очрашуы. Күзгә яшьләр килде. Шулай да, аларның хозурлануын күзәтүдән башка, атны давайлау кирәк бит әле. Теге кызылармеец,

тезгенен тарткалап, атка суккалаган арада, тиз генә арбадан төшеп, атымның йөгәненнән эләктереп алдым».

Шәкүр карт, йодрыгын йомарлап, тезгенне тоту хәрәкәте ясап алды. Юкка гына патша солдаты булмаган да, махсус гаскәрләрендә хезмәт итмәгән бит. Йодрыгы потлы гер кебек авыр, куллары көрәктәй, киң җилкәле, баһадир булганы күренеп тора.

«Ат, авызлыгын чәйнәп, күзләрен миңа төбәп, исәнләшкән кебек итеп кешни. Әйтергә теле генә юк мәхлукның. Атның бит бар кичереше күзеннән билгеле. Аларның күз карашында акыл, фикер чагыла: шатлык кичергәне дә, пошаманда булуы да билгеле. «Ат елый», – дигәннәре дә хак бит…

Шулай ат миңа үзенең шатлыгын сиздерә. Мин үземне белештермәс хәлдә, тегеңә кычкыра башладым: «Ну-ка, ыслизай мой лошат, – димен. – Дачим украл атны?!» Теге винтовкасын алды да, миңа төбәп: «Уйди, стрелять буду!» – ди. Мин куркуны оныткан, күкрәгемне ачып суга-суга: «Эстриләй, курыкмыйм мин, войнa видал, твой пүлә ни баюс. Ысматри, ранный был, нога потерял. Дай мой лошат, вор, карак, разбойник!» – димен. Ару гына урысча тудыйм-судыйм сүзләр дә өстәп җиппәрәм. Ул чакта бисмилла әйтеп тору юк инде.

Юк тарткалаша, ату белән яный, куркытырга маташа. Мин дөнья ярып кычкырам. Бер кулым белән тезгенне тоткан, икенчесе белән тегенең аягын өзәңгедән ычкындырырга тырышып тарткалыйм. Озак гаугалаштык. Шунда бер әфисәр килеп чыкты: «В чем дело?» – ди бу. «Чум дилы, чум дилы, чикмәннән тун җылы, – димен. – Менә бу вор мой лошат воровал. Биз лошат жит сафсим пропал, ничу дилат. Мин туже воевал, не воровал, – дидем. – Ыскажи, атны биреп, отпускайт итсен».

Кайчан, кайда, кем гаскәрендә воевать иткәнне әйтмәдем. Патша гаскәрендә икәнне белсәләр, пропал, атмасалар да, атсыз калдырулары көн кебек ачык иде. Шуларны уйлап, бу турыда бик җәелеп китмәдем. Әфисәр дә бик сораштырып тормады, кырыс кына: «Ладно, слезай, отпусти, бедный мужик ведь», – дип, тагын ниләрдер әйтте дә, китеп барды. Кызылармеец, аттан төшеп, иярен салдырды да, йөгәнен дә алырга онытып, китеп барды.

Мин, атлы да, тәңкәле йөгәнле дә булып, атымны тәртәгә мичәүләп кайтып киттем.

Кайтуга, күрше-күлән җыелды. Ах-ух киләләр. Инәй белән Миңлеҗиһан бичәм кочаклап ук алдылар. Шатлыктан елашалар. Берсе дә мине исән-сау кайтыр дип көтмәгән. Ә инде атларны алып кайту турында өмет тә итмәгәннәр. Хөснетдин инде куанычыннан чыдый алмый, бер мине, бер атны кочып сөя: «Атсыз калдым дип көяләнгән идем, Аллаһка шөкер. Син дә исән-сау…» – ди.

Башкалар да, ис-акыллары китеп, бот чабалар: «Афәрин, егет икәнсең, солдат!» – диләр. Билгеле инде, башта алар минем турыда: «Юләр, дуамал, ат өчен үләргә китте!» – кебек фикердә булган.

Юләрләнерсең шул, дуамал да булырсың! Атсыз ике кулсыз бит, ягъни җан бирмәккә тиң. Чәм дә көчле, дуамаллык та юк түгел. Кайчак юләрлек тә кирәк. Бар да уңай хәл ителде, шөкер!

Аннан ике атның, бер-берсен танып, ыргылып очрашуы булмаса, теге ат менгән армеецны тотып кара, бар. Атлар мәхәббәте дә моңа төп сәбәпче булды бит. Дуамаллыкка карый, ике хайванның дуслыгы җиңде.

Дөресен әйткәндә, мин үзем дә болай уңай тәмамланыр димәгән идем. Кызулык, чәм белән, утка кергәндәй, үземне белештермәс хәлдә идем шул, Аллаһның рәхмәте, үземнең кодрәтем…» ■

Безнең мирас №10 октябрь 2020

Төмәнәкне кемнәр нигезләгән?

Илфак Шиһапов

Төмәнәктәге йорт

Туймазы ягы авылларын кемнәр нигезләгән соң? Төмәнәкне генә түгел, башка авылларны да. Башкортстан тарихчысы Ә.Әсфәндияров, бик озак еллар архив документлары белән эшләгәннән соң, республикадагы күпчелек авыллар тарихына караган мәгълүматлар бастырды. Төмәнәк авылын нигезләүне дә ул XVII гасыр азагы-XVIII гасыр башында яшәгән Кыр Елан волосте «башкорт»ы Төмәнәк Кудайметов исеме белән бәйли. Һәм бу факт бернинди дә шик уятмый кебек. Тик менә кемнәр икән соң ул шактый гына чыганакларда «Кыр Елан волосте башкортлары» дип исемләнгән төркем? Каян килгән алар? Кайбер тарихчылар күпме генә тырышмасын, Алтын Урда чорында да, аннан соңгы татар ханлыклары чорында да бу якларда татар һәм нугай татарларыннан башка төркемнәр искә алынмый. «Баджгар» һәм «маджгард» (маҗар) кебекләр бар, тик алары – бүгенге венгрлар. Ә бу яклардагы Урда татарлары «кыйпылчыгы» – нугай татарлары. Һәм менә шушы якта (XVI гасыр азагында-XVII гасыр башында) Елан волосте халкы яши башлый. Болар нинди халык соң? Алар кайлардан килгән һәм нинди телдә сөйләшкән? Менә бу мәсьәләләрне тәгаенләү өчен, әз генә булса да XVI-XVII гасырларга кайтып килеп, элекке Казан ханлыгының Рус дәүләте кул астына керү чорын, андагы татарларның шуннан соңгы тормышын бераз гына яктыртмыйча булмас.

Билгеле булганча, XV-XVI гасырларда Идел буеннан алып бүген «Көнбатыш Башкортстан» дип аталучы җирләргә кадәрле биләмәләр Чыңгыз нәселеннән

«

Тик тагын бер үзенчәлек – болардан көньяктарак булган киңлекләрне, ике ханлык арасындагы җирләрне дә кертеп (әйтик, шул ук бүгенге Уфа урнашкан урынны), тарихта «Нугай Урдасы» дип аталган шактый зур һәм көчле берләшмә били.

килгән Казан ханнары кул астында була. Көнчыгыштагы җирләр исә шулай ук Чыңгыз династиясенә барып тоташкан, тарихи әдәбиятка «Себер ханнары» исеме белән кергән, Урта Азия белән бәйле династия кулында санала. Тегесендә дә, монысында да татарлар яши. Тик тагын бер үзенчәлек – болардан көньяктарак булган киңлекләрне, ике ханлык арасындагы җирләрне дә кертеп (әйтик, шул ук бүгенге Уфа урнашкан урынны), тарихта «Нугай Урдасы» дип аталган шактый зур һәм көчле берләшмә били. Аның белән исә Чыңгыз нәселеннән булмаган, шуңа күрә дә хан титулы алырга да хокуксыз, Идегәй нәселеннән килгән татар бәкләре идарә итә. Алтын Урда чорыннан ук, шул ук Себер төбәгендәге һәм Нугай Урдасындагы татарлар да, Казан ханлыгына буйсынганнары да, күчмә яки ярымкүчмә тормыш алып бара. Бары тик Казан тирәсендә генә утрак тормышлы авыллар яшәп килә.

Һәрхәлдә, Каманың сул ягында, Аксак Тимер яуларыннан соң, утрак тормышлы авыл һәм шәһәрләр булуы теркәлмәгән диярлек. Шул ук вакытта, бу өч берләшмәдә дә этник яктан Алтын Урда чорында ук үзара аралашкан, этноска әйләнгән, бер телдә сөйләшкән халык яши. Әлбәттә, татарларда азмы-күпме ыру-кланнарга бүленү дә саклана (әйтик, шул ук Барын, Ширин, Аргын, Мангыт, Кыпчак, Табын һ.б.). Әмма, белгечләр анализлавынча (В.Трепавлов, Д.Исхаков, И.Измайлов), бу бүленеш этник түгел, ә күбрәк административ-территориаль төсмердә булган. Шуңа да Казан, Себер (күпмедер дәрәҗәдә – Кырым һәм Әстерхан да) ханлыкларындагы һәм Нугай Урдасындагы халыкның даими рәвештә бер-берсе белән аралашып, кушылып, кайвакыт зур-зур төркемнәрнең бер территориядән икенчесенә күчеп яшәве табигый хәл. Диалектлары гына аз-маз аерылган (анысы күрше авылларда да күзәтелә) мондагы халыкның да үзләрен – татарлар, ә телләрен татар теле дип атавы ул чордан калган күп кенә документларга теркәлгән. Бу чорның сәяси үзенчәлеге тагын шунда – җир биләмәләренең хуҗасы булып бары тик Чыңгыз нәселеннән килгән ханнар гына саналган. Шулай ук кешене ниндидер югары катламга күтәрү дә шул чор кануннары нигезендә, бары тик алар хокукында гына булган. Шуңа да, әйтик, бүгенгә билгеле тархан ярлыкларының барысы да Казан ханнары тарафыннан бирелгән булуы гаҗәп түгел. Ә менә күчмә Нугай Урдасы бәкләре, аларда күпме генә көч булса да, Казан ханлыгы җиңелгәнче диярлек ул яктан юридик көчкә ия була алмаганнар. Хәер, шулай булса да, Рус дәүләте алар белән шактый аралашып, сәүдә-дипломатик багланышларны тыгыз тотып яшәргә тырышкан.

Нугай Урдасы Казан ханлыгы белән үзара багланышларны киң җәелдергән. Казан ханбикәсе Сөембикәнең нугай бәге Йосыф кызы булуы, Казан ханы Сафагәрәйнең күп вакытта хәрби яктан нугай татарларына таянуы, аларның җәйләүләренең Казан тирәсендә үк булуы, бик күп кенә татар авылларының нигезләнүе дә шул ук дала татарлары белән бәйле икәнлеге инде күптән тарихи яктан исбатланган. Казан ханлыгы халкы бу чорда, элекке Татар дәүләте чорыннан ук килгәнчә, даругаларга, ягъни административ-территориаль берәмлекләргә бүленеп яши. Казан тирәсендә

яшәгән халыкның җир биләмәләре исә Агыйдел һәм Ык буйларында да, Казаннан төньякта һәм Иделнең Тау ягында да, Кинель, Самара, Сок елгалары буенда да була. Монысы да ярымкүчмә тормышның ханлык татарлары арасында шактый таралган булуын күрсәтә. Әйтик, ханга ясак түләүче кеше кышын Казан тирәсендәге биләмәсендә яшәп тә, җәен киек ауларга, мал көтәргә хан тарафыннан бирелгән үз «җирләре»нә барган. Бу күренеш, кайбер мәгълүматларга караганда, XVIII гасырга кадәр дәвам иткән.

Шулай ук, әйтик, Себер татарларыннан булган табыннарның зур бер өлешенең XV гасыр азагы-XVI гасыр башында хәзерге Башкортстан җирләренә күчеп утыруы да, кайбер Себер татарлары төркемнәренең хәзерге Пермь өлкәсе җирләренә, бүгенге Башкортстанның төньягына күчеп килүләре дә фәндә билгеле. Казан ягы татарларының далага (әйтик, ханнар алышынганда), Себергә күчүе дә тарихта теркәлеп калган. Бу табигый хәл. Чөнки бу җирләрнең барысы да борынгыдан ук татарныкы. Әлбәттә, татар чикләрендә күпмедер хәзерге мари, удмурт, чуаш, мордва, хант-остяклар да яшәгән. Тик дәүләт тотучылар – XIII-XIV гасырларда ук бербөтенгә әйләнгән татарлар. Риваятьләр, әкиятләр, җырлар бер үк, тел һәм гореф-гадәтләр дә бер үк. «Идегәй» дастанын гына алыгыз. Аның бер версиясе – Казан ягында, берсе – Себердә, берсе – Дим буенда, берсе – Бөрьяндә, берсе Әстерхан ягында табылуы – үзе үк кызыклы мисал. Ә бит Идегәй – Татар дәүләте, Алтын Урда бәге, Аксак Тимер яуларыннан соң далада яшәгән татарларны бер тирәгә туплаган нәселнең башында торган шәхес. 1552 елда Казан ханлыгы Рус дәүләтенә буйсындырыла. Ләкин Мәскәү гаскәрләренә Казан тирәсендә генә дә әле тагын 4-5 ел каты сугышлар алып барырга туры килә. Бу чорда шактый мөстәкыйльлек алган Нугай Урдасында исә ике бертуган – Йосыф белән Исмәгыйль арасындагы каршылык көчәя, нәтиҗәдә, Казанга ярдәм күрсәтелми. Казан алынгач, Мәскәү белән дус булырга омтылган, үзенең Мәскәүгә буйсынуын таныган, аңа баш игән Исмәгыйль, абыйсы Йосыфны үтергәч, Урданы үз кулына алмакчы була. Әмма Ходай каргаган сыман, далага корылык, аның белән бергә ачлык килә. Ирекле татар казакълары төрле якка тарала башлый, «дус» Мәскәү дә артык ярдәм күрсәтми. Нугай татарларының зур бер өлеше Идел-Урал арасыннан Иделнең көнбатыш ягына күченә. Хәер, бу күчеш әле шактый озак дәвам итеп, XVII гасырның беренче чирегенә кадәр сузыла. Исмәгыйльдән соң күчмә татарлар белән аның уллары һәм оныклары җитәкчелек итә. 1563 елда үлгән Исмәгыйльнең Казан тирәсендә, Ык һәм Кама буйларында җәйләүдә торганы билгеле («Посольские книги по связям...»). Аның нәселдәшләре дә, инде элекке көчләре булмаса да, бу якларда әле үзләрен һаман да хуҗаларча тотарга омтыла. Әле 1586 елда да Ырыс бәк Мәскәүнең бөек кенәзе Федорга, Уфа шәһәре нигезләнү уңаеннан, килешмәүчәнлеген белдерә. Биредә Ырыс бәк сүзләрен китерү урынлы булыр, чөнки алар нугай татарларының үзләрен татар дип атаганын бик ачык күрсәтә: «Говорят у нас в ТАТАРЕХ: неотстатолному другу досадное слово говорить не пригоже...» [Пекарский П. Когда и для чего основывались города

> «
> **Мәскәү гаскәрләренә Казан тирәсендә генә дә әле тагын 4-5 ел каты сугышлар алып барырга туры килә. Бу чорда шактый мөстәкыйльлек алган Нугай Урдасында исә ике бертуган – Йосыф белән Исмәгыйль арасындагы каршылык көчәя, нәтиҗәдә, Казанга ярдәм күрсәтелми.**

Уфа и Самара // Сборник отделения русского языка и словесности Императорской АН.Т.Х., №5, 1872]. Хәер, шушы ук нәселдән булган бәкләр җитәкчелегендәге күчмә татарлар бу җирләрдә әле 1640 нчы елларга кадәр күченеп йөриләр. Башкорт риваятьләре һәм шәҗәрәләрендәге Урмәмәт, Кара Килмәт, Аксак Килмәт кебек бабалар – алар нәкъ менә Нугай Урдасының татар морзалары (болары да билгеле фактлар). Нугай морзаларының бу яклардан күчеп китүе әлеге җирләргә көнчыгыштан килгән калмыкларның һөҗүмнәре белән бәйле. Күпмедер өлеше күчеп китсә дә, аларның кайберләре бу якларда кала һәм, XVII гасырның 30-40 нчы елларында Мәскәү хакимиятенә баш иеп, «башкорт»ка әйләнеп китә. «Юрматы», «Мең» берләшмәләренең шәҗәрәләре ап-ачык итеп шуны сөйли.

Шушы ук чорда, ягъни XVI гасырның икенче яртысы-XVII гасырның беренче яртысы аралыгында, Мәскәү шактый бушый һәм элек Казан ханлыгы кул астындагы җирләрне үзләштерүне «кайгырта» башлый. Монда бер кызыклы үзенчәлек бар: Казан ханлыгын яулап алган Мәскәү кенәзләре үзләрен ханнарның дәвамчылары итеп игълан итә, титулларына «царь Казанский» дигән атама өсти һәм шактый гына халык та, чит илләрнең хакимнәре дә аларны шул дәрәҗәдә кабул итәләр. Шунысы да кызык: бу чорда да, әле шактый соңрак та Мәскәү хакимияте Казан һәм Алтын Урда ханнары тарафыннан бирелгән ярлык-грамоталарны таный, ягъни алар юридик көчкә ия булып кала. Әйтик, элек Казан ханнарыннан тарханлыкка ярлык алган «йомышлы татарлар»ның балалары, оныклары, шул татарча ярлыкларын күрсәтеп, урыс хакимияте чорында да дәрәҗәләрен раслыйлар, ниндидер өстенлекләр алалар… Ләкин үзеңне хаким дип игълан итү – бер нәрсә, ә шул җирләр белән идарә итү, алардан ясак җыю – икенче нәрсә. Шуңа күрә дә, Казанны алып, ул тирәләрдә берничә ел барган баш күтәрүләрне бастыргач, Явыз Иван элек Казан ханнары кул астында булган җирләргә, андагы халыкка мөрәҗәгать итә. Менә шуннан бер өзек: «По взятии Казани, царь Иван Грозный приказал разослать по всем «улусам» жалованные грамоты «черным ясачным людям» (для ханов и царей, «белых московских», покоряемые народы ничем иным не были, как лишь «ясачными» данниками). В царских жалованных грамотах «ласково» «черные ясачные люди» «улещались», чтобы они шли к нему (царю) «без всякого страха, он их пожалует, и они бы платили ему ясак, как и прежним казанским царям» (Ищериков П.Ф. Очерки из истории колонизации Башкирии. Ч.1. – Уфа, 1933). Элекке Казан ханлыгында яшәгән халык, урыс кул астына кергәч тә, төрле катламнарга бүленеп исәпкә алына: морзалар – морза, электән хәрби хезмәт белән бәйле «йомышлы татарлар» йомышлы татар булып кала («служилые татары»). Аларның аерым хезмәтләре өчен тарханлык дәрәҗәсе алганнары «тарханнар» дип йөртелә, ә менә ясак түләүче гади «кара халык» – күп кенә документларда «ясаклы татарлар» яисә «ясаклы чуашлар» дип исәпкә алына. Бу чордагы «чуаш» атамасының милләтне билгеләүгә бернинди катнашы юк, чөнки шул ук вакытта хәзерге чуаш халкының бабалары әле «тау чирмешләре» («горные черемиса») дип йөртелә. Хәер, «ясаклы чуаш» атамасы да XVII гасырның икенче яртысында юкка чыга һәм ясак түләүче татарларны «ясаклы татарлар» дип, үз этник исемнәре белән атап йөртә башлыйлар. Һәм монда шуны ассызыклап әйтергә кирәк: Казан алынгач та, нәкъ шул ясаклы кешеләр беренчеләрдән булып патшага баш ора («челобитный» яза) һәм аңардан йә элекке үз җирләренә, яисә яңа буш җирләргә урнашырга хокук ала («Жалованные грамоты»). Чөнки бу якларга әле урысның кулы җитә алмый.

Ә менә шул ясаклы кешеләрнең Уфа өязенә күчкәннәре исә «башкортлар» яки «ясаклы башкортлар» дип исемләнә башлый. Гади генә итеп әйткәндә, Ка-

«Казан ханлыгын яулап алган Мәскәү кенәзләре үзләрен ханнарның дәвамчылары итеп игълан итә, титулларына «царь Казанский» дигән атама өсти һәм шактый гына халык та, чит илләрнең хакимнәре дә аларны шул дәрәҗәдә кабул итәләр.

«Бабай утары» күренешләре

зан өязендә «ясаклы чуаш» яки «ясаклы татар» иseme белән теркәлгән халык, бу яклардан урыс патшаларына баш орып җирләр сорап алгач, монда «башкорт»ка әйләнәләр. Әйтик, Байлар волостен нигезләүче Шәехдирбыш Миркамалов (Митноманов) һәм аның балалары Казан өязенең Җөри даругасындагы Балтач авылында яшәгәндә, «ясаклы чуашлар» дип аталалар, ә менә Ык, Сөн һәм Иж елгалары буеннан җирләр алгач, «башкорт» дип санала башлыйлар. Урал волосте «башкорт»ларының Түбән Сон авылында яшәгәндә (Татарстанның хәзерге Мамадыш районы), «ясаклы чуаш» булып, бу яклардан җир алгач, «асаба башкорт» яки «вотчинник»ка әйләнүе билгеле. Шул ук кешеләр, ниндидер сәбәп белән кире Казан өязенә кайткан очракта, анда «ясаклы татар» яки «ясаклы чуаш» катламы саналганнар (Теләүлек нәселе моңа мисал). Кыпчак волосте тарханнарының Казан өязенең Нугай даругасындагы Күгәрчен авылында (Татарстанның хәзерге Балык Бистәсе районы) «ясаклы чуаш», «йомышлы татар» булып, аннан тархан дәрәҗәсен алып, «кыпчак башкорт»лары булып саналуы да документлар белән исбатланган (И.Габдуллин, Д.Исхаков). Алай гына да түгел, Юрматы волосте башлыгы Татигач би, XVII гасыр башында әле Казан өязендәге Шәдке авылында яшәп (Татарстанның хәзерге Теләче районы), «йомышлы татар» буларак исәпкә алынган. («Писцовые книги...», Ш.Исәнгуловның «Малоизученные аспекты истории дореволюционного Башкортостана» җыентыгында.) Бу сүзләрне исбатларлык документлар безнең кулда да бар. Урыс хөкүмәте документлары, күпчелек очракта, урыс булмаган халыкларның милләте буенча түгел, ә салым-ясак түләү буенча катламнары белән исәпләнгәнен күрсәтә. ■

Татар матбугаты тарихы

«Чулпан» газетасы

«Чулпан» газетасының беренче бите. 1918 ел

Газета 1918 елда Томск шәһәрендә шактый үзенчәлекле шартларда – мөстәкыйль Себер Республикасы (мохтарияте) өчен көрәш, Русиянең Аурупа өлеше һәм Себер төрки-татар мөселманнарының милли-мәдәни автономиясе вакытында барлыкка килә. «Чулпан» 1917 елның октябрь аенда оешкан Себер мөселманнары мәркәз шурасының басма органы булып тора. Шигаре: «Яшәсен Сибирия мохтарияте! Яшәсен Сибирия мөселманнарының милли вә мәдәни мохтарияте!» Газетада: «Эшче туганнар! Ясагыз үзегезгә оешмалар! Оешуда, берләшүдә көч!» – дигән лозунглар да басылган. Мөхәррире – Әхнәф Таңгатаров (1892-1954).

Басманың үзендә: *«Тоткан юлы Сибириядә яшәүче мөселманнарның милли, ихтыярларын күзәтү, ул тугрыда тиешле вакытта мөзакәрәләр (бәхәсләр) ачып, максатларны һәркем аңларлык җиңел телдә әйтеп бирү. Зур Сибириядә таралган милли мәсьәләләрне мөмкин кадәр җанлырак тоташтыруны күз алдында тотканлыктан, милли кирәкләрне һәрнәрсәдән артык күргән бу гәзиткә һәркем бу көннәрдә язылырга кирәк. Һәр мөселманның өстәлендә бу гәзитәнең булынуы милли бер бурыч!»* – дип язылган.

«Чулпан» Себер Республикасы составында Себер мөселманнары өчен аерым милли вә мәдәни мохтарият булдыру, мөселман эшчеләрен берләштерү, аларга сәяси белем бирү, милли гаскәри берләшмәләр төзү идеясен яклый һәм гамәлгә ашырырга омтыла. Аның сәхифәләреннән Себердә яшәүче татар-башкортларның милли хәрәкәте, Том шәһәрендәге мәдәни тормыш турында кызыклы гына мәгълүматлар алырга мөмкин. Газетаның тагын бер үзенчәлеге ул – литография , ягъни ташбасма ысулы белән басылган.

Игътибарыгызга тәкъдим ителә торган өзекләрне әзерләгәндә, «Чулпан»ның 1918 елгы 5 март санынннан файдаландык.

* * *

Том хәбәрләре

Шәһәремездәге Хәрби комитет мөселман казармасындагы «Мөселман гаскәриләр клубы» залында солдатларны укыта башлады. Мөгаллим һәм лекторлар чакырылып, русчадан, ана теленнән укытыла башландыгы кеби, татар тарихыннан да лекцияләр укыла башлаган.

* * *

21 февральдә шәһәремездә татарча театр булып, Мөселман музыка-драма оешмасы тарафыннан «Ирем кайтты», «Бүләк өчен»нәр куелды. Кичә күңелле генә үтте. Саф файда дарелмөгаллиминдә* укучы фәкыйрь шәкертләр файдасына иде. Театр булган көннең икенче көнендә шул ук шәкертләр файдасына «Кружка» ысбуры да булды.

* * *

24 февральдә Том шәһәрендә мөселман эшчеләренең оешмасы тәшкил кылу хакында бер мәҗлес булып, уставы кабул кылынды һәм хәзердән үк шул эшне вөҗүдкә чыгару *(барлыкка китерү)* тугрысында кирәкле адымнар атларга тиешлеге күрелде. Шул ук оешма янында эшчеләргә махсус җәмәгать кибете ясалу да мөзакәрә кылынып, уставы кабул ителде. Устав буенча бу җәмәгать кибетенә член булу хакы теге эшчеләр оешмасында әгъза булуга бәйләнгән.

Хәрби комитеттан

Большевиклар, ике көн мөддәт *(срок)* куеп, мөселман солдатларының коралларын 38 нче полкның ликвидационный комиссиясенә тапшырырга кушып, мөселман ротасының командирына ультиматум биргәннәр, ләкин сәбәпләре күрсәтелмәгән иде. Бу ультиматум безгә тапшырылганчы корал алынуның сәбәпләрен тикшерү өчен большевиклар илә сөйләшү тиешле булганлыктан, 25 февральдә көндезге унбер ярым сәгатьтә мөселман солдатларының гомуми җыелышы булды һәм ошбу карарлар чыгарылды:

1) Шәһәремезнең эчке хәлләре хәвефле булып, көннән-көн Гражданский сугыш кузгалу ихтималы көтелгәнлектән, түбәнге сыйныф эшче мөселман халыкларының мәнфәгатен күзәтеп, гаскәри оешмаларымызны куәтле тотар өчен, һичбер партиягә кушылып хәрәкәт итмәскә тиешле булганлыгымыздан, коралларны бирмәскә!

2) Гарнизонный советка өч вәкил җибәреп, мөселман солдатлары корал вә патроннарын бирмәскә теләгәнлекләрен аңлатып, ультиматумны алмаштырырга кушып, мылтыкларны вә патроннарны мөселман солдатлары кулында калдыртырга карар кылынды.

Гомуми җыелышта мөселман солдатлары исеменнән сайланган вәкилләр – Юнысов, Кәрим Алтынбаев, Галиев гарнизоннный советка барып сөйләделәр. Большевиклар гафу үтенү мәкамендә җавап бирделәр. Икенче көнне аннан вәкил килеп казарманы карады вә моннан соң ихтиляф *(каршылык)* чыкмаячагына вәгъдә биреп китте.

---

* Сүз Томск шәһәрендәге татар мөгаллимнәре әзерли торган уку йорты турында бара.

Томскта милли тормыш кайнап торган Татар урамының элекке

Бер мәктүб *(хат)* мөнәсәбәте илә

Бу нумер гәзитәмездә ихтиляльдан *(революциядән)* соң берничә вакыт Уфадагы Мәхкәмәи шәргыядә *(Диния нәзарәтендә)* казый булып торган мөхтәрәм Хөҗҗәт әл-Хәким әфәнде Мәхмүдевнең мәктүбен *(хатын)* басамыз.

Кузгатылган бик мөһим мәсьәләләр арасында вакыты үткән һәм күптән хәл кылынганнары булса да, хат әһәмиятен бер дә югалтмый. Бундай мәсьәләләрнең берсе – Сибириядәге мөселманнарның съездын ясап, бер мәркәз тәшкил кылу мәсьәләседер.

Съезд инде үткән елның октябрендә үк ясалып, Сибирия мөселманнарының Мәркәз шурасы төзелде һәм бу Шура, Сибирия фәүкыльгадә *(гадәттән тыш)* съездына да үзеннән кешеләр катыштырып, милли эшләр тугрысында бик күп файдалы карарлар чыгартырга муәффәкъ булды *(иреште)*. Сибирия областной Думасына да алты мөселман вәкил кертергә муәффәкъ булып *(ирешеп)*, милли эшләрне күзәтүдә үзенең вазыйфасын яхшы аңлаганын белдерде. Ләкин безнең бу мәкаләбезне язудан максудымыз Шураның эшләгән эшләрен санап күрсәтү түгел, бәлки, мәктүб мөнәсәбәте илә, уртага килеп чыккан бер вакыйганы ачып китү генә иде.

Хөҗҗәт әл-Хәким әфәнденең мәктүбен игътибар белән укучыларга бик яхшы мәгълүм булыр ки, тегендә, Эчке Русиядәге җәмәгать хадимнәре һәм мөәссәсәләре *(оешмалары)* безнең бундагы хәлләремез берлән никадәр таныш һәм никадәр

һәм бүгенге күренеше

безнең ихтыяҗларымызны аңлап эш йөртергә хазир *(әзер)* булганнармы? Мондагы мөселманнар бөек Сибирия тирә-ягына таралып, бик вак парчаларга бүленгәнлеге һәркемгә мәгълүмме?

«Эчке Русия һәм Сибирия мөселманнары мохтарияте» дигән җансыз бер ләихә *(программа)* белән хәл кыйлуның да уңайсыз һәм гайрәтсез булганлыгын аңлаучылар барлыгын хәзер без, Аллаһка шөкер, ишетә башладык.

Эчке Русияле кардәшләребезнең, бердән, бездән бик ерак торулары, икенчедән, Тупраклы мохтарият *(территориаль автономия)* игълан итәргә хәзерләнеп йөрүләре, табигый, аларга безнең хакта уйлап, безнең ихтыяҗлар тугрысында баш ватарга вакыт та җитми.

Без тагы бер мәртәбә «Эчке Русия вә Сибирия мөселманнары милли вә мәдәни мохтарияте» дигән фикернең тәкъдирнең бертөрле шаяруы аркасында гына килеп чыккан нәзари бер нәрсә булганын, вакыйгъда һичбер файда вә тиешле юл күрсәтә алмаганын әйтеп узабыз.

Үз тарафымыздан без ул фикерне «Эчке Русия мөселманнарының тупраклы мохтарияте» һәм «Сибирия мөселманнарының җөмһүрияте эчендәге милли вә мәдәни мохтарияте» дип икегә бүләбез дә ул ике бүлекне кардәшлек вә аңлашу уе белән бәйләп куябыз... Менә шулай булганда гына, без тугры юлга төшкән булырбыз.

*Текстны басмага **Рәйсә Шәрәфиева** һәм **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

Безнең мирас №10 октябрь 2020

Яңа Татар бистәсе мирасы

Борһанеддин Мәрҗанинең кабер ташы

Айдар Гайнетдинов

Ш.Мәрҗанинең газиз улы Борһанеддин һиҗри 1272 елның 19 рамазанында (1856 елның 10 маенда) дөньяга килгән. Башлангыч белемне әтисеннән алган, аннан Истанбулда җиде ел укыган. Ул башта 1882 елның 1 сентябрендә указ (№6436) алып, әтисе Ш.Мәрҗани белән бергә имам-мөдәррис вазыйфаларын башкарган. Әтисе вафат булгач, аның эшен дәвам иткән.

Борһан хәзрәт 2 мартта кичке сәгать биштә, үпкәсенең ялкынланып шешүе сәбәпле, вафат булган һәм Казанның Яңа Татар бистәсе зиратына әтисе янынарак җирләнгән. Аның кабер ташы чагыштырмача яхшы сакланган һәм формасы, язулары белән Ш.Мәрҗани ташын хәтерләтә.

Текстының укылышы мондый:

Алгы ягы (уеп язылган):

1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) түвүффийәш-шәйху Борһанеддин
3) Мөхәммәд бине Шиһабеддин әл-Мәрҗани фии гашиййәти
4) йәүмил-әрбәгааъи ли-ихдәә гашәра ләйләтән халәт мин
5) җүмәдииәл-үүләә әрбәга вә сәләәсиинә бәгъдә әлфин вә сәләәсәмиъәһ».

Арткы ягы (уеп язылган):

1) «Җәгаләллааһү Тәгааләә
2) кабраһү раудатән мин рийәәдыйль-җәннәһ
3) Борһанеддин хәзрәт Казан шәһәрендә
4) 35 йыл микъдары имамәт вә тәдрис илә
5) гомер кичүреб 62 йәшендә даре бәкайә кайтды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе:

Алгы ягы:

1) «Хөкем Аллаһта.
2) Шәех Борһанеддин
3) Мөхәммәд бине Шиһабеддин Мәрҗани кич белән
4) чәршәмбе көн мең өч йөз утыз дүртенче елның
5) унберенче җөмадиәл-әүвәлендә вафат».

Арткы ягы:

1) «Аллаһ Тәгалә аның каберен
2) җәннәт бакчаларыннан бер бакча итсен.
3) Борһанеддин хәзрәт, Казан шәһәрендә
4) 35 ел микъдары имамлык һәм укыту белән
5) гомер кичереп, 62 яшендә мәңгелек дөньяга кайтты».

Таш үлчәмнәре: 135х44х18.

Алгы ягы

Арткы ягы

Эпиграфик истәлекнең текстыннан аңлашылганча, кабер иясенең чын исеме – Мөхәммәд, икенче иseme, ягъни кушаматы – Борһанеддин, куньясе – Әбел-Габбас. Мәрхүм хуш мәҗлесле, йомшак табигатьле, гыйлем һәм хөрмәт иясе, ачык сөйләү һәм ягымлы телгә ия һәм шулар белән күп мөдәррисләрдән өстен булган. Хәзрәтнең үзеннән соң 5 улы, 2 кызы һәм хатыны калган. Бакыйлыкка күчкән вакытында олы улы – «Мәрҗани» мәдрәсәсендә мөгаллим, икенчесе сәүдәгәр булган, калган өчесе сәүдә мәктәбендә укыган. Кызларының олысы Габдулла бине Галим Агишевта (чыгышы Саратов шәһәреннән) кияүдә, кечесе әле сабый бала гына булган. ■

Безнең мирас №10 октябрь 2020

Фәнир Галимов: «Авыллар, һичшиксез, яшәячәк!»

(Бөтенроссия татар авыллары иҗтимагый оешмасы советы рәисе ***Фәнир Гыйльметдин улы Галимов*** *белән «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире* ***Ләбиб Лерон*** *әңгәмәсе)*

– Фәнир әфәнде, Сез татар авылларын, милли традицияләрне саклау һәм ислам динебезне үстерү юнәлешендә зур эшләр башкарасыз. Моның башлангычы кайда икән? Югыйсә хәзер күп кеше милләт, өммәт турында түгел, ә гаиләсен, үзен генә уйлый...

– Мин инәки ягыннан да, әтки ягыннан да бабакайларны күрә алмыйча калдым. Бабам Миңнулла Гыйниятуллин 1942 елда сугышта һәлак булган. Без үскәндә, хәбәрсез югалган, дигәннәр иде. Соңрак, хатлар язып, белешә торгач, Мәскәү өчен барган сугышларда һәлак булганын ачыкладым. Бабайның каберен эзләп табып, аның төпчек кызын һәм оныкларымны шунда алып барып күрсәттем.

Ә әтки ягыннан бабакай 1927 елда, кече улы Сабир тугач вафат булган.

Өченче хатынына өйләнгәндә бабакайга – 53, ә әбекәйгә 17 генә яшь була. Ул ничек вафат булган? Кызганыч, бу турыда сорап калмаганмын. Әбекәй урманны бик ярата иде. Аягына оек һәм кәлүш киеп, иртә яздан чыгып китәр иде дә, көзгә кадәр һәркөн урманга йөрер, төрле үләннәр җыеп киптерер, анналары кыш буе шуны кешеләргә таратыр, күпләр шуның шифасын табар иде. Ул шактый кырыс, әмма дөреслекне ярата торган кеше булды. Аның баш астыннан беркайчан да Коръән төшмәде, күңелкалебе гел иманда булды. Йөз яшенә җитеп вафат булды мәрхүмәкәй. Миңа да әбекәй йогынты ясагандыр инде… Хәзер үземнең оныклар да гел минем янда.

– Һичшиксез, әбиләрнең оныкларга йогынтысы зур. Үзем дә хатыныма: «Оныкларны күбрәк син кара, аларга нәрсә дә булса өйрәт! Белеп, аңзиһеннәренә сеңдереп калсыннар», – дип әйтәм.

– Әти-әнием колхозчылар, гап-гади авыл кешеләре булды. Без – кечкенәдән фермада бозау карап, көтү көтеп үскән балалар. Укыган вакытта да әти-әни: «Укыдыңмы, дәресеңне карадыңмы?» – дип түгел, ә: «Шул эшне эшләдеңме?» – дип, алга бурычлар куеп тәрбияләде.

Инәки янына гел кеше килә торган иде. «Чүпрәң бармы?», «Оеткың бармы?», «Бер кыерчык ипи биреп тор әле», «Катык биреп тор әле…» – дип керүчеләр бездән өзелмәде. Инәки мәрхүмәкәй үлгәнче кешеләргә бик мәрхәмәтле булды. Гомумән, без үскәндә авыл халкы бердәм, бер-берсенә ярдәмчел иде. Мин бигрәк тә шул вакытларны сагынам. Печән алып кайттың икән, күршең йөгереп керә, күршең алып кайткан икән, син ярдәм итәсең… Без менә шундый ярдәмчеллекне күреп-белеп үстек. Инәкиләрнең тәрбиясе педагогиканың язылмаган кануны иде: «Кеше әйберенә тимә!», «Әби-бабайларга ярдәм ит!», «Кеше белән исәнләшеп үт»… Гап-гади нәрсәләр, әмма, асылына төшенсәң, аларның нигезендә зур тәрбия ята. Ул: «Син шулай бул, син болай бул!» – дип артыгын да әйтми, ә балаларын үз үрнәгендә тәрбияләр иде…

> **«Сау-сәламәт кеше вәгъдә бирә икән, ул аны үтәргә тиеш! Шуннан үземә сүз бирдем: малны фәкать изге эшләргә генә тотарга!**

– Кешеләргә ярдәм итү, мәрхәмәтлелек орлыгы Сезгә менә шул вакытларда ук салынмадымы икән?

– Кешеләргә ярдәм итү мәсьәләсендә минем үз фикер-карашым барлыкка килде. Предприятиемне булдырып, матди мөмкинлегемне ныгыткач, туганнарга, дус-ишләргә акча биреп тора башладым. Әмма намуссызлары кире кайтармас булды. Үземнең дә чыгымнарым шактый күп, кредит түләргә кирәк… Мин шунда: әгәр дә кешенең үз кулаягы хәрәкәтләнә, башы эшли, гомумән, мөстәкыйль гамәл кыла ала икән, аңа акча бирмәскә дигән нәтиҗәгә килдем. Мин бит, акча биреп, үз-үземә дошман гына җыям икән!

Бер гыйбрәтле вакыйганы исегезгә төшерәм. Берәү акча сорап дустына, хәлле генә кешегә барган икән. Тегесе аягын аяк өстенә куйган да: «Менә мин алтын түфли белән дә йөри, гадиен генә дә киеп йөри алам. Әгәр дә сиңа акча бирсәм, син аны кире кайтарып бирмәячәксең… Әйдә, без дуслыкны югалтмыйк, үземә алтын түфли алып киям дә мактанып йөрермен, дуслык та калыр. Ә сиңа акча бирсәм, дуслык бетүгә гаепле булып калырмын», – дигән. Кызганыч, күпләр бурычны вакытында кайтарып бирә белми, ә кайберләре кайтарып бирүне намус эше дип тә санамый… Сау-сәламәт кеше вәгъдә бирә икән, ул аны үтәргә тиеш! Шуннан үземә

Зыялыларыбыз «Төмәнәк» татар иҗтимагый үзәге каршында

сүз бирдем: малны фәкать изге эшләргә генә тотарга! Әгәр дә син кешегә акча бирергә уйлыйсың икән, кире кайтарып алуны өмет итмә. Моннан соң күңелем ялкынланып, яңадан-яңа эшләр эшлисе килеп китте, юл ачылды... Дуслар арасында да үземне башкача итеп түгел, ә аларның тиңдәше итеп тоя башладым. Мохтаҗларга, гарип-горабага, әбиләргә ярдәм итсәң, алар сиңа меңнәрчә рәхмәт әйтеп, догалар укып кала. Ә аяккулы йөреп торган кешегә ярдәм итсәң, алар сине каргап та калырга мөмкин. Хәтта берсе: «Шул акчаларыңа төренеп үлгәнеңне күрсәм иде!» – дип чыгып китте.

Мәчет төзү, чишмәләрне төзекләндерү кебек изге эшләргә күңел тартыла гына. Минем өчен болар рәхәтлек бирә, эшли башлаган эшне тизрәк төгәллисе килә... «Бабай утары» тарих-этнография комплексын төзегәннән соң, кешеләрдән күпме рәхмәт ишеттем. Әби-апалар килеп: «Безнең инәкинең өе шуңа охшаган иде», – дип, шундагы өйләргә кереп, намаз укып чыгалар. Чишмәбезне «Инәкиләр чишмәсе» дип

Төмәнәктәге «Ак өмет» мәчете

атадык. Чыршылар утыртып, һәрбер агачка инәкиләребезнең исемен кушарга булдык. Авылдашларыбыз моны бик теләп кабул итте. Теләгән һәркем килеп чыршы утыртты, чыршыларга инәкиләренең исемнәре язылган такталар элде. Балалар лагере оештырып җибәрдек. Аларның шунда көлешеп, уйнашып йөрүләре минем өчен җан рәхәте.

Әлеге конференцияне уткәрү... Мин аңа җаным-тәнемне биреп әзерләндем, ничек узар икән дип борчылып йөрдем. (Сүз 21-22 август көннәрендә

Башкортстанның Туймазы шәһәре һәм Төмәнәк авылында үткән Төбәкне өйрәнүчеләр конференциясе хакында бара. – ***Ред.***) Аллаһка шөкер, матур гына узды дип уйлыйм. Болар мине яңа эшләргә рухландыра... Гаиләм бу эшләремдә миңа бик ярдәм итә. Хикмәт акчада гына да түгел, күңелең бай булса, күп әйберне эшләп була.

– Үз пенсия акчаларын җыеп, авылдагы чишмәне төзекләндерүчеләр, тәртиптә тотучылар бар бит... Димәк, аларның күңел-калебләрендә шәфкатьлелек, изгелек эшләү теләге ята.

– Әйе, бер тарихчы үзенең пенсия акчасына китаплар чыгара, дидек. (Сүз Карабаш бистәсендә яшәүче Фазыл Вәлиәхмәтов хакында бара. – ***Ред.***) Бу аңа нәрсәгә кирәк?! Китаплар чыгару рухи канәгатьлек бирә, башкаларның аның хезмәтенә булган мөнәсәбәте яңа эшләргә дәртләндерә. Шуның белән ул авылдашларының исемен, аларның кылган гамәлләрен тарихта, киләчәк буын өчен мирас итеп калдыра. Миңа калса, күп нәрсәне эшләү кешенең күңел канәгатьлегеннән, рухи шатлыгыннан тора. Эшләгән эшеңнән канәгать буласың икән, яңасына алынасың килә.

– Милләт турында уйлануларыгыз кайчан башланды?

– Дөресен әйткәндә, җырчы Фән Вәлиәхмәтов белән концертларда йөри башлагач кына, татарның бөеклеген аңлый башладым. Элегрәк миллилеккә әллә ни игътибар да итми идем. Казан, Бөтендөнья татар конгрессы белән аралаша башлау мине 180 градуска үзгәртте...

– Менә шуннан Сез яшәү мәгънәсенә төшенәсез...

– Әнгам Атнабаев язган:

«Син башкортмы, син татармы –
Анда түгел мәсьәлә,
Башкорттан да, татардан да
Урыс туа, –
Вәт бәла!
Менә кайда мәсьәлә!»

Милләтләр бер-берсенә комачауламаска, һәркемнең үз юлы булырга тиеш дип уйлыйм. Нигә мин башкортны яки чуашны әрләргә, алар миңа нишләп каршы булырга тиеш әле?!

– Гади халыкның бернинди гаебе юк. Ул элеккечә дус-тату яшәвен дәвам итә...

– Күптән түгел Кытайдан кайткан кунаклар белән Баймак якларына киттек. Гап-гади башкорт авылына керәбез: кымызлар белән шатланып каршы алалар. Игелекле, ярдәмчел, мәрхәмәтле, җырга-моңга бай халык. Шуңа башкорт кардәшләр арасында дусларым бик күп.

– Татар авылларының киләчәген ничек күзаллыйсыз? Авылларны саклап калып булырмы?

– Мин үзем, туган авылымда яшәүче кеше буларак, Төмәнәкнең һәр сулышын яхшы тоям. Авыл, һичшиксез, яшәячәк! Илдә тырыш кешеләр бик күп. Бүген авылдан 180ләп кеше аталы-уллы Марат һәм Ринат Шәйдуллиннар ачкан заводта эшли. Үзебезнең авыл кешеләре генә җитми, читтән дә чакырабыз. Авылда ун-унбишәр баш мал асраучылар күп. Өендә цех ясап, тимер-бетон әйберләр ясаучы да бар. Россиянең күп төбәкләрендә йөрим: бездәге кадәр шәхси теплица беркайда да юк. Төмәнәктә яшелчәчелек эше 1990 нчы еллар башында ук оешып китте. Анда эшчеләр җитми, читтән килеп тә хезмәт итәләр. Төмәнәк һәм аның янындагы авыллар матур яши һәм яшәячәк дип ышанам. Татар халкы бик тырыш, күршесеннән уздырып яшәргә омтылу аның канына сеңгән.

«

Мәчет төзү, чишмәләрне төзекләндерү кебек изге эшләргә күңел тартыла гына. Минем өчен болар рәхәтлек бирә, эшли башлаган эшне тизрәк төгәллисе килә...

Авылның киләчәге байлык һәм тамак туюда гына түгел. Иң борчыганы – телебезнең бетеп баруы. Без гомер буе татар мәктәбендә укыдык. Балаларны хәзер татарча укытмагач, алардан милли мәдәниятебезгә хезмәт итүче язучылар, журналистлар, сәнгать әһелләре чыкмаячак. Русча укыган бала татарча уйламаячак инде!.. Дөрес, өйдә татарча гына сөйләшергә кирәк, дибез, әмма бу мәсьәләне һич кенә дә хәл итмәячәк. Әлеге балалар милли җанлы булырга мөмкин, ләкин татар телендә ни шигырь, ни хикәя, гомумән, берни дә тудыра алырга сәләтле булмаячаклар. Бу проблема бездә генә түгел, башкортларда да шулай.

> «
> **Һәр төбәктә шул авылның үз кешесе җитәкче булырга тиеш. Шулар, инициатива күрсәтеп, авылны күтәрсеннәр һәм сакласыннар иде.**

Гомумән алганда, Россиянең күп төбәкләрендәге татар авыллары үрнәк булырлык, матур итеп яши. Самара, Пенза, Пермь, Киров һәм Оренбург өлкәләренә барсаң, күрәсең: татар авыллары зур, матур, халкы аек һәм эшчән. Бу авыллар, һичшиксез, яшәячәк! Аларның киләчәге өметле...

– Татар халкын, милләтне яшәтүдә сәнгатьнең ролен ничек бәялисез?

– Әйткәнемчә, Фән дустым белән 1992 нче елларда танышып, хезмәттәшлек итә башладык. Мин – инженер-механик. Татар җырын тәнкыйтьләр өчен берниндi махсус белемем юк. Әмма хәзер йөрәккә яткан, күңелгә үтеп керердәй җырлар бик аз. Эстрада күбрәк шоуга корылган. Концерттан кайткач, хатынымнан сорыйм: «Бу артистның берәр җыры исеңдә калдымы соң?» – дим. «Ю-у-ук! Киемнәрен алмаштыруы гына, сикерүе генә истә», – ди. Җырның иң беренче сүзе үк аңлашылырга тиеш. Сүзе күңелгә үтеп кергәч кенә, аның нәрсә турында икәнен беләсең. Мәгънә – сүздә. Сүзе булса, ул үзеннән-үзе көйне тартып чыгара... Җыр сүзе затлы, зәвыклы булырга тиеш! Хәзерге эстрада җырчыларын халык ярата, концертларына ашкынып баралар икән, димәк, бүген милләткә шул кирәк...

– Киләчәктә тарихта барыбер моңлы, тирән мәгънәле җырлар гына калачак. Тормыш җыр кебектер инде ул, сикәлтәле...

– Тормышта сикәлтәләр күп инде... Берничә мәртәбә үлемнән калдым. Аллаһы Тәгалә мине һәрвакыт яклап-саклап килде. Балачакта башым шешеп киткән, тын да алмый башлаганмын, иртәгесен, вафат булды дип уйлап, мине җирләргә уйлаганнар. Таң алдыннан шеш шартлап, эрен аккан да, айнып киткәнмен. Берзаман, машина белән бәрелгәч, каршыга очып чыкканмын да, алдагы машина чак туктарга өлгергән... Мин исән калганмын. Өченчесендә урманда агач астында калдым, аңымны җуйганмын, кабыргам сынган. Хастаханәдән чыккач, шул урынга барып карасам: бар җир типтигез, ә нәкъ мин яткан урында чокыр! Менә шулай үлемнән исән калу очраклары булды.

– Бу Сезгә Аллаһы Тәгаләнең бер кисәтүе һәм өндәве булгандыр инде. Түбәнкамада сугыш чоры хатын-кызларына куелган һәйкәл ачылышында булдык. Моны күреп, башкалар да шулай эшләсен иде дип уйлыйм. Бу һәйкәл янында үз әбиемне искә төшердем. Аллаһы Тәгалә Сезгә күбрәк игелекле эшләр башкарырга насыйп итсен.

– Адәм баласы рәхәт булган чакта түгел, ә менә авырлыклар килгәндә туган авылын искә төшерә торгандыр. Акчаң булмаса да, ялкауланмасаң, ара-

«Бабай утары» тарих-этнография комплексы күренешләре

кы эчмәсәң, эштән курыкмасаң, авыл җирендә менә дигән итеп яшәргә була. Нинди генә катлаулы вазгыять килеп туга карамастан, авыл илне туйдырган һәм туйдырачак. Бөек Ватан сугышын искә төшерегез. Инәкәйләрнең, тыл хезмәтчәннәренең Җиңүгә керткән өлеше бәһасез бит! Авыл кешесе сиңа һәм миңа мохтаҗ түгел. Киресенчә, без авыл халкына мохтаҗ! Өеңдә алтын өстендә ят, тик син экологик чиста ризыктан башка яши алмыйсың, тамакны туйдырырга кирәк! Син игенченең, терлекченең, җир кешесенең хезмәтенә мохтаҗ! Авыл – илне ризыкландыра алу сәләтенә ия урын, күренеш ул. Кешелек яшәгәндә, авыллар булачак.

Әмма авыл халкына кешелекле мөнәсәбәт булырга тиеш! Мин дәүләт сәясәте турында гына әйтмим. Күп очракта авылны читтән килеп аның җирләренә хуҗа булган кеше тарката. Ул кеше синең авылыңны, аның халкын, хуҗалыгын, рухи тормышын беркайчан да кайгыртмаячак. Кайчандыр гөрләп торган фермаларның җимерелүе, мал-туарның, техниканың очсыз бәядән сатылуы турында еш ишетәбез. Чөнки хуҗа, җитәкче читтән килгән... Кая гына барсам да: «Җир кем кулында?», «Авылга кем хуҗа?» – дип сорыйм. Әгәр дә читләр икән, иртәме-соңмы ул аны таркатачак. Чөнки аңа бу авылның, аның кешеләренең язмышы, киләчәге кирәк түгел. Һәр төбәктә шул авылның үз кешесе җитәкче булырга тиеш. Шулар, инициатива күрсәтеп, авылны күтәрсеннәр һәм сакласыннар иде. ■

Илкәем бар – дөньям түгәрәк!

19-20 һәм 21-22 август көннәрендә Татарстанның Азнакай районында һәм Башкортстанның Туймазы районындагы Төмәнәк авылында Төбәкне өйрәнүчеләр конференциясе булып узды. Фәнни җыен Ык буе авылларының тарихына, әдәбиятына һәм табигатенә багышланган иде.

Төмәнәккәем

***Фәнир Галимов** сүзләре һәм көе*

Сагынып кайттым ерак яклардан,
Төмәнәккәем, зәңгәр таңнарым,
Арыш басуың, назлы җилләрең,
Каршы алды мине тауларың.

Кушымта:
Төмәнәккәем, туган җиркәем,
Бик сагындым сине, нишләем?!.

Арымаем мин, йөгереп менсәм дә
Ак тавыңның биек ташына.
Урманнарыңда йөреп туймадым,
Карый-карый агач башына.
Кушымта.

Ялан тәпиле бала чагымдай,
Йөрим тагын инеш буенда.
Йөгерә-йөгерә таныш ташлардан
Чылтырап аккан көмеш суында.
Кушымта.

Фоторепортажны тулысынча beznenmiras.ru сайтыннан карарга мөмкин

Безнең мирас №10 октябрь 2020

Ислам дөньясы

Габдерәшит Ибраһимов

Принц Ито Хиробуми

«Япониягә исламият кермәгән, тик ислам тәгълиматларының барысы да японнарның табигатендә бар. Исламияттә нәрсә булса – шуларның һәммәсе дә бар японнарда.

Кабат Принц Ито белән күрешү

Беркөнне авылларда йөргәндә, Мори тирәсендәге болынны үтеп бара идем, почта ташучы, артымнан куып җитеп, бер телеграмма китереп бирде. Ачып укыдым: япон телендә. Телеграммалар, гадәттә, катакана хәрефләре белән языла. Укысам да, бик аңлап бетерә алмадым. Ито имзасын күргәч, чакыргандыр, ахры, дип уйладым. Шул ук көнне поездга утырып, туп-туры Принц Итоның бакчасына юл тоттым. Принц мине илтифат күрсәтеп каршы алды, чәй эчкәннән соң, арабызда шундый сөйләшү узды:

– Япониядә ничек бу дәрәҗәдә алга китеш булды? Конституция идарәсен төзүгә нәрсә этәрде? Бу хакта дөреслеккә туры килә торган мәгълүмат ала алсам, чиксез шат булыр идем. Сезнең вакытыгыз бик кыйммәтле, бушка үтүен теләмим, шуңа күрә әл-әһәм фә-л-әһәм, ягъни «әһәмиятлерәкнең әһәмиятлесе янында өстенлеге бар» дигән кагыйдәгә буйсынып, турыдан-туры бу хакта сүз башлавым өчен гафу үтенәм.

– Юк, болай дипломатларча сөйләшергә теләмим, минем бу юлы Сезнең белән бик үз итеп һәм бик озак сөйләшеп утырасым килә. Без әле бик күп тапкыр күрешербез, бу сорауларыгызга да җавап бирермен. Тик бу юлы, бер-беребезне тагын да якынрак таныр өчен, кайбер кереш сүзләргә вакыт бирсәк тә зыян булмас. Минем дә беләсем килгән кайбер нәрсәләр бар. Мәсәлән, Япония кебек ерак

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

җиргә Сезнең кебек олы яшьтәге кешенең, бу кадәр чыгымнар тотып, мәшәкатькә, юл азапларына түзеп килүениндидер бер Аурупа кешесенең Японияне күрергә килүенә һич кенә дә охшамаган. Сезнең, һичшиксез, бер тирән уегыз, бер киң планыгыз булырга тиеш. Иң элек менә шуларны бераз аңлауның минем өчен файдасы булмый калмас, Сезнең өчен дә әһәмиятле булачагы инкяр ителә алмас.

– Алайса мин Сезгә мәсьәләне бөтен нечкәлекләре белән сөйләп аңлатмасам, булмас. Вакытыгызны кызганмасагыз, җентекләп сөйләп бирермен.

– Теләгем дә шул: вакытларыбызны менә шундый мөһим сөйләшүләр белән үткәрик.

– Мин – Русиядә туып үскән татар кешесе. Динем – ислам. Бервакыт матбугат дөньясында да яшәп алдым. Безнең татарларның кимсетелгән милләт икәнлеген әйтеп, сөйләп торуның кирәгеН күрмим. Авыру кеше ни эзли – дәва, ә чирне яшерү – үлемне сайлау дигән сүз. Менә минем дә бу кадәр ерак һәм азаплы юлга чыгуны кирәкле күрүемнең максаты шул.

– Мин үзем дә шулай дип уйлаган идем. Тагын бераз ачыклый төшсәгез, нәтиҗәдә, авыруларыбыз берләшүе дә мөмкин. Бәлки, дәва өчен берәр чара табылыр. Сездә булган чирнең бер кисәгенең бездә дә булуы бар. Көнчыгыш халыкларында, раса йогынтысы булса кирәк, чирләрдә дә һәрвакыт бәйләнеш була.

– Безнең татарлар һәм, гомумән алганда, мөселманнар һәрвакыт берәр төрле басым астында көн итәләр. Бөтен Аурупа халыклары, Тәре вакыйгаларыннан соң, мөселманнарга мәңгелек дошман булдылар. Бу соңгы 20 ел эчендә Аурупа алып барган сәясәт тулысынча исламиятькә каршы. Аурупада Көнчыгыш мәсьәләсенең нидән гыйбарәт икәнен беләсездер. Гомумән, Көнчыгыш мәсьәләсе киңәя барган саен, раса мәсьәләсенең ишеге шакылган кебек, чирләребезнең берләшәчәге көн кебек ачык. Минем төп фикерем менә нәрсә: Аурупалыларның иң курыккан нәрсәләре – дин мәсьәләсе. Ислам диненең рухи көчен Аурупаның бөек фикер ияләре инде күптән аңлаганнар. Сәяси көчнең таянычы да – дин, дөресрәге, туптан, мылтыктан, һәртөрле сугыш корабларыннан да көчлерәк берәр нәрсә булса, ул – дин. Кораблар үзләреннән-үзләре хәрәкәт итә алмыйлар, туп, атылмаса, шартламый. Боларның экипажлары һәм олы җитәкчеләре дин хакына үзләрен фида итәләр, көймәләрне хәрәкәт иттерәләр. Менә шул көчне үз юлларында куллана алу өчен, аларга исламиятне һәрвакыт дошман итеп күрсәтәләр, иҗтимагый фикерне дә шул юлга этәрәләр. Бөтен бөек дәүләтләрнең фикере, сәясәте бу.

– Сезнең бу фикерегезнең кайбер җәһәтләрен тәнкыйть итсәм дә, аның мин кушылырга теләгән яклары да бик күп. Аурупа дипломатлары, чынлап та, динне гаять көчле корал итеп кабул итәләр һәм, чынлап та, сәясәт өлкәсендә дин кадәр, дөресрәге, ислам дине кадәр бөек көч юк. Әгәр госманлы төрекләре бу көчне куллана белсәләр, бөтен җиһанны дер селкетерләр иде. Бүгенге көндә Җир шарында курку белмәс сугышчан бер халык булса, бу – төрек-татар милләте. Госманлы хөкүмәте бу көчне тиешенчә куллана алса, галәм Ислам галәме булачак.

– Бүген төрек-татар милләте турында аерым бер карта ясалса, гаҗәеп манзара барлыкка килер иде. Бу кадәр зур халык, дин! Көнбатыш Кытай тулысынча керә, Урта Азия шулай ук, Азәрбайҗаннан Кече Азиягә кадәр сузылып китә. Шундый зур карта булачак ки, кәгазьгә бастырылып күрсәтелүе дә җитә, бар да бик яхшы аңлашылачак. Әле боларның уртак диндә булуларын күз алдына китереп карасаң, мондый көчкә каршы туплар, мылтыклар ни эшли ала?! Әле тагын шуны да өстәргә кирәк: Бенгалның күпчелек өлешендә татарлар яши, Пәнҗапның да бер өлешендә

татарлар[1] бар. Болар барысы да – мөселманнар. Мондый көчнең каршысына бернинди көч чыга алмас.

– Әле, яхшы, исемә төште: Сездән сорарга уйлаган идем. Миңа Төркиядән дини карта китерегез әле, зинһар. Бик рәхмәтле булырмын. Бик күптән тели идем. Мондый карта Токиода булырга тиеш.

– ИншәАллаһ, мин дусларга язармын, булса, җибәрерләр. Тик бармы икән андый карта?.. Булуы бераз шикле, ләкин шулай да язачакмын.

– Һичшиксез, булырга тиеш, чөнки Төркиянең яшәеш картасы ул. Безнең Япониягә исламият ничек керми калды икән? Мин менә шуңа бик гаҗәпләнәм. Моңа диңгез киртә булган дип уйлыйм.

– Япониягә исламият кермәгән, тик ислам тәгълиматларының барысы да японнарның табигатендә бар. Исламияттә нәрсә булса – шуларның һәммәсе дә бар японнарда.

– Шулаймы? Нәрсәләр бар соң, бик кызык?..

– Иң башта арулык – исламның төп кагыйдәләреннән берсе. Тугрылык, ышанычлылык, җиргә утыру, аннан соң хатын-кызларның ирләргә карата үз-үзләрен тотышы, тагын бик күп нәрсәләр японнарда гадәт булган, бездә болар – дин.

– Мин Сездән тагын бернәрсә сорарга телим: бу яңа Төркия турындагы фикерегез нинди? Кайбер Аурупа газеталары: *«Төркиянең элеккесе-яңасы – икесе дә бер, боларның мәмләкәт белән идарә итәр өчен сәләтләре юк...»*, – дип язалар. Әйе, нәкъ менә шулай диләр. Әлбәттә, Сез Төркиядә дә бик еш булгансыз, төрекләрнең сәләте турында да беләсездер.

– Аурупа халыклары һичбервакыт Төркиягә яхшылык теләмәсләр. Дөресен генә әйтим, гомумән, Көнчыгышның көчле булуын, алдынгы булуын теләмәсләр. Япон халкы руслар белән сугышта шанлы җиңү казанды. Япония үзенең һәр җәһәттән алга киткән мәмләкәт булуын күрсәтте. Шуңа да карамастан, Йокохамадагы Америка хәрби корабларының экипажы һәм матрослары шәһәрдә йөргәндә, кайда күрсәләр, шунда япон полициясе кешеләрен хурлыйлар, мин бу хәлне берничә тапкыр күрдем. Әмма шул ук кораб Петербургка яисә Гамбургка, Марсельгә барса, беркайчан да андый начар мөнәсәбәттә булмаячаклар.

– Һәр атна французларның сәүдә кораблары килә. Матрослары, шәһәргә чыгып йөргәндә, берәр япон мәйханәсенә керсәләр, әле һаман Франция байрагын эләргә тәкъдим итәләр. Шул ук кораб берәр Аурупа иле портына керсә, берәү дә андый тәкъдим ясамый. Менә Аурупа халкының бөтен Көнчыгышка карашы бу. Көчсезрәкләргә тагын да яманрак күз белән караячаклары шик тудырмый. Алар өчен, Көнчыгыш халкы никадәр көчсез булса, шулкадәр яхшырак. Мин Сезгә: «Ихтимал, чирләребез кайбер нокталарда берләшер», – дигән идем. Менә берләште дә. Моннан 15-16 ел элек бу матрослар җинаять эшләргә, кеше үтерергә мөмкин, безнең хөкем йортларыбызны танырга теләми торганнар иде. Хәзерге вакытта бераз каушадылар. 16 ел элек Италия гаскәре килгән иде. Йокохама тирәләрендә ауга чыкканнар. Берни ата алмаганнар, шул ачудан бер япон кешесен мылтыктан атып үтергәннәр. Япония хөкүмәте җинаятьчене бирүләрен таләп итсә дә, Италия бирмәде. Үтерелгән кешенең варисларын Италиягә чакырды, болар анда китә алмадылар, китсәләр дә, ни эшкә ярар иде. Ул вакытларда бөтен Аурупа кораблары Япония яр буйларында үз кануннарыннан башка канун танымыйлар иде.

[1] «Татар» атамасын Габдерәшит Ибраһимов биредә «төрки» мәгънәсендә кулланган булырга тиеш (тәрҗ. иск.).

– Менә шуннан Аурупаның Көнчыгышка нинди күз белән каравы аңлашыла да инде. Төркиягә дә нәкъ шундый ук ышанычсыз күз белән караулары бик табигый. Төркия никадәр яхшы идарә итсә итсен, Аурупа барыбер ышаныч белдермәс, хупламас.

– Әйе, без боларның тагын да ямьсезрәкләрен күрдек, кичердек. Моннан 40-50 ел элек, бәлки, әле аннан соң да безнең хәлебез Төркиянең бүгенге хәле кебек иде. Ил эчендә һәр тарафта фетнә, тыштан: Аурупа – бер яктан, Америка икенче яктан көчле янаулар астында тотасылар иде. Бәрәкәт бирсен, географик урнашуыбыз безгә бераз ярдәм итте. Чит илләр тыкшынуына урын калдырмыйча, тиз генә үзебезне кулга алдык. Төркия исә тагын да кыенрак хәлдә, бөтен яктан дошман сарган һәм эчкә дә үтеп кергән. Шулай булгач, Төркиянең хәле тагын да мөшкелрәк. Мәмләкәтне үзгәртеп кору өчен чит илләрнең күзәтүенә һәм киңәшенә мохтаҗ. Ә алар исә үз мәнфәгатьләрен – Төркиянең җимерелүен алга сөрәләр. Бик кызганам, чөнки болар үз башыбыздан үтте. Утыз ел элек мәмләкәтебезгә гаять зур куркыныч яный, чит илләр төрле яклап тыкшынырга маташалар иде. Төнлә йоклый алмадык, көндез ашарга вакыт таба алмадык, гел киңәш-табыш иттек. Безнең Кутай[2] бик гайрәтле кеше. Кайчак төнлә дә тынычлыкта калдырмый, эшләтә иде. Нәтиҗәдә, берничә ай киңәшкәннән соң, карар кабул иттек. Ул карарның кыскача эчтәлеген сөйләп үтәргә телим.

Япониядә реформа

(Принц Итоның сөйләгәннәре буенча)

«Башта мәмләкәт эченә дин әһелләрен җибәрдек. Бу кешеләрнең үзләрен ике ай буе әзерләгән идек. Болар бөтен өлкәләрне гизделәр, бер авылдан икенче авылга йөрделәр. Берсе китте, икенчесе килде. Шул рәвешле, вәгазь сөйләп, нәсыйхәт биреп, нәкъ өч ел гизделәр. Иң зур рольне бу кешеләр башкарды. Иң мөһим вазыйфа шул кешеләрнең вазыйфасы иде. Болар милләткә ниятне, нишләргә кирәклеген күрсәттеләр. Шулай эшләмәгән очракта, Ватанның куркыныч астында калачагын аңлаттылар. Мәмләкәтнең киләчәген саклау өчен, һәркем үз вазыйфасын башкарырга тиеш. Конституция идарәсенең ни икәнен ачыклап, милләткә төшендерделәр.

Мин дә, аерым делегация эчендә, төп кануннарны өйрәнү өчен, Аурупага киттем. Без, биш кеше, зур, кечкенә – бөтен Аурупа хөкүмәтләренең идарә ысулларын өйрәндек. Яхшы якларын анализладык, кимчелекле якларын тәнкыйть итеп, шунда ук япон теленә тәрҗемә итеп, бастырып бардык. Бу эштә минем вазыйфам бик авыр иде. Безнең Кутай (Микадо) болай дип әйтә иде: «Бу – төп канун, ул – бөтен мәмләкәтнең яшәеше. Ул бары тик Аурупаны кабатлау, аңа иярү генә булмаячак, милләтнең табигатенә һәм әхлагына туры китерелергә тиеш. Биредә бөтен җаваплылык синең өстеңдә, мәмләкәтнең яшәешен синең вөҗданыңа тапшырдым, һәрнәрсәгә син җавап бирәсең...»

Аурупада нәкъ өч ел яшәдем. Илгә кире кайткач та, биш ел буе бу җыелган мәгълүматны тәртипкә салдым. Моннан соң, сайлау ысулының нидән гыйбарәт икәнен һәм сайлау тәртибен эштә күрсәтү өчен, мәмләкәт эченә кешеләр җибәрдек. Болар бөтен өлкәләрне, калаларны гизделәр. Аннары һәр каладан авылларга кешеләр җибәрелде. Шул рәвешле бик күп эш эшләнде.

---

[2] Японнар Микадога, «Кутай», диләр, гади халык исә, «Тенси», ди (Габдерәшит Ибраһимов искәрмәсе).

Токио. ХХ гасыр башы

Моннан тыш, төрле илләргә укырга ике йөз яшь кеше җибәрдек. Бер фәнни юнәлешкә егерме кеше билгеләп, боларга үз фәнни өлкәләрендә белгеч булырга, белем һәм осталык казанырга кушылды. Менә шул рәвешле эш алып бардык. Әлбәттә, бик авыр булды, әмма, нәтиҗәдә, искиткеч уңышларга ирештек.

Иң авыр мәсьәлә – финанс учреждениеләре белән идарә ысулын тәэмин итү иде. Боларның кешесе юк иде, акчасы юк иде. Төркиядә кешесе табылыр дип өмет итәм, чөнки ничә йөз еллар Аурупаның уртасында яши, Аурупа идарәсен күреп тора. Бездә кеше юк. Конституция идарәсен төзү һәм тәртипкә салу өчен генә дә җиде-сигез ел кирәк булды.

Биш ел буе бай кешеләргә һәм сәүдәгәрләргә, үзләренең киң күңеллелек белән биргән ризалыклары буенча, бик зур салымнар салынды. Мәмләкәтнең алдынгы кешеләре һәм зур түрәләре дә өч ел буе хезмәт хакларының яртысын казнага калдырып бардылар. Менә шундый еллар, яр буйларына чит ил кораблары килеп туктый торган иде. Почта корабларының матрослары һәм юлчылары безне төрлечә хурлыйлар, кимсетәләр иде. Без тавыш чыгармадык. Хәтта хатын-кызларыбызны да көчләделәр. Алар никадәр җәберләсәләр, без шулкадәр күз йома идек. Инде шөкер, Кутай Саманың [Император Микадоның] тырышлыгы белән, мәмләкәтебезнең киләчәге тәэмин ителде».

Боларны сөйләп биргәч, Принц Ито:

– Хәзергә мин Сезгә менә шулкадәр мәгълүмат бирә алам. Тәфсилләп сөйләсәм, әллә ничә том китап булыр иде, – диде. Аннан соң миннән: – Инде Сезгә сорау бирергә телим. Хәзерге көндә [12 март] Төркиядә инкыйлаб (революция) тәмамланды, тотрыклылык тәэмин ителеп, эшкә керешелдеме? – дип сорады.

– Мин алай дип уйламыйм. Безнең татарларда бер сүз бар: «Корбан чалынмыйча, бәйрәм булмый», – диләр. Моның белән генә инкыйлаб тәмам була алырмы? Боларына минем дә акылым ирешми.

– Мин дә бик аптырадым. Дөресе генә, әгәр дә алай гына эшләрен җайга сала алсалар, хуплауга лаек булачаклар.

– Карарбыз, бер елны бу рәвешле үткәрә алсалар, аннан соң эчке тотрыклылык ничек булачагы аңлашылыр. Әлегә фетнәләр ахыргача бетмәгән.

Принц Итоның исламият хакындагы фикере

– Безнең исламият турында мәгълүматыбыз бик аз, кызганыч ки, күршебездә Маньчжурия мөселманнары яши торып, ничек булгандыр, безнең японнар ул якка тартылмаганнар. Әгәр 30-40 ел элек Сезнең кебек кешеләр килгән булса, бу өлкәдә бик зур алга китеш булыр иде. Христианлык килеп караса да, уңышка ирешә алмады. Миссионерларының һәрвакыт сәяси фикер артыннан барулары сәбәпче булгандыр дип уйлыйм. Бик күп акча туздырсалар да, уңышлары аңа күрә түгел. Гомумән, христианлыкны кабул иткән кешеләр түбән катлау кешеләре арасыннан, затлы гаилә кешеләре арасында христианлыкны кабул итүчеләр бик сирәк очрый. Исламият күбесенчә Көнчыгыш милләтләре арасында таралган. Шуның белән бәйле рәвештә уйлап куйдым: ул безнең японнар арасында җиңелрәк тарала алыр иде. Тик менә *теаддүд-и зәүҗат* [бердән күбрәк хатынга өйләнү] мәсьәләсе белән килешә алырлармы икән? Ихтимал, бу мәсьәлә бераз каршылык тудырачак. Безнең японнарда бер тапкырдан артык өйләнү бик сирәк күренеш. Шулай да бар, бер дә юк түгел.

– Исламият *теаддүд-и зәүҗат*тан гыйбарәт түгел, хәтта араларында ниндидер бер бәйләнеш бар дип тә әйтеп булмый. Ник дигәндә, исламиятнең таләпләре арасында түгел. Исламият бик саф дин. Иң кыска гыйбарә белән белдерергә теләсәк, болай дип әйтә алабыз: исламият ул тәүхид [Аллаһтан башка илаһи көч булмауга ышану] белән гүзәл әхлактан гыйбарәт.

– Исламият нигезләре турында миңа, рәхим итеп, бераз мәгълүмат бирә алмассызмы икән? Гомумән дә, бу минем уйларымның берсе иде.

– Исламият Сезгә әле генә әйтеп күрсәткәнем кебек: бу дөньяны бар итеп, аны хәрәкәткә китерүче булырга тиеш һәм, әлбәттә, бар. Бары тик табигатьнең тәэсире белән генә аңлатып булмый моны. Без ул хәрәкәткә китерүченең асылын дөрес аңлауда гаҗиз калачакбыз, чөнки ул кешелек акылыннан да өстенрәк тора. Бу сәбәп белән мөгаллимнәргә ихтыяҗ соралган. Болар – бөек пәйгамбәрләр, рәсүлләр. Алар гүзәл әхлакны һәм гомуми ышанычны тәэмин итә торган илаһи кануннарны өйрәткәннәр. Менә боларны тану исламият була. Моның асылы ике сүз белән белдерелә: «Ләә иләһә иллаллаһ Мөхәммәдун рәсүлуллаһ» [Аллаһтан башка илаһ юк, Мөхәммәт – Аллаһның рәсүле] сүзләре.

– Ничек дидегез, акрын-акрын тагын бер тапкыр әйтегезче.

Мин кәлимә-и тәүхидне [*Ләә иләһә иллаллаһ Мөхәммәдун рәсүлуллаһ*] акрын-акрын өч тапкыр әйттем. Принц Ито да бу гүзәл сүзләрне минем артымнан кабатлады. Аннары мин болай дидем:

– Менә шул сүзләрнең мәгънәсен раслап, кабул итсәгез, Сезгә мөселман дип әйтәләр, Сез шул мизгелдән башлап мөселман буласыз. Мөселманлыкның бар булганы менә шуннан гыйбарәт.

– Гаҗәп нәрсә! Мин биредә кабул итмәслек, расламаслык берни дә күрмим. Бу бик хуш килә күңелгә.

Мин бу мөхтәрәм заттан моннан соң бу сүзләргә каршы төшкән берни дә ишетмәдем. Ул көнне шул рәвешле сөйләшүебезне тәмамлаган идек. Әлбәттә, арабызда барган әңгәмә бер дә кимчелексез теркәп куела алмый, ләкин төп мәгънәсе менә шулардан гыйбарәт иде. Моннан соңгы күрешүләрдә дә ни хакында сөйләшүләребез барысы да тәртибе белән теркәп барылган.

Төрекчәдән ***Асия Рәхимова*** *тәрҗемәсе* ■

Мөһаҗирлектәге татар китабы

Фин илендә Кәрәкәшле кызы

Хатыйп Миңнегулов, филология фәннәре докторы

Гәүһәр Туганай кызлары Хәтфә һәм Гүзәл белән

Гәүһәр Туганай шигырьләрендә туган төбәгенең гореф-гадәтләре, шөгыль һәм яшәү рәвешләре дә гәүдәләнеш тапкан.

Кәрәкәшле кызы әсәрләрендә туган як, бала һәм үсмерчак хатирәләре зур урынны били. Әмма аның иҗаты алар белән генә чикләнми. Шагыйрәнең тугыз дистәгә диярлек сузылган гомер юлының иң зур өлеше иленнән читтә – Финляндиядә уза. Биредә ул балигъльык яшенә керә, гаилә кора, балалар үстерә, эшли, кешеләргә, бигрәк тә үз халкына булдыра алган кадәр хезмәт күрсәтә. Шунда ук бакый дөньяга да китеп бара. Мондый чынбарлык, яшәешнең реаль вазгыяте, әлбәттә, аның иҗатына да сизелерлек йогынты ясый. Шагыйрә, гомумән, табигать, ел фасыллары, аларга хас сыйфатлар турында язарга ярата. Аның аерым шигырьләрендә Финляндиянең урман-сулары, кош-кортлары, озакка сузылган карлы, «кара» кышлары хакында шактый юллар бар:

...Финляндиядә шулай инде, җәйне көтеп гомер үтә,
Елы көнгә туеп булмый – өч айдан җәй үтеп китә. (14 б.)

Ахыры. Башы журналның 9 нчы (2020) санында.

Гәүһәр Туганай Суомидагы тормышның көйле, халкының тырыш, эшчән булуын да искәртә. Мәгълүм ки, әлеге мәмләкәттә милләттәшләребезгә шактый уңай мөнәсәбәт урнашкан. Бу хакта Кәрәкәшле кызы да язып үтә:

...Рәхмәт төшсен бу милләткә: безне яхшы тоталар,
Кимсетмичә, тигез карап, бөек хөрмәт итәләр.
Фин халкы инсаниятле, исеме танулы, мәшһүр,
*Меңләрчә тәшәккер (рәхмәт. – **Х.М.**) белән рәхәт яшибез,*
*мәсрур (шат. – **Х.М.**). (73 б.)*

Әмма матди яктан ничек кенә мул, «рәхәт» яшәсә дә, мөстәкыйль дәүләте булмаган халыкка, бигрәк тә чит мәмләкәтләрдә гомер кичерүче кавемнәргә үзләренең телмоңнарын, гореф-гадәтләрен саклау һәм киләчәк буыннарга тапшыру гаять кыен… Монда төп шартларның бик мөһиме булып халыкның бердәмлеге тора. Мөһаҗәрәттәге башка каләм әһелләре кебек, Гәүһәр апабыз да бу мәсьәләгә кат-кат басым ясый:

Бер-береңдән аерылмый дусча бергә берләшик,
Бергә татлы сүзләр сөйләп, күгәрчендәй гөрләшик.
Бергә уйнап, бергә көлсәк, бергә җырлап, бергә торсак, –
Ахырда үкенмәбез, авырлыклар күрмәбез. (84 б.)

...Фин илендә торабыз – әз монда безнең халык.
Көч куеп тырышабыз, тормаска артка калып.
Кирәк бергә яшәргә, таралмыйча бер булып.
Аерылмыйча яшәсәк – капламас кара болыт. (54 б.)

Билгеле ки, дәүләтчелеген җуйган халкыбыз коточкыч колониаль изелү елларында да, зур югалтулар бәрабәренә булса да, үзенең телен, милли барлыгын саклап, киләчәк буыннарга тапшыра килгән. Бу юлда аның даими һәм ышанычлы юлдашы, таянычы ислам дине булган. Әлеге тарихи тәҗрибәне, реаль хакыйкатьне тирәнтен аңлаган шагыйрә дә кавемдәшләрен иманлы булырга чакыра, Ураза һәм Корбан бәйрәмнәре уңае белән махсус шигырьләр дә иҗат итә. Автор өчен дин, тел, миллият – аерылмас төшенчәләр.

> **«Дәүләтчелеген җуйган халкыбыз коточкыч колониаль изелү елларында да, зур югалтулар бәрабәренә булса да, үзенең телен, милли барлыгын саклап, киләчәк буыннарга тапшыра килгән.**

Узган гасыр урталарында Финляндиядә яшәүче, болай да оешып, бердәм булып җитмәгән милләттәшләребез арасында төрекчелек хәрәкәте, Истанбулга йөз тоту көчәя. Хәтта төрек телендәге басмалар да дөнья күрә. Әмма күпчелек, Төркиягә, төреккә һич тә каршы килмичә, үзенең элек-электән килгән милли барлыгын сакларга омтыла. Гомәр ага Таһир оештырган «Тукай җәмгыяте» бу юнәлештә нәтиҗәле генә эшли. Хәсән ага Хәмидулла халкыбызның тарихын яктырткан хезмәтләр яза, милли рухлы шигырьләр иҗат итә. Мондый милләтпәрвәрләр арасында Гәүһәр Туганай да бар. Аның берничә әсәре турыдан-туры шушы бәхәскә бәйле:

Берсе әйтә: «Татар түгел, мин – төрек», – ди.
Икенчесе ди: «мин – татар, – сөйлисең ни?» (22 б.)

Башка күп кенә татар зыялылары кебек, Кәрәкәшле кызы да Истанбулны, төрекләрне якын-үз итә, зурлый, укучыларын да бу халыкка дустанә карарга чакыра. Әмма бер үк вакытта, тарихи хакыйкатькә тугры калып, татарлыкны да кискен яклап

чыга. Строфаларының төгәлләнеше белән Шәмседдин Зәкинең (1821-1865) «булгай-булмагай» шигырен хәтерләткән парчасында (1962) Гәүһәр Туганай болай ди:

Һичбер заман татар төрек булмай-булмай,
Ул юл белән киткән эшләр уңмай-уңмай.
Шивә башка – туган телгә килмәй-килмәй,
Халкыбызның күңеленә сеңмәй-сеңмәй... (29 б.)

«Төрек-татар» мәсьәләсе «Татар без!» шигыренең дә (28 б.) төп мотивы. Менә андагы аерым юллар: «*Әллә нәрсә дисәләр дә, татар булгач – татар без», «Бездә бар да бар» («сүзе» дә, «көе» дә, «җыры» да).*

...Туган телебез булып торсын, төрекчәне дә өйрән,
Фин кызларына өйләнми, татар кызына өйлән.
Кияүләр дә татар булсын, татар белән зал тулсын,
Төрек кардәшләребез дә хөрмәтле кунак булсын.

Шагыйрәнең «Дәрдләрем», «Милләтем», «Татар», «Идел суы» һәм кайбер башка әсәрләрендә дә татар тематикасы шактый тулы яктыртыла. Автор фикеренчә, халкыбыз уңган-булган, озын тарихлы («Татарлыкны әзсенмәгез, татар – Чыңгыз баласы»; аның «теле матур», җыр-көе моңлы). Урыны белән, мөгаен, артык яратканга, үз халкын тәнкыйтьләп тә ала. Идел, Казан – Кәрәкәшле кызының төп кыйбласы.

Мөһаҗәрәттәге милли әдәбиятыбызда «Татарстан» атамасы, аның белән бәйләнешле тематика сирәк очрый. Татар дөньясы, элеккеге тарихка нисбәттән, киң планда карала, еш кына «Идел-йорт», «Идел-Урал», «Казан» төшенчәләре рәвешендә күзаллана. Гәүһәр Туганай исә бу юнәлештә кыю гына эш итә. Аның хәтта республикабызга багышланган махсус әсәре дә бар. Ул «Бүгенге Татарстан» дип атала (42-43 б.). 1966 елда иҗат ителгән бу шигырьне җөмһүриятебезнең билгеле бер дәрәҗәдә идеаллаштырылган картинасы дип тә атарга мөмкин. Анда муллык, алга китеш, тәртип, рәхәтлек...; «мәктәпләр гөрләп тора – бар да татар телендә»... Автор Татарстанны «зур гөлбостан» белән тиңли. Элеккеге әдәбиятта касыйдә, мәдхия жанрлары бик актив кулланыла. Аларда, гадәттә, авторлар үзләре күрергә теләгәнне бар, булган рәвешендә тасвирларга ярата. Кәрәкәшле кызы да билгеле бер дәрәҗәдә шул традицияне дәвам иттерә. Әмма аның шигырендәге төп төшенчә-сурәтләр реаль чынбарлыктан артык ерак китми. 2020 елда Татарстанның төзелүенә 100 ел тулды. Аның тарихы, үткән юлы хакында сүз барганда, Кәрәкәшле кызының да бу шигыре бер гыйбрәтле мисал була ала.

XX гасырда мөһаҗәрәттә иҗат ителгән күп кенә язмаларда илдәге хакимиятне, Кремльне, совет системасын тәнкыйтьләү очрый. Гәүһәр Туганай иҗатында исә мондый хәл күзәтелми.

* * *

Вәзен-кафиядә, поэтик стильдә, сүз-гыйбарәләр сайланышында аерым төгәлсезлекләр, бәхәсле яклар булуга да карамастан, Гәүһәр Туганай иҗаты мөһаҗирлек әдәбиятында гына түгел, ә гомумән, татар сүз сәнгатендә дә билгеле бер игътибарга лаек. Ул – татар мәнфәгатьләре өчен көрәшүче чын милли шагыйрә. Аның уй-кичерешләре, сагыну-сагышлары укучыларны битараф калдырырлык түгел. Шунысын да искә төшерик: соңгы берничә дистә елда илдән китеп, чит мәмләкәтләрдә яшәүче милләттәшләребез шактый. Әмма, ни кызганыч, алар арасында Сания Гыйффәт, Хөсәен Габдүш, Әхмәд Гәрәй, Гәүһәр Туганай... кебек татарым, телем, моңым дип янучылар, фидакярләрчә тырышучылар бик аз шул. Рөстәм Сүлти, Чулпан Зарифтан... кала, татарча иҗат итүчеләр бөтенләй юк диярлек.

Гәүһәр һәм Хәким Туганайлар

Гәүһәр Туганайның «Иртә чиркәү кыңгыравы тәэсире астында» баш исеме белән 1968 елның 6 декабрендә язылган бер шигыре бар (96 б.):

Чит илдә яшәве җайсыз,
Торам гүя ярты җансыз.
Кая барсам да, ят тоям,
Бу әрнүне язып куям.
Иртәдән үк кага чиркәү.
Күңел белән без тик икәү.
Туганлар, туган ил калган,
Язмышны белмисең алдан.
Көн-төн үз (ул. – ***Х.М.****) илне сагынам,*
Сары яфракдай саргаям,
Канатсыз кош кебек яшим,
Итләрен мәҗбүрдән ашыйм.
Ничек аңлатырлык әйтим,
Сизәм үземне гел ятим.
Сагынам моңлы азанны,
Моңайган шәһрем Казанны.
Йөрәк төптән сагынмасам,
Бу сүзләрне язаммы?!.

Игътибар итегез: бу юлларны бит чит илдә ярты гасырдан артык яшәгән, шунда гаилә корган, балалар үстергән, тамырланган, мул тормышлы кеше яза! Никадәр әрнү-сагыш, никадәр сагыну-юксыну!.. ■

Гәүһәр Туганай шигырьләре

«Безнең мирас» журналын укучыларга Гәүһәр Туганайның аерым шигырьләрен тәкъдим итәбез. Аларны сайлап алу шактый кыен, шартлы булды. Чөнки җыентыктагы 100ләп шигырьнең һәрберсенең үз кыйммәте бар. Бәлкем, киләчәктә Кәрәкәшле кызының махсус шигырьләр җыентыгын әзерләп бастыручы булыр. Ютазылы-баулылар үз якташларын ни дәрәҗәдә беләләр, Гәүһәр апаларын ни рәвешле искә алалар икән – күңелдә бу төр сораулар да туып тора.

БИЮ ҖЫРЫ

Әйдәгез, биегез, уйный бию көебез,
Кадерле милли биюне җанландырып биегез.
Биегез, биегез, белмәгәнгә карамый,
Матур биюләребезне онытырга ярамый.
Биегез, биегез милли бию көенә,
Башка биюләрдән өстен бик килешле күренә.
Яшь җегетләр, яшь кызлар, көчәйтегез берлекне,
Ялгыш юлларга китеп, ташламагыз үзлекне.
Бергә уйнап, бергә көлеп, ничек матур биисез,
Вальс, танго күңеллерәк, иске бию, димисез.
Яшьләр, картлар бергә утырып, милли ашлар ашыйбыз,
Шулай һаман бергә булсак, югалмыйбыз, яшибез! (4 б.)
9.03.1959

ДӨНЬЯ КӨТҮ

Төрле михнәт белән кичә дөнья тормышы,
Бәндәләрен сынар өчен Ходай кормышы.
Күпме тынычсыз булса да, туйдырмый ул,
Үлемне теләмисең, яшисең килә гел.
Төрле хәсрәт эчендә ныкката башлар,
Нәфсең сүнә, бугазыңдан үтми ашлар,
Туктамасдан ага күздән ачы яшьләр.
Кинәт яшь-яшь агара кап-кара чәчләр.
Егламаганын да дөнья елата ул,
Уйламаган кешене дә уйлата ул.
Кеше өмид белән бәхетле көн көтә,
Булган бәхетле көннәрен сизми үтә.

Менә шулай яшен кебек яшьлек китә,
Сыкрандыра торган картлык килеп җитә.
Хак дигәнчә һәр авырга сабыр кирәк,
Әмма бәгъзән сабыр итүчеләр сирәк.
Динле булсаң, күп хәтәрдән котыласың,
Чын сәламәт булсаң һәм чыдаса йөрәк. (13-14 б.)
30.08.1962

ТАТАР БЕЗ!

Әллә нәрсә дисәләр дә, татар булгач – татар без,
Итләр, майлар бәһаирсә дә, пәрәмәч ашап ятабыз.
Кыш көнендә соңламыйча майлы каз тутырабыз,
*Җәй буена казы ашап шәп үкде (уңды. – **Х.М.**) дип утырабыз.*
Нигә безгә: «Татар түгел, төрек мин», – дип сөйләргә,
Матур көйләр бар чагында, төрек көен көйләргә?!
Хәрефе дә бар, сүзе дә күп, көе дә бар, җыр да күп.
«Бездә берни юк», – дип йөрсә, укымаган бер бөртек.
Болар бар да читтә туган – телне яхшы белмиләр,
Бездә бар да бар дисәң дә, колакка да элмиләр.
...Аңгыра башлы булмаганы татарлыкны ташламас,
Татар телен якка куеп, төрекчә укый башламас.
Туган телебез булып торсын, төрекчәне дә өйрән,
Фин кызларына өйләнми, татар кызына өйлән.
Кияүләр дә татар булып, татар белән зал тулсын,
Төрек кардәшләребез дә хөрмәтле кунак булсын. (28 б.)
24.03.1966

ТОРМЫШЫМ

Бала чагымдан ук дөньяны күп гиздем,
Шатлык көнләре дә булды, ачы хәсрәткә дә түздем.
Дөньяда мин генә түгел, хәсрәтле күп,
Сабыр итмәсәң, һәр көнне күз яше түк.
Шулай төрлечә кичә бу дөнья тормышы,
Әби-бабайлар да шулай бер юлдан йөрмеше.
Тормыш көнләрендә була төрле-төрле,
Бәгъзән шадлыкда яшисең гөрли-гөрли.
Һава да бер көйгә тормый – ничә төрле:
Кайчак кара болытлы, буранлы, карлы.
Бу хәлләргә түзеп торсак – көн ачыла,
Болытлар таралып, нурлы кояш чыга. (66 б.)
11.04.1967

Шигырьләрне журналга филология фәннәре докторы,
*профессор **Хатыйп Миңнегулов** әзерләде.* ■

Шайтанлы чишмәсе буенда

Гази Кашшаф

Рәсемдә (сулдан уңга): Мостай Кәрим, Гази Кашшаф һәм Хәсән Туфан

Шайтанлы чишмәсе буенда безнең авылны дүрт яктан да таулар саклап, салкын җилләрдән ышыклап тора. Кышларын буран күмеп китә торган тау астындагы нәни авыл миңа һәрвакыт тау башында балкый кебек тоела һәм нурларын да тирә-якка, еракка чәчә төсле. Мин аны кечкенәдән үк бик ярата идем һәм Тукайның шигырен үзебезнең авылга карата язылган дип исәпләп, абый белән җырлап йөри идек:

Тау башына салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул...

Тау күкрәген тишеп чыккан чишмәләр бездә берәү генә түгел, ләкин бөтен авыл Шайтанлы чишмәсен яратарак бирә, аның суын шифалырак дип таба, Тукай да безгә шул турыда җырлагандыр кебек була.

Хәмит машинасын бик кызу алып бара. Ул олы юлны гына түгел, авыл араларындагы басу юлларын да яхшы белә — турыдан гына элдерә.

Горком секретареның:

— Аннан юл бармы соң? — дигән соравына:

— Табабыз! — дип кенә җавап бирә.

Без, Кандраны, Кандра күлен сулъякта калдырып, үрләрдән генә чабабыз. Бер сәгать тә вакыт узмый, «XXI партсъезд» исемендәге колхоз правлениесенең кояш нурлары белән балкыган якты, җылы идарәсенә килеп керәбез.

Председательнең пөхтә, ләкин кәгазьләргә күмелгән өстәленә аркылы озын өстәл сузганнар. Кызыл материя белән ябылган бу өстәлдә бер өем газета-журналлар тора, мине нәкъ шул өем алдына китереп утырттылар. Сизеп торам, янәсе, күр, без аю өнендә яшәмибез, сезнең язганнарны күзәтеп торабыз.

Иң өстә «Казан утлары»ның соңгы саны, «Азат хатын», «Ялкын», «Агыйдел», «Башкорт кызы» журналлары — барысы да әле яңа һәм таушалмаган. «Кызыл таң» һәм «Совет Башкортстаны» газеталары...

— Барысын да укыйбыз! — диде партком секретаре Аскаров.

— Безнең колхозда ике китапханә, анда 20 меңләп китап бар, — ди кемдер. — Алардан тыш ике мәктәп китапханәсе...

Таныша башлау китап турында сөйләшүдән ялганып китте.

— Халык бик күп укый бит хәзер. Китап җиткереп булмый. Безнең авыл советы бюджеты ел саен китап алу өчен 200 сум билгели. Әмма сәүдә оешмалары китапларны без сораган вакытта һәм кирәк кадәр җибәрми.

Моны авыл советы председателе Әюпов иптәш әйтте. Марк Семенович аның сүзен куәтләде:

— Ана телендә китап җитми. Кыска пьесаларга бик сусыйбыз!..

Гази Кашшаф – Миргази Солтан улы Кашшафетдинов (1907-1975) – әдәбият галиме, тәнкыйтьче. Хәзерге Туймазы районының Яңа Арсланбәк авылында туган. 1950-1958 нче елларда – «Совет әдәбияты» журналының баш мөхәррире, 1960-1975 нче елларда – КДУ укытучысы. Хезмәт Кызыл Байрагы (1957) ордены иясе. Ул илленче еллардан башлап бөтен гомерен герой-шагыйрь Муса Җәлилнең тормышын һәм иҗатын өйрәнүгә багышлый. «Моабит дәфтәрләре»нә иң беренче гыйльми комментарийлар яза.

Игътибарыгызга әдипнең «Башкортстанда» дип аталган юльязмасыннан бер бүлек тәкъдим итәбез. Анда сүз Башкортстан Республикасының Сәйрән һәм Яңа Арысланбәк авыллары турында бара.

— Эш зурдан китте, танышып бетик әле, — диде Фатих Дәүләтшин.

Монда колхозның җитәкчеләре — элекке фронтовиклар җыелган иде.

Менә минем кордаш Зәйнулла Хәмидуллин, ул инде олыгайган, калынайган, чәчләре дә чаларган, шулай да йөзе түгәрәк һәм яшьләрчә шома, матур, сөйкемле.

Без аерылганнан соң, аның башыннан ниләр генә узмаган. 1933 елда ул «Үрнәк» колхозы председателе булып эшләгән, аннан партиянең район комитетында инструктор, балык заводы директоры, шуннан соң армия... 1945 елда фронттан кайткач, «Фрунзе» исемендәге колхозга председатель итеп сайлыйлар. Колхозлар эреләндерелә, Зәйнулла председатель булып сайлана.

— Хәрби биографиягезне дә сөйләп бирсәгез иде! — дим мин.

Зәйнулла бераз уңайсызланамы, мактану дип аңламасыннар дип уйлыймы, бик коры гына, анкета тутырган кебек, белешмәләр әйтә. Ярый әле янәшәдә шәһәр комитеты секретаре тора. Марк Семенович аның өчен сөйләп, кайбер детальләр белән «анкета»ны җанландыра.

I дәрәҗә Ватан сугышы ордены һәм медальләр белән бүләкләнгән Зәйнулла. Ерак Көнчыгышта да, II Балтыйк буе, II Украина фронтларында да көрәшкән. Берничә кат яраланган. Немец снайпере аның күкрәгенә пуля җибәргән, пуля, партбилетын тишеп, тәненә кергән. Зәйнулла госпитальда озак дәваланган, яңадан стройга баскан.

— Ул партбилет бармы әле? — дим мин.

— Юк, алыштырдылар…

Бөек Ватан сугышы архивында дошман пулясы тишеп узган партбилет, бәлки, саклангандыр!

Венгриядә сугыш барганда, Зәйнулла тагын яралана, ләкин стройдан чыкмый, үзенең пулемет взводы белән алга һөҗүм итә. Чехословакиядә Брно шәһәрен фашистлардан азат иткәндә өченче тапкыр яралана…

Җитез хәрәкәтле, интеллигентлыгы сүзеннән дә, эшеннән дә сизелеп торган элеккеге солдат Әкрәм Әюпов 1947 елдан бирле авыл советы председателе булып эшли икән. Егерме елдан артык җирле советта сайланып эшләү — үзе яхшы характеристика. Димәк, сайлаучылар аның эшен яраталар, ә ул сайлаучыларның ихтыяҗларын яхшы белә.

Колхоз коммунистларының җитәкчесе Әхнәф Аскаров та фронт утларын кичкән егет булып чыкты.

Минем янда утырган Фатихның әтисе — Салих Дәүләтшин, мәсәлән, беренче коммунистлардан иде. Волостька, өязгә бик күп көрәшчеләр бирде ул ячейка. Хәзер дә аның сафларында чыныккан коммунистлар тирә-якта гадел хезмәт итәләр. Алар көче белән авыл яңарган, бәхетле юлга баскан. Озын булган бу юл, ай, озын!

Аның озынлыгы авылның тарихы белән үлчәнә. Ачылы күл буенда бер Каңлы башкорты Сорурбикә исемле кызын Арсланбәк исемле батыр егеткә кияүгә биргән.

Кызның бирнәсенә җир бүләк иткән. Бабай белән кияү ат менеп чыкканнар да тау башыннан тау башына күчә-күчә җир бүлгәннәр. Бабай тиешле кеше, камчысы белән ишарәләп, ерактагы тау сыртларына күрсәткән:

— Әнә сезгә җир шул таудан монавы тауга чаклы, тегесеннән шушысына кадәр!

Җәй буе йөреп чыга алмаслык урманлык, болынлык, тау-ташлык җирләрне бабай җиңел генә бүлгән. Арсланбәк, чибәр кәләшне алып, шул җирдән үзенә урын сайлаган. Артта бабай тора, йозак нык дип уйлаган, күрәсең, ул, Кандра күлгә таба килеп, дүрт яктан да тау ышыклап торган иңкү урынны сайлап, өй салып утырган.

Тырыш кеше булган Арсланбәк. Ләкин коры кул белән ул чаклы җирне эшкәртү — мөмкин булмаган эш. Табигать бүләк иткән байлык белән генә дә яшисе килмәгән аның. Җәен җир эшкәртсә, кышын аучылык аңа мул азык биргән. Җәнлек тиреләрен ул Уфага илтеп сата торган булган.

Нәсел үрчи, патша чиновниклары ээзәрлекләгән кешеләр килеп, мондагы куе урманда ышык урын табалар, бергә-бергә көн итә башлыйлар.

Арсланбәк батырның токымнары Пугач явында да катнаша һәм бу асыл егет соңыннан сөргенгә озатыла. Ирек сөюче табигать баласына каторга ошамый, ул аннан кача һәм урманнарда яшеренеп йөри. Арсланбәк еш кына, авылның тау башына килеп, курай уйный торган булган.

Авыл халкы, йокыларыннан уянып, аны елый-елый тыңлый икән. Ирек һәм бәхет даулаучы егет, авылга төшмичә генә, карагайлы кара урман эченә кереп яшеренә, ди. Авылга керсә, авыл халкы аны патша палачларына тотып бирергә тиеш булган, күрәсең.

Еллар узган, ләкин бәхет ташы ялтырамаган. Иксез-чиксез урманнар, болынлыклар да, бәхет уңдырасы урында, күп очракта борчу тудырганнар.

Аларны алдаганнар да, талаганнар да. Алпавыт Хәйдәр Сыртланов биш тиеннән мең десятина урман бүлеп алган. Ләкин мең генә десятина идеме икән ул? Украина, Казан якларыннан килгәннәр, кайсылары сорамыйча ук кереп утырган. Шулай итеп, без үскәндә, авыл картларының әйтүенә караганда, Арсланбәк белән Сорурбикәгә бүләк итеп бирелгән җирләрдә утыздан артык татар, башкорт, типтәр, украин, рус авыллары яши һәм шулар арасында иң фәкыйре безнең авыл иде.

Аның каравы, илле авылны берләштергән волостьта җиде мәктәп булса, берсе безнең авылда ачылган. Хәзер инде ул үзенең 70 еллыгына аяк басып килә. Шунда өч класслы белем алган безнең авыл яшьләре, бәхет табу юлларын өйрәнер өчен, читкә китәләр, күмер, алтын шахталарына юл алалар иде. Таптылармы алар бәхетне, юкмы, ләкин азатлык көрәшеннән берсе дә читтә калмады.

20 нче йөзнең башында авылда русско-башкирская школа ачылган. Школаны яндырып та караганнар, ләкин аның саен яктылык куәт алган. Русча-татарча укытыла торган мәктәп яшьләрнең күзен ача килгән. Хәзер колхоз идарәсе аның урынына сигезьеллык мәктәп салдырган, якты бүлмәләр, җиһазландырылган физика һәм химия кабинетлары, физкультура залы, пианино, китапханәләре белән мәктәп инде тау башына менеп утырган.

— Мәктәп төзелеше аның белән генә чикләнми, — ди Зәйнулла. — Мондый мәктәпне без – икене, башлангыч мәктәпне икене салдык. Хөкүмәттән бер тиен сорамадык!..

Хәзер бездә укытучылар саны гына 43. Ә укучылар — 565.

— Яшьләр авылдан китмиләрме? — дип сорыйм мин.

— Яшьләр шәһәргә китә икән, — ди Аскаров, — белем алырга китә.

Муса Җәлил

ОКОПТАН ХАТ

(Гази Кашшафка)

Кадерле дус!
Кайнар йөрәгемдә
Дәрт кабызган җылы хатыңны
Укыдым да, тотып мылтыгымны,
Кабатладым изге антымны.
Мин кечкенә кеше, тар окопта
Кечерәям булыр тагын да.
Ә шулай да бөтен дөнья бүген
Урын алган минем аңымда.
Күңел тоя,
миңа терәк булып,
Бөек халкым тора артымда.
Ничек туңсын йөрәк,
тоеп тәндә
Шул халыкның йөрәк җылысын?!
Ничек сүнсен өмет,
сизеп илнең
Җиңү утын, кайнар сулышын?!
Канат җәеп үлем куркынычы
Торган саен окоп алдымда,
Мин көчлерәк тоям ирек тәмен,
Яшәү дәртен кайнар канымда.
Күзләрдә яшь, беләм, алар горур
Яшәү хисе белән яшьләнгән.
Нәрсә артык җирдә илне саклап
Тар окопта батыр яшәүдән?!
Рәхмәт, дустым, салкын чишмә
төсле
Татлы сүзең җанга көч бирде.
Илдәге дәрт, ирек, яшәү хисен
Хатың аша миңа күчерде.
Кил, дускаем, шушы хат аркылы
Саубуллашып, кайнар үбешик.
Соңгы теләк:
җиңеп фашизмны,
Якты илдә тагын күрешик.

Октябрь, 1944 ел

— Быел без унъеллык мәктәп өлгертергә уйлыйбыз, — ди Әюпов. — Аннан соң китүчеләр азаер.

Өстәлгә зур журнал китереп салалар, анда бухгалтер хуҗалыкның исәбен теркәп барган. Зәйнулла Хәмидуллин миңа язылган цифрларны күрсәтә:

— Менә, карагыз, бу — безнең файда!

Колхоз 1968 елда миллион өч йөз мең сум керем алган. Һәм һәр хезмәт көненә 3 сум 77 тиен түләгән.

— Авылдан элек киткәннәр дә кире әйләнеп кайттылар инде!

Халык шулкадәр бай, ул, йомышы төшсә, ат сорамый, машина сорый. Колхозда 200 ат бар, машина — 16. Колхоз үзенең белгечләренә 10 мотоцикл алып биргән, ә үз акчаларына алганнары — 105 кеше, дүрт кеше инде автомобиль сатып алырга да өлгергән.

Соңыннан без Миңлеәгъзам абзыйга чәй эчәргә кергән идек. Мәэмүнә җиңгинең сый-хөрмәтен авыз иткәндә, шул ук бәхет, байлык турында сүз китте.

Сүз дә юк, халык бай тора: һәркемдә — алты почмаклы өй, шифоньер, радиоалгыч, тегү машинасы, диван-кровать. Телевизор бик тиз ишәеп килә, 215 хуҗалык инде баллонлы газ куллануга күчкән.

— Менә улым машина алыйк, дип әйтә, — ди Миңлеәгъзам Колыев — Тугыз умартадан 15 фляга бал алган идем. Кая куясың аны? Һәр флягасында 50 кило бит. Йә, ашагыз әле, сатып алган бал түгел...

— Ә колхозда умарталар ничек? — дим мин.

Колхозның умарталыгы да ишле икән, дүрт кеше 240 умарта карый.

Сигезьеллык мәктәпне карап чыккач, Зәйнулла мине урманга каратып сорый башлады. Бу тау башыннан бик ерак җирләр күренә иде.

— Каратал түбәсен онытмадыңмы?

— Юк...

— Әнә ул, шуның итәгендә инде умарталыкның бер өлеше...

— Беләм, шау чәчәккә күмелеп утыра торган җирләр инде!..

— Болынлыклар да җитәрлек...

Мин Каратал түбәсенә, аның куе һәм биек агачларына карыйм. Миңа алар хәзер дә бал исе аңкытып торалар кебек тоела.

— Шайтанлы чишмәсе ничегрәк?

— Шайтанлы? — диде, гаҗәпсенеп, Марк Семенович. — Кызык исем, ни өчен шулай атаганнар?

— Шайтан көче белән атылып чыга ул! — диде Зәйнулла.

— Аның легендалары да кызыклы, — дидем мин.

«

Без үскән вакытта инде әллә шайтаннар юашланды, әллә без алар белән дуслаштык, яздан алып кара көзгә хәтле Шайтанлы буенда ат саклап куна идек, бер адашкан егет булмады.

Сәрән авылы белән ике арадагы тау битеннән ургылып бер чишмә ага. Ян, Шәриф, мин — өчәүләп — ул чишмәнең суын авылга борып җибәрергә һәм бакчаларны сугару өчен файдаланырга мөмкин бит дип хыялланып йөри идек.

Без яшь чакта Шайтанлы чишмәсенә шайтаннар оялаган, алар тау битендәге имәнлек һәм юкәлектә яшеренеп яталар, туйлары вакытына туры килсәң, таң әтәчләре кычкырганчы адаштырып йөртәләр, дип сөйлиләр иде. Адашып

авыл башында әйләнеп йөргән кешеләрне исемнәре белән әйтәләр иде.

Без үскән вакытта инде әллә шайтаннар юашланды, әллә без алар белән дуслаштык, яздан алып кара көзгә хәтле Шайтанлы буенда ат саклап куна идек, бер адашкан егет булмады.

Нинди генә куркыныч әкиятләр сөйләмәсеннәр, безнең авыл кызларының юлы Шайтанлыдан өзелмәде. Алар, чүпләмле алъяпкычларын киеп, ак яулыкларын колак өстеннән генә бәйләп, итәкләрен килешле итеп кыстырып, буялган көянтәләренә яшел чиләкләрен асып, Шайтанлыга суга баралар иде. Җыелышып түгел, ялгыз-ялгыз барырга яраталар иде алар. Ни өчен шулай икәнен, егет булгач, үзем белдем: кызларга сөйгән егетләре белән күрешеп сөйләшергә бик уңайлы урын иде ул!

Безнең авыл шул Шайтанлы суын эчеп яши, ул су тәмле, саф, тешне камаштырырлык салкын. Кызлар чишмәгә килгәч, битләрен юалар, шуңа күрә аларның йөзе нәфис, йомшак була, ул суны эчеп үскән яшьләр зирәк-тапкыр булалар. Берәрсенең зирәклеге турында сүз чыкса:

— Аптырата алмассың, Шайтанлы суын эчеп үскән диләр аны! — дип горурланып та куялар иде.

Хәзер Шайтанлы чишмәсенең шайтан көчен колхоз үзенә буйсындырган. Тау итәгеннән терлек фермасына торбалар белән су керә, сыерлар, сарыклар автоэчергечтән шул Шайтанлы суын эчәләр. Шуңа күрә алар сөтне дә мул бирәләр, көрлекләре дә мактап бетергесез. Водопровод авылга да килгән: хәзер көянтә-чиләк күтәреп суга баручы кызлар юк, авыл урамында — су колонкалары…

Фермада эшләүче егетләр-кызлар белән әңгәмә ясаганда, зур кружканы тутырып минем алга Шайтанлы суын китереп куйдылар: сыйлаганда су эч, янәсе.

Ләкин бу суны сорап алып эчәргә кирәк! Әгәр безнең авылга килсәгез, Шайтанлы суын эчмичә китмәгез, аның тәме бер дә авыздан китми. Шифалы су ул.

— Ярый, сез бай, бәхетле яшисез. Бишьеллыкны да өч елда төгәлләп, биш мең центнер арттырып ашлык биргәнсез. Яшьләрегез укуга омтыла, читтән торып укучылар да җитәрлек. Балалар да бала тудыру йортында гына дөньяга киләләр икән…

Минем сүзне партком секретаре бүлә:

— Соңгы дүрт ел эчендә балаларның үлү очраклары бөтенләй бетте.

— Ел саен 59 балага үрчеп торабыз, — дип өсти авыл советы председателе.

— Авырлыклар да бардыр бит?

— Авырлык, дип, алар бар инде, — ди Зәйнулла. — Шифер саламны алыштырып бетерде, халык үз тормышыннан канәгать. Терлекчеләрнең 80 проценты инде биш көнлек эш көненә күчте. Санаторий, курорт кирәк кешегә — түләүсез путевка бирәбез. Бәйрәм көннәрдә эшләгәннәр ике хак алалар. Иген уңышы да район буенча гектардан 21,2 центнер булса, безнең колхозда өч мең гектар җирнең һәр гектары 22,3 центнер уңыш бирде. Шулай да безнең авырлыкларыбыз күп: безгә төзү материаллары җитми… Марк Семенович, бирегез әле безгә кирпеч күбрәк итеп, — председатель шәһәр комитеты секретарена борылды. — Әнә культура сараен да салып бетерәсе бар. Үзебездә безнең таудан таш чыгару бригадасы эшли, ул ташны без фермалар салу өчен генә файдаланабыз. Күпме акчабыз банкта ята. Төзү материаллары булса…

Авылны яңабаштан үзгәртеп салган, тормышны социалистик нормаларга яраклы рәвештә көйләп җибәргән бу ярсу йөрәкле абзыйлар һәм апалардан аерылып китәсе дә килми. Күңелле яши алар!

1969 ел ■

Гази Кашшафның «Шайтанлы чишмәсе буенда» исемле мәкаләсен басмага әзерләгәндә Башкортстан Республикасының Туймазы районындагы Яңа Арсланбәк һәм Сәйрән авылларында яшәүчеләр белән элемтәгә чыктык. Ни дисәң дә, әлеге юлъязма язылганнан соң ярты гасыр вакыт үтеп киткән бит. Бактың исә, авылдашлары Гази Кашшафны онытмый, хәтта мирасын өйрәнү белән дә шөгыльләнә икән.

Телефон аша эзләнә торгач, без Сәйрән мәктәбенең татар теле укытучысы, Яңа Арсланбәк килене Гүзәл Кәүсәр кызы Таҗетдинова белән элемтәгә чыктык. Иске йортны сүткән вакытта Гази Кашшафка бәйле фотоларга юлыккан, шуннан соң әдипнең нәсел-нәсәбен өйрәнү эшенә керешкән ул. Дөрес, Гүзәл Кәүсәр кызы бүгенгә ярты юлда гына. Әлеге эшендә аңа сабырлык һәм уңышлар телик.

Ә инде хәзерге көндә Яңа Арсланбәк халкы ничек яши? Ярты гасыр эчендә нинди үзгәрешләр булган? Бу сорауларга җавап эзләү өчен киләчәктә әлеге авылга – Муса Җәлилнең дусты Газиз Кашшафның кендек каны тамган җиргә махсус сәфәребез булыр, иншаАллаһ.

Әлегә әдип туган җирдән – Яңа Арсланбәктән килгән шушы фотолар һәм мәкалә белән таныша торыйк.

Редакциядән

Гази Кашшафның әтисе Шаһисолтан һәм әнисе Тайфә. Яңа Арсланбәк авылы

«Күңелгә җылы хис тулып тамды»

(Гази Кашшафның чормада табылган мирасы)

Гүзәл Таҗетдинова

Күренекле галим, әдәбият белгече, язучы, Татарстанның Муса Җәлил исемендәге премиясе лауреаты Гази Кашшаф – безнең якташыбыз. 1907 елның 15 апрелендә Яңа Арсланбәк авылында дөньяга килгән ул.

Аның ата-бабалары бик укымышлы кешеләр була. Әтисе Шаһисолтан хәзерге Татарстан Республикасының Сарсаз, Бәйрәкә һәм Тымытык мәдрәсәләрендә белем алган, төрле фәннәрне, шулай ук рус телен дә өйрәнгән. Яңа Арсланбәк авылы халкы аны үзләренә мулла хезмәтенә чакырган. Рус телен яхшы белгәнгәдер, аны «урыс мулла» дип йөрткәннәр. Яңа Арсланбәк авылында ул указлы мулла вазыйфасын башкарган. 1900 елда Яңа Арсланбәк авылында, Шаһисолтан мөрәҗәгате нигезендә (ул һәр йортка кереп култамга җыя), земство идарәсе тарафыннан «Рус-башкорт училищесы» ачыла. Шулай итеп, ул анда хатыны белән мөгаллимлек итә башлый. Әтисе ир-егетләрне укытса, әнисе Тайфә (хәзерге Бүздәк районының Килем авылыннан килен булып төшкән) кыз балаларга белем биргән.

Илдә совет хакимияте урнашкач, Шаһисолтан мулла вазыйфасыннан баш тарта, әмма үзенең яраткан шөгылен ташламый – колхозда умартачы булып эшли. Ул 1937 елда, авырып, 77 яшендә вафат була.

Әтисеннән төпле белем алган Гази, 1920-1925 нче елларда Бәләбәй укытучылар семинариясендә укый. Шулай ук



Шаһисолтан хәзрәткә имамлык итү турындагы указны мөфти Ризаэддин Фәхреддинов биргән

«
Әтисе Шаһисолтан хәзерге Татарстан Республикасының Сарсаз, Бәйрәкә һәм Тымытык мәдрәсәләрендә белем алган, төрле фәннәрне, шулай ук рус телен дә өйрәнгән. Яңа Арсланбәк авылы халкы аны үзләренә мулла хезмәтенә чакырган. Рус телен яхшы белгәнгәдер, аны «урыс мулла» дип йөрткәннәр.

Гази Кашшаф хатыны Һаҗәр, энесе Фәтхелбаян һәм аның хатыны Нәкыя белән

Гази Кашшафның балачак дуслары

аның дүрт сеңлесе дә, әлеге училищены һәм югары уку йортларын тәмамлап, гомер буе укытучы булып эшли. Араларында Ленин һәм Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары белән бүләкләнгәннәре, «Башкортстанның атказанган укытучысы» исеменә лаек булганнары да бар.

Гази Кашшафның әтисе – **Шаһисолтан**, бабасы – **Кашшафетдин**, карт бабасы **Габделмәҗит** исемле булган. Ә Габделмәҗитнең әтисе **– Габделкәрим**, аның әтисе – **Габделгалим**. Шулай итеп, сораша торгач, язучының җиде буынын ачыкладык. Ә бу бабайларның нәсел чыгышы, борынгыларның сөйләвенә караганда, Болгар тарафларыннан икән.

Шаһисолтан хәзрәтнең 12 баласы дөньяга килгән. Миргазиян исемлесе – икенче хатыннан туган балаларының иң зурысы. Аның Фәтхелбаян һәм Шәрифҗан исемле энеләре булган. Фәтхелбаян энесе сугышка китеп хәбәрсез югалган, аның хатыны Нәкыя апа (иремнең икетуган тутасы) озак еллар Яңа Арсланбәктә яшәде. Хәзерге вакытта ул торган нигездә Нәкыя апаның туганнары гомер итә. Шушындагы йортны сүткәндә, әлеге фотосурәтләр килеп чыкты да инде.

Гази Кашшафның Тайбә, Фатыйма, Мөкәрәмә һәм Саҗидә исемле сеңелләре дә булган. Тайбәнең кызы Роза апа (1936-2020) Уфада яшәде. Фатыйманың

кызы Найзә (1925 елгы) – Октябрьский шәһәрендә, Сәҗидәнең кызы (1928 елгы) Химия апа Туймазыда яши. Мин, Роза апа белән очрашып, күп мәгълүматны аңардан белеп калдым. Роза апа җәй көне Яңа Арсланбәккә кайтып йөрде. Кызганыч, Гази Кашшаф туып-үскән йорт, янгын чыгу сәбәпле, сакланмаган. Әлеге нигездә Роза апаның ире һәм балалары матур гына йорт төзеп килә, бәлки, шунда ук бөек язучы, Җәлилне дөньяга таныткан мөхтәрәм якташыбыз хөрмәтенә истәлек тактасы да булыр.

«Гази Кашшаф туып-үскән йорт, янгын чыгу сәбәпле, сакланмаган. Әлеге нигездә Роза апаның ире һәм балалары матур гына йорт төзеп килә, бәлки, шунда ук бөек язучы, Җәлилне дөньяга таныткан мөхтәрәм якташыбыз хөрмәтенә истәлек тактасы да булыр.

Роза апа миңа Гази Кашшафның өч улы булуы турында сөйләде. Алар да, әлеге нәсел кешеләренә хас булганча, укымышлы, затлы, зыялы кешеләр икән. Гази, хатыны Һаҗәр уллары бәләкәй чагында авырып үлгәч, аның бертуган сеңлесе Асиягә өйләнә. Олы улы Ренарт (1931 елгы) әтисе эшләгән Казан дәүләт университетында 19 яшеннән алып 46 ел дәвамында Россия тарихын укыткан, доцент булган. Ул 2007 елда 76 яшендә дөньядан киткән. Икенче улы Руслан – күренекле математик, Санкт-Петербургта яши. Адик улы диңгезче хезмәтен башкарган.

* * *

Гази Кашшафның Яңа Арсланбәккә 1969 елның гыйнвар аенда рәсми җитәкчеләр белән кайтуы билгеле[1]. Шул вакыйга уңаеннан аның мәктәп укучыларына язып калдырган хаты бар.

Сулдан өченче – Г.Кашшафның бертуганы Сәҗидә

[1] Журналыбызда басылган юлъязма әлеге сәфәр уңаеннан язылган. ***– Ред.***

«Арсланбәк сигезьеллык мәктәбен зур кызыксыну һәм канәгатьләнү белән карап чыктым. Кайчандыр мин дә шушы мәктәпнең укучысы идем. Ул чакта 4 класс бер бүлмәдә укый иде. Хәзердә бу бинаны һични белән чагыштырып булмый: киң, иркен һава, якты! Тагын бер тапкыр шушы мәктәпнең якты бүлмәләрендә, лабораторияләрендә рәхәтләнеп укыр идем! Ләкин тарих артка чикми, бу мөмкин түгел. Авылдашларыма, якташларыма бәхет, шатлык телим, отлично укырга киңәш бирәм. Хөрмәтле укытучылар коллективын Республиканың 50 еллыгы белән котлыйм[2] *һәм эштә яңадан-яңа уңышлар телим!*

Кызганыч ки, ял көне туры килде, укучылар белән очраша алмадым. Җитмәсә, минем китаплар да сездә бик аз икән. Мөмкин булган кадәрлесен туплап җибәрергә тырышырмын.

Уңышлар теләп, хөрмәт һәм ихтирам белән, Г.Кашшапов.

Тышта 40 градус салкын, күңелгә җылы хис тулып тамды – шул хис белән китәм! *Алда очрашулар өмете белән...»*

Аяныч, Яңа Арсланбәк мәктәбе ябылганга инде 40 ел чамасы вакыт үтеп китте. Бу хат хәзерге вакытта Сәйрән мәктәбендә саклана.

* * *

Гази Кашшаф, вәгъдәсенә тугры калып, туган авылы мәктәбенә «Муса Җәлил» һәм «Муса Җәлил турында истәлекләр» исемле китапларын җибәрә. Арсланбәк мәктәбе ябылгач, бу ядкярләр дә Сәйрәнгә күчә. Китапларга автографларны ничек матур, тәмле тел белән язган ул:

«Туган авыл! Туган мәктәп! Изге йорт, изге җирләр! Беренче тапкыр мин сездә хәреф таный башладым, беренче тапкыр сез тормышка юл күрсәттегез, күңелемне ача башладыгыз! Тормышта бик күп юллар барлыгын әйттегез! Мин шуларның береннән киттем...

Дөрес сайладыммы мин юлны? Анысын сез әйтегез!

Туган авылыма, туган мәктәбемә мәхәббәтем көчле!

Г.Кашшапов. 14/III.69, Казан»

«Бу китапның русчасы да бар, ләкин үземдә калмаган. Мәскәүдә басылган җыентык һәм аларга мин язган сүз башлары шулай ук кул астында юк. Шуңа күрә туган мәктәпнең китапханәсенә җибәрә алмыйм. 7, 8, 10 нчы класслар өчен әдәбият дәреслекләрен сез күп күргәнсез, аларны чыгарышуда да минем нәни хезмәтем бар иде. Аларын да җибәреп тормыйм.

Туган авыл яшьләренең Муса Җәлил кебек батыр булуларын телим!

Г.Кашшапов. 14 март, 1969 ел, Казан»

«

«Туган авыл! Туган мәктәп! Изге йорт, изге җирләр! Беренче тапкыр мин сездә хәреф таный башладым, беренче тапкыр сез тормышка юл күрсәттегез, күңелемне ача башладыгыз! Тормышта бик күп юллар барлыгын әйттегез! Мин шуларның береннән киттем...

Дөрес сайладыммы мин юлны? Анысын сез әйтегез!

Туган авылыма, туган мәктәбемә мәхәббәтем көчле!

Г.Кашшапов»

---

[2] Татар язучыларының әлеге сәфәре БАССРның 50 еллыгы уңаеннан оештырылганлыгы аңлашыла. ***– Ред.***

Гази Кашшаф яшьли вафат булган тормыш иптәше Һаҗәр ханым белән

* * *

Гази Кашшафның Яңа Арсланбәк мәктәбе директоры Мәгариф абыйга Уфа шәһәреннән язып җибәргән хаты да бар. Әлеге хатны миңа Мәгариф абыйның кызы, танылган анестезиолог Флүрә Габдуллина (кызганыч, ул бер ай элек вафат булды) биргән иде.

«Мәгариф дус! Мин авылга кереп кенә чыга алдым, үз машинаң булмагач, машина хуҗасына буйсынасың. Сине күрәсе килгән иде. Мин Муса Җәлилнең немец тылында оештырган подполье группасын өйрәнеп йөрим, материаллар туплыйм. Җепнең бер очы Муллаҗанга килеп тоташа. Ул Муса белән бергә эшләүчеләрнең берсе булса кирәк, Абдуллин фамилиясендә йөргән, Крушино хәрби әсирләре Муллаҗанны таныйлар иде дип ышанам. Шуңа күрә аның иң соңгы карточкаларыннан берәрсен (копиясен алып) миңа җибәрсәң иде. Бу гомуми эш өчен, патриотик эш өчен кирәк, бу шулай ук Муллаҗанның якты истәлеге өчен кирәк! Шул үтенеч белән сиңа эндәшәм һәм түбәндәге адрес буенча җибәрүеңне сорыйм:

г.Казань, М.Горького, 17, кв. 1, Гази Кашшафу.

Сәламәтлек теләп, ихтирам белән, Г.Кашшапов. 24/68, Уфа»

* * *

Киләчәктә Гази Кашшафның затлы, зыялы бабалары, кардәшләре турындагы мәгълүматларны төрле архивлардан эзләргә, бу шәхеснең Россия буенча сибелгән нәсел-нәсәбе белән элемтәне ныгытырга һәм башлаган тикшерү эшемне дәвам итәргә уйлыйм. ■

Безнең мирас №10 октябрь 2020

Мөдәррис Әгъләм вафаты
(1946-2006)

Ләбиб Лерон

Рәсемдә (сулдан): Ләбиб Лерон, Газинур Морат, Мөдәррис Әгъләмов һәм Ркаил Зәйдулла. 1979 ел.
Айрат Садыйков фотосы

Без студент чакта Мөдәррис абый берара, безнең белән бергә, Гадел Кутуй урамындагы тугыз катлы тулай торакның (2Б йорт) 194 нче бүлмәсендә яшәп алды. 1979-1980 нче еллар иде бу. Ул вакытта аңа 33-34 яшьләр булгандыр. Яше мәшһүр шагыйрьләрнең (әйтик, Байрон, Пушкин, Маяковский, Артюр Рембо, Велимир Хлебников, Николай Рубцов) вафат булган яшенә, ягъни утыз җидегә якынлашуына ишарәләп, Мөдәррис абыйдан үзебезчә көлгән булабыз:

– Җүнле шагыйрьләр утыз җиде яшьтә үлә, тарихта каласың килсә, сиңа да күп калмады! – дибез.

Ул да безгә кушылып көлә.

Алгарак китеп әйтим: якын дусты Зөлфәт тә, Мөдәррис абый үзе дә, гомерләренең әлеге мәгълүм чиген узып, алтмышны тутырып, чын мәгънәсендә халык шагыйрьләре булып бакыйлыкка күчте.

Вафатына бер ай кала, Зөлфәт абыйның үз юбилее кичәсендә әйткән сүзләре хәтеремдә яңара:

– Чын шагыйрьләр бу яшькәчә яшәми, хәерлегә булсын!

Утыз җидене генә түгел, алтмышны да узып вафат булсалар да, Мөдәррис Әгъләм дә, Зөлфәт абый да чын шагыйрьләр иде. Алар үзләренең зур шагыйрь икәнлекләрен белеп китте...

2006 елның 2-4 мартында Азнакайда, шагыйрь Илдус Гыйләҗевкә алтмыш яшь тулу уңаеннан, Әдәбият көннәре булып узды. Бер төркем әдипләр катнашында үткән



әлеге чарага Мөдәррис Әгъләм дә барды. Азнакайга барышлый, «Рәхмәт аланы»нда туктап, чәй-каһвә эчеп торган бер мәлдә, Мөдәррис абыйның тавышсыз, пышылдап диярлек сөйләшүенә игътибар итеп, болай дигән идем:

– Күрәм, Мөдәррис абый, салкын тигән сиңа. Сузып йөрмә, дәвалан! – мин әйтәм. – Хәлеңне аңлыйм, чөнки үземнең дә синең кебек шактый вакыт тавышны югалтып йөргәнем булды. РКБда бер табиб бар, фониатр. Азнакай егете. Исеме Анфас иде шикелле. Шуңа барып күрен. Миңа ул булышты. Аның киңәшен тотып, гомеовокс дигән дару эчтем. Файдасы тиде – тавышым шундук ачылды. Азнакайдан кайтуга, син дә бар шул егет янына!

– Әй, башны катырма әле, болай да рәтләнә ул! – дип, Мөдәррис абый кулын селтәде дә сигаретын авызына капты. Ул арада горык-горык йөткерергә тотынды…

Без, ир-ат заты, шундый халык бит инде: берәр җиребез авырта башласа, дәвалану турында уйлап та карамыйбыз, үтәр әле, дип, Мөдәррис абый шикелле кул селтибез.

«Үтәр әле…» Кайчакта чир үтә, кайвакыт үтми шул… Мөдәррис абый, белүемчә, гомере өзелгәнчегә кадәр тавышсыз сөйләште. Азды чире, аздырды аны шагыйрь. Исенә килеп, төрле төнәтмәләр, дару-мазар эчә башлаганда, соң иде инде…

2006 елның 30 октябрендә «Казан» милли-мәдәни үзәгендә Мөдәррис Әгъләмгә алтмыш яшь тулу уңаеннан әдәби-музыкаль кичә узды. Аны Мөдәррис абыйның якташы, Зәй тумасы Рабит абый Батулла алып барды. Зал халык белән шыгрым тулы булган ул кичәдә Мөдәррис Зөфәр улы Әгъләметдиновка (тулы әйтелеше шулай) «Татарстанның халык шагыйре» дигән мактаулы исем бирелде. Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев Указын Татарстан Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин игълан итте.

Мөдәррис абый ак кәчтүм-чалбардан иде. Авыруын сиздермәскә тырышты, шаярды, башын артка чөеп, кулларын алга – югарыга ыргытып шигырь укыды (Разил Вәлиев шундый мизгелне эләктереп, аны фотосурәткә төшергән иде шикелле). Әмма шагыйрьнең йөзендә хасталык чалымнары нык сизелә иде инде…

Милли-мәдәни үзәктә узган юбилей кичәсендә. Мөдәррис Әгъләмне каләмдәшләре Туфан Миңнуллин, Разил Вәлиев, Равил Фәйзуллин һәм Мөхәммәт Мирза котлый. 2006 елның 30 октябре

Көндәлек битләреннән

«10 НОЯБРЬ, 2006 ЕЛ.

Кичә Зиннур Хөснияр белән Мөдәррис абый янына барырга ният иткән идек. Бүген төштән соң шуны тормышка ашырдык: Зиннур, Акъегет (Рөстәм Фәйзуллин) һәм мин Мөдәррис абый янында булдык.

Без килгәндә, Равил Фәйзуллин белән Ркаил Зәйдулла фатирдан (Нәҗибә Сафина фатиры) чыгып килә иде...

Әгъләм кара трикодан, әфлисун төсендәге футболкадан иде. «Кәртечкә»гә төшкәндә футболкасы өстеннән кәчтүм генә киде.

Шагыйрьгә «Салават күпере» һәм «Сәхнә» журналларының яңа саннарын, шулай ук рәссам Фәрит Муллахмәт ясаган «М.Әгъләмов» портретын (журналда басылачак ул портрет-рәсем артында Рәис Даутовның шагыйрь турындагы кыскача белешмәсе бар) бирдек. Сөенеп кабул итте.

– Миңа канис булса, мин сездән риза-бәхил, – диде әкә (Мөдәррис абыйга без, яшьтиләр, шулай дәшә идек). – Тәм юк авызда. Тәм булмагач, дөньяның яме юк!

Бер сәгать чамасы гәпләшеп утырдык.

Без булганда Мөдәррис абый, подъездга чыгып, тәмәке пыскытып керде.

– Бик каты йөткерер алдыннан гел шулай тәмәке тартып ала ул! – диде Нәҗибә ханым...»

«12 НОЯБРЬ, 2006 ЕЛ.

Якшәмбе. Урамда Фәйрүзә Мөслимова очрады.

– Әгъләм яныннан кайтып киләм әле. Шундый ябыккан! – ди...»

«15 НОЯБРЬ, 2006 ЕЛ.

Шимбә. Мөдәррис абыйдан интервью алмакчы булам, шуның өчен 27 (Тукай гомеренчә!) сорау әзерләдем...»

«16 НОЯБРЬ, 2006 ЕЛ.

Пәнҗешәмбе. Әгъләм янына Рөстәм Акъегет белән бергә барырга тиеш идек. Нindiдер сәбәпләре булып, ул бара алмады.

Сәгать 9:40та Мөдәррис абый янында идем инде. Диктофонны көйләп куйдым. Шагыйрьнең бертуганы Рәсимә апа да шунда иде. Әңгәмә барышын ахырына кадәр ул, ут йотып дигәндәй, шагыйрь энесенең һәр сүзен йотлыгып тыңлап утырды.

Мөдәррис абый йөткерә-йөткерә сөйләде. Әңгәмә ахырында хәле бетә башлаган кебек тоелды. Чаршау артындагы ятакта бераз ятып алды...

Йөткерүләр ешая төшкәч, шагыйрьне әңгәмә өчен кузгатуыма мин инде үкенә үк башладым. «Бүгенге көндә сине бик борчыган сорау бармы?» – дигән сөалемә каршы ул: «Соравың бетәме инде?» – дип, шаяртып дигәндәй әйткәч, мин инде коелып иңәр чиккә җиттем...»

«23 НОЯБРЬ, 2006 ЕЛ.

Пәнҗешәмбе. Язучылар берлегенә Нәҗибә Сафина килде. Ркаил Зәйдулла белән икәү аның белән сөйләшеп тордык.

– Мөдәрриснең хәле бик начар, – диде ул. – Кичә «Кремль асты»ннан табиб (Илсур Шәймәрданов) килде. Озак тормас инде, диде. Хастаханәгә кереп яткан булса да, нәтиҗәсе барыбер шушылай булыр иде, диде.

Мөдәррис абый, саташып, вакыт-вакыт алышынып та ала икән инде.

– Янында төн кунарга без кирәкмибезме? – дип сорады Ркаил.

– Кирәкми әлегә, – диде Нәҗибә ханым.

Мөдәррис абыйның хәлен белешеп, Шәүкәт абый Биктимеров та шылтыраткан икән:

– Бакудан кайтуга, Ирек Бәһманның хатынын җирләдек. Мөдәррис берәр сүз әйтәме соң? – дигән.

– «Татар зиратында урын кыйбат торамы икән?» – дип сорады Мөдәррис, – диде Нәҗибә ханым...»

«25 НОЯБРЬ, 2006 ЕЛ.

Шимбә. Көндезге сәгать уникеләрдә Зөлфәт абый шылтыратты:

– Мөдәррис янында булдык. Саташып ята. Сулы мамыкны сыгып, авызына берничә тамчы тамызган идем, кое төбенә ике чиләк су салган кебек булды, ди. Шуннан соң аңлаешсыз сүзләр әйтә башлады: тугызынчы май... тугызынчы май... икәү бергә...

Зөлфәт абый, бер мәл тын торды да:

– Әллә Мөдәрриснең киләсе елга шул вакытка мине чакыруы булды инде, – дип әйтеп куйды.

Мин Зөлфәт абыйны тынычландыра башладым:

– Сез бит икегез бергә кайчандыр Уфага баргансыз, шулай бит?! Мөдәррис абый шуны искә төшергәндер, мөгаен?!

– Бәлки...

Зөлфәт абыйның дәшми торуыннан файдаланып булса кирәк, трубканы Фирая апа алды:

– Мин әле бу, энем... Әйе, әле генә Мөдәррис абыең яныннан кайттык... Озак тормас инде...

– Фирая апа, Зөлфәт абыйдан сора әле, алар Уфага кайсы вакытта барды икән? Минемчә, шул чакны искә төшерүедер Мөдәррис абыйның...

Бераздан Фирая апа тавышы:

– Зөлфәт абыеңнар, чынлап та, май башларында барганнар, ахрысы. Тик, нишләптер, пәлтәдән булганнар...

Алар Мөдәррис абый янында булган чакта «Ашыгыч ярдәм» машинасы килеп киткән. Кыскасы, Мөдәррис абыйның хәле шәптән түгел, ул соңгы көннәрен кичерә, ахрысы. Үзем дә Нәҗибә ханымга шылтыраттым. Яңалык шул ук. Мөдәррис абыйдан алган интервьюны компьютерга күчереп яткан мәлем...»

«26 НОЯБРЬ, 2006 ЕЛ.

Якшәмбе. Телефоннан Шәүкәт абый Галиев белән сөйләштем, Илдар абый Юзеевка нисбәтле истәлек китабы мәсьәләсендә. Аның белән гәпләшеп, телефон трубкасын куюга, Нәҗибә Сафинага шылтыраттым (кичке сигезләр иде шикелле).

– Ләбиб, кил... – диде ул.

Нәкъ шушы мизгелдә Мөдәррис абый өзелгән (соңыннан Нәҗибә ханым әйтте). Шундук Ркаил Зәйдуллага, Газинур Моратка, Марат Закирга һәм Зиннур Хөсниярга бу турыда шылтыратып әйттем.

Без (З.Хөснияр, М.Закир, шофер Айдар һәм мин) килгәндә, фатирда Нәҗибә ханым, аның кызы белән кияве, Мөдәррис абыйның апасы Рәсимә, янә бер хатын-кыз бар иде. Бераздан ике әби кереп, алар Мөдәррис абый гәүдәсе яткан чаршау артына утырды.

Без килер алдыннан гына Чаллыдан Рәшит Бәшәр шылтыраткан булган:

Мөдәррис Әгъләмов һәм Ләбиб Лерон (шагыйрьнең вафатына ун көн кала). 2006 елның 16 ноябре

– Их, күзләрем авырта, җил ярамый, хушлашырга килгән булыр идем! – дип уфтанган.

Нәҗибә ханымның әйтүенчә, Мөдәррис абый уникe сәгать тоташ йоклаган. Уянгач, бурсык маеннан ясалган төнәтмәне бал кашыгына салып, ике тапкыр эчкән. Үзен тәртипкә китерткән. Нигәдер «кассета» дигән сүз әйткән.

Төнге икенче киткәнче (димәк, 27 ноябрьгә кергән чак инде бу) шунда булдык...»

«28 НОЯБРЬ, 2006 ЕЛ.

Мөдәррис абый белән хушлашу көне. Алдан сөйләшеп куйганча, Марат Закир белән икәү, Нәсим Акмал машинасына утырып, Нәҗибә ханым фатирына киттек.

Подъезд төбендә Ркаил Зәйдулла Нәҗибә ханымның бер ир туганы белән гәпләшеп тора иде. Бераздан катафалк машинасы – «Лимузин» килеп җитте. Мөдәррис абыйның улы Идел (шагыйрә Рина Асылбаева белән Мөдәррис абыйның уртак уллары) белән күрештем. Язучылар берлегенең «Газель» машинасына (шоферы Алмаз исемле) утырып, Газинур Морат, үлем-китем вакытында чатыр чабып йөрүче Язучылар берлегенең хезмәткәре Шамил Бәдретдинов килеп җитте. Нәгыйм Шаһи, Хәбир Ибраһим күренде. Бераздан катафалк машинасы мәетне Зур концерт залына алып китте...

Халык күп иде. Зиратка да шактый кеше барды. Аларны исемдә калганча язам: Туфан Миңнуллин, Разил Вәлиев, Марсель Галиев, Мөхәммәт Мирза, хатыны Фәридәне күптән түгел генә җирләгән Әхәт Гаффар, Зәки Зәйнуллин, Рабит Батулла, Мәсгут Гайнетдин, Фәрит Яхин, Хәбир Ибраһим, Фәрит Муллахмәт, Рафаэль Сәхәби, Хәлим Җәләй, Ркаил Зәйдулла, Әлфәт Закирҗанов, Зөлфәт абыйның кызы Кадрия һәм башкалар...

Урының җәннәт түрендә булсын, Мөдәррис абый! Мин әле синең юклыкны аңлап, төшенеп җитә алмыйм... Тугыз-ун көн элек кенә әңгәмә корып утырган идек ләса...»

Шагыйрь китте, җыры калды. Ә безгә шагыйрьнең мирасын барлап, исемен яд итеп, һәрдаим догада булып яшәргә дә яшәргә әле...

2020 елның 20 сентябре ■



ТАШ БАТЫР ТУРЫНДА РИВАЯТЬ

(Хикәят)

АЙДАРБӘК САРМАНБӘТОВ

Күренекле кыргыз язучысы, тәрҗемәче, публицист һәм журналист, Казакъстанның «Мәңгелек дуслык» (2010), Төркиянең Мәхмүт Кашгарый исемендәге (2012), Кыргызстан Республикасының күпсанлы премияләре лауреаты Айдарбәк Имангази улы Сарманбәтов 1953 елның 8 июнендә Кыргызстан Республикасындагы Ыссык Күл районындагы Кара Өй авылында дөньяга килгән.

Кыргыз дәүләт университетын тәмамлап, журналист һөнәре алган Айдарбәк, халык сәнгать һөнәрчелеге берләшмәсендә тугыз ел эшләп, 1990 елдан хөкүмәт, парламент һәм халыкара газеталарда, «Кыргызстан әдәбияты» журналында хәбәрче, баш мөхәррир вазыйфаларын башкара. Бүгенге көндә ул – «Төрки дөнья әдәбияты» журналының баш мөхәррире, Халыкара иҗтимагый поэзия академиясенең генераль директоры.

А.Сарманбәтов – Кыргызстанда, Төркиядә һәм Кытайда дөнья күргән утызга якын китап авторы. 2019 елда аның «Изге үр» дигән китабы Татарстан китап нәшриятында «Төрки әдәбият» сериясендә татар телендә басылып чыкты. Ул үзе дә, тәрҗемәче буларак, нәтиҗәле эшчәнлек алып бара: рус, төрек, казакъ, азәрбайҗан, татар, алтай, гагауз һ.б. халык язучыларының әсәрләрен кыргыз теленә тәрҗемә итә.

А.Сарманбәтовның риваять нигезендә иҗат ителгән «кан башка, нәсел-нәсәбе башка, әмма бер-берсенә үтә дә лаек булган ике батыр турында»гы хикәятендә ут-күрше булып яшәгән ике халыкка нисбәтле гыйбрәтле вакыйга сурәтләнә. Тарихтан, әлеге җан тетрәткеч хикәяттән сабак алып, безгә дә бердәм булып яшисе дә бит, кана...

Редакциядән

– Бабай, безнең борынгы бабаларыбыз нинди булган?

– Аларның күбесе курку белмәс, кыю-батыр булган, халкы өчен, ирек өчен көрәшкән...

– Ә син... сез халык өчен ни эшләдегез?

– ... ?!

Кайчандыр Аксак Тимер сугышчылары ыргытып калдырган ташлардан зур һәм кечкенә таулар хасил булып, бүгенге көндә легендага әверелгән Санташка искиткеч гүзәл Каркырдан күтәрелгәч, күл тарафына ат белән юыртып барганда, иң әүвәл кечкенә бер алан уртасындагы тирмәнне хәтерләтеп торган зур, йомры таш күзегезгә чалыныр. Кайчан, каян барлыкка килгән ул, кем һәм ни өчен тәгәрәтеп китергән аны – билгесез. Әллә кайчаннан бирле тора инде ул. Элек бу йомры ташка терәлеп диярлек изге агач – мазар торган. Гыйбадәт кылу урыны булган ул. Ә хәзер һичкемдә мазар кайгысы юк, тирә-юнь буп-буш. Бу Таш батыр үз гомерендә ниләр генә күрмәде: мәрхәмәтсез, шәфкатьсез чорларны да кичерде ул, шаулы бәйрәмнәрнең дә шаһиты булды, катлаулы, авыр һәм бәхетсез язмышларны да күрмәде түгел. Әгәр йомры ташны игътибар белән тыңлап торсаң, имеш, ул көндез дә, төнлә дә, җәен дә, кышын да гүләгән тавыш чыгара икән, үзенчә шулай «сөйләшә», янәсе. Без аның телен аңласак, кем белә, бәлки, ул безгә үзе генә белгән бик күп вакыйгаларны озын-озак итеп сөйләгән булыр иде... Шундый вакыйгаларның берсе хакында, әйтик, кан башка, нәсел-нәсәбе башка, әмма бер-берсенә үтә дә лаек булган ике батыр турында хикәят тәкъдим итәргә булдым...

* * *

Тын гына агып барган чуар болыт, бермәл зәңгәр чиста күк йөзенә ябышып торгандай итте дә, ерак-ерактагы Хан-Тәңренең очлы башына чорналды. Берничә җайдак тарлавыктагы иңкүлек буйлап, бүреләр сыман юыртып, югарыга таба күтәрелеп бара. Беркем берни дәшми. Тавыш-тынсыз, кәефсез, барысын да уй баскан. Юл газабы – гүр газабы, диләр. Хак икән. Хәтта ыгы-зыгысыз чакта да бернинди бәя тормаган башыңны бер мизгел эчендә корыч кылыч чабып төшерүе ихтимал яки сызгырып очкан уклар, котмәгәндә, сине үтәли тишеп чыгарга мөмкин. Юл сугышчыларны тәмам хәлдән тайдырды. Җайдакларның калкынып-калкынып барган очлы сөңгеләрен исәпкә алмаганда, бүтән артык хәрәкәт ясаучы юк. Вакыт-вакыт сугышчыларның әле берсе, әле икенчесе куе урманлы тау битләренә, зәңгәрсу-кызыл, шома кыяларга шөбһәле карашын юнәлтеп ала. Нәрсәдәндер шүрлиләрдер, күрәсең. Тау сыртына җитәрәк, төрле мәзәкләр уйлап чыгарырга һәвәс булган зәңгәр күзле, җирән чәчле такылдык Койкот янәшә барган юлдашларының әле берсен, әле икенчесен үчекләргә, котыртырга тотынды. Юлдашларының кайсы үпкәләгәндәй итте, кайсысы исә пырхылдап көлеп җибәрде. Инде Койкот та тынды, сөйләшми башлады. Ат өстендә изрәп барса да, күзләре яна үзенең. Оста аучы ул. Уклар салынган садагы һәрвакыт аркасында булыр. Бу юлы ул

аның турында онытты булса кирәк, садак бер якка янтайды, уклар чак кына коелмыйча калды. Арыган кешене юлда йокы баса башлый. Аның да башын куркыныч уйлар билидер, мөгаен.

Көн кичкә авышты. Кояш, тауларда күләгәләр хасил итеп, түбән төшә башлады. Караңгыланганчы, бу тарлавыктан ничек тә исән-сау чыгып котыласы иде. Барысын да борчыган уй шул. Йөксез-нисез җайдаклар шаулап аккан елга буйлап, еландай сузылган сукмаклардан өстерәлеп диярлек, баруларын дәвам итте. Алар, Нахсын батыр җитәкчелегендәге ойрат-калмык сугышчылары, туган яклары Жунгариядән бирле тау сыртлары аша бара-бара, Каркырны үтеп, Санташка килеп чыкты. Бернинди йөксез-нисез алдан баручы җайдак – нәкъ менә шул Нахсын батыр инде. Ул кыска буйлы, нык бәдәнле, кымыз белән шыплап тутырылган күн капчыктай кабарынкы, юан иде. Дошман угыннан һәм кылычтан саклану өчен, өстенә алтынсу көбә һәм сарык тиресеннән тегелгән толып кигән. Толып эченә батыр гәүдәсе көчкә сыйганлыгы читтән күренеп-сизелеп тора иде. Батыр башындагы мөгезле тимер башлык – шишак – кояшта ялтйолт килә. Ул аны тагы да гайрәтлерәк итеп күрсәтә иде. Бу юлы ул беркем белән дә сөйләшмәде. Моңсулыктанямансулыктандырмы, Нахсынның алсу йөзендәге йоннары кабарган, сыек мыегы авыз читеннән салынып төшкән, чырае төн кебек караңгы. Нахсын батырны, еллык салымны җыярга дип, Кытайның төньягындагы жунгарлар таҗдары Сыбан Доржун үзе бурут-кыргызларга җибәрде. Жунгарлар ике ел элек таулар арасыннан сил суы кебек ташып чыктылар да ике елга култыгы аша Көньяк һәм Төньяк диңгез буенда яшәгән кыргызларга һөҗүм иттеләр. Аннары алар Кочкор, Кемин һәм Чуй үзәнлеген үзләренә буйсындырды. Тыныч кына гомер итеп ятучы кыргыз авыллары бик тиз тар-мар ителде. Дошман явыннан исән калган көньяктагы кыргызлар Анҗыян һәм Гысарга хәтле сибелде, ә төньяктагылары исә очсызкырыйсыз һәм сусыз кайсак даласына таралды. Тары кебек сибелгән бурут-кыргызлар хәзер каршылык күрсәтә алмаячак дип уйлады хан. Шуңа күрә Нахсын батырны унлап кына сугышчы озата барды.

– Ы-ы-ы-ыгу-гу-а-а-а-ы-ыху-у-у-а... – Нахсын көтмәгәндә тамагын кырып алды һәм бик борынгы бер җыруны сузып җибәрде. Бик шөбһәле чакларда, дошманнар белән хәл аеруча катлаулы вакытларда ул гел шушы җыруны көйли иде. Андый-мондый хәл буласын сизенмәсеннәр өчен, юлдаш яугирләр алдында шулай җырлап алу – аның бердәнбер ысулы иде, күрәсең.

– Ы-ыххуа-аа-уу-уххх-муа-аа...
Җерден-судан җаралып, у-у-ххаа-а...
Теңирден келген җаныбыз, у-ум-маа...
Җер үстүндө җиңилгис, х-маа-а...
Батырлардан бабабыз, у-ахха!
Беттегенди чабабыз, у-у-ахха-а...
Эңсегенди алабыз, у-ахха!
Ы-ыххуа-аа-ухх-муа-аа...

Әйе, сүз һәм җыр никадәр көчкодрәткә ия шул! Озын юл газабыннан интегеп, йокымсырап барган яугирләргә кинәт көч-куәт иңгәндәй булды, гәүдәләрендәге тамырларда кан кайный башлады, ышанычлары артты, тик торганнан кәҗәләнеп алдылар. Аларның шәлперәйгән гәүдәләре турайды, сүз-әңгәмәләре җанлана төште, үзләрен хакимнәрчә тотып сөйләшә башладылар.

Нахсын җырлавын җырласа да, башындагы фикерләре кырмыскалар кебек кайный иде, бара-бара ул авыр, тирән уйга чумды. Дөресен генә әйткәндә, күрше халыкларның кайчаннан бирле бер-берсенә явыз дошманга әверелүен төгәлен генә беркем дә белми ич. Хәзер дә тотрыксыз, болгавыр заман. Гомумән алганда, бурутлар кыю

халык. Туган илләреннән кайсы-кая куылса да, ватаннарын ташлап китмәгән бер төркем батырлар, өннәрендә яраларын ялап ятучы бүреләр шикелле, качып-яшеренеп, үзләрен кыерсытучыларны сабыр гына көтеп ята булыр. Аларга хәзергә кагылмавың хәерлерәк...

Карап торышка ваемсыз булып күренгән калмык батыры, күк йөзе урталай ярылса да, гадәт буенча берни дә сиздермәс иде – ул ике яктан калкып торган тауларга каш астыннан гына күзләрен йөгертеп алды. Һәрбер кыя, һәрбер йомры таш, һәрбер чыршы артыннан көтмәгәндә кыргызлар атылып килеп чыгар кебек. Ул чакта аңыңа да килми калырсың – уклар сызгырып очар, сөңгеләр бәреп егар, дошман кылычлары башыңны чабып өзәргә дә күп сорап тормас. Мондый хәлләрнең шаһиты булырга бик еш туры килде аңа. Кыргызлар җитез, курку белмәс халык. Тапкыр, зирәк кавем. Шуңа күрә дә алар, гасырлар аша үтеп, миллилекләрен, үз биләмәләрен югалтмыйча, бүгенге көнгә исән-имин килеп җиткәннәр. Кыргызлар – хәтта пар мөгезле зирәк Искәндәргә дә, канлы кылычы белән бөтен дөньяны яуларга ашкынган Аксак Тимергә дә буйсынмаган халык. Ничәмә йөз ел узган югыйсә, әмма калмыклар белән үҗәтләнеп орыш алып баруын дәвам итә. Башка дошманнар да бар бит әле. Аз санлы сугышчылар гына калуына карамастан, йә җиңелеп, йә ярсу барс сыман җиңеп, алар әле дә аяусыз көрәш алып бара. Егерме еллар элек тынгысыз таждар Сыбан Рабданның улы Галдан Сарен, алтмыш меңлек гаскәре белән җиңел генә һөҗүм итеп, кыргызларны, берочтан аларны яклап кушылган кайсакларны да кырып салып, ул кавемне ватаныннан мәхрүм итәргә, учак көлен сибеп җибәрергә, ыруны җир белән тигезләргә теләде. Шул вакытта җиде яшьтән алып җитмеш яшькәчә булган барлык ир заты юк ителде. Бурутлар ул чакта да буйсынмады, исән калды. Инешләр һәрдаим агып торудан далада зур күл хасил булгандай, кинәт бер йодрыкккa төйнәлеп, башларын югары күтәрергә бурутларга әллә ни күп вакыт кирәк булмады. Әлеге канкоештан соң егерме еллап вакыт узмагандыр, Әхмәт бәй Кашгарны тар-мар итте, ун меңлек гаскәре белән аңа каршы чыккан Зайсан Доржунны вак кисәкләргә бүлгәләп ташлады. Ирек сөйгән, тамырларында кодрәтле кан аккан халыкны бөтенләй юк итү, җир йөзеннән себереп түгү мөмкин хәл түгел, күрәсең. Ни генә әйтсәң дә, мәгърур Азиянең төп халкы бит ул! Борын-борын заманда ук барлыкка килгән бу халыкны, тәгаен, күк һәм җир саклыйдыр! Һәрвакыт юктан бар була, чуар феникс шикелле, кабат көлдән ярала. Кайчандыр кырмыскалар кебек чутсыз-сансыз булган кытайлар, үзләрен тәкъва халыктан җәберләнгәндәй хис итеп, меңнәрчә чакрымга эчәгедәй сузылган Бөек дивар төзеп куеп, чарасыз чакларда шуның артына яшеренде... Ошбу уйларын ханга сөйләп, Нахсын гүяки күңелендәгесен бушата иде. Ә тегесе аның сүзләренә колак салмады. Кем белә, бәлки, ул бүгенге вазгыятьтәге хәл-халәтеннән канәгать булгандыр һәм шул сәбәпле, Нахсын менә хәзер аз санлы яугирләре белән хәрәкәт итеп ятмыштыр. Ахыр чиктә, ул-бу була калса, хан да читтә кала алмаячак анысы...

Әгәр хаким аны мәҗбүр итмәгән булса, әлбәттә, хәзерге мәлдә авыр уйларга чумган Нахсын шәхсән кыргызлар белән бәйләнешкә кереп тә тормаган һәм мондый озын, куркыныч сәфәргә кузгалмаган да булыр иде. Баһадир өйдә туа, яуда үлә, дигәндәй, аның авыр уйларга чумуы үз башын кайгыртудан яисә елгыр кыргызлардан куркудан түгел, киресенчә, әлеге батыр һәм буйсынмас халыкны тирән хөрмәт белән искә алудан иде. Уйлап

баксаң, аның шымчыланып йөрерлек шәхси үче дә юк бит. Дөрес, бихисап батырларны һәлак иткән канлы бәрелешләрдә күп катнашырга туры килде аңа. Әмма бу бит бар халыктан үч алырга кирәк дигән сүз түгел. Әйе, кайвакыт дошманың сиңа берне генә түгел, берничә мәртәбә абруеңны төшерерлек дәрәҗәдә яра сала… Эчтән сызасың, җаныңны канәгатьсезлек хисе били… Тик бу, кем әйтмешли, үзең теләп алган яра…

Их, ошбу фани дөньяның һәрвакыт ызгыш, сугыш чыгарырга атлыгып торган комсыз, бозык хакимнәре булмаса!.. Нәкъ менә алар – халыкларны канкоешка дучар итүчеләр. Нишлисең бит, болгавыр заманның башка яугирләре кебек, горур халкының кыю улы, баһадир Нахсын да, үз хакиме ни кушса, шуны үтәргә мәҗбүр. Шул мизгелдә аның күз алдына агарынган чырайлы, карсак буйлы, хәйләкәр һәм коточкыч саран, эче-тышы хөсетлек белән тулган Сыбан Доржун килеп басты. Юл-сәфәргә чыгар алдыннан ул Нахсынны кабат сараена чакыртты һәм икесе генә чакта мондый сүзләрне җиткерде:

– Кыргызлар яшәгән диңгез буен әйләнеп-йөреп чыгыгыз. Хуҗа була бел, әйт үзләренә: ике еллык ясак түләсеннәр. Минем фәрманга ничек карыйлар – яхшылап, дикъкать белән күзәт. Күзләренә туп-туры карап сөйләш, хәрәкәтләренә игътибар ит, шул-вакытта гына аларның безгә карата мөнәсәбәтен – ачулымы яисә буйсынучанмы икәнлеген күрерсең. Илләрен ташлап китүчеләр бармы, әллә бөтенесе бергә таралышып беткәнме – игътибар белән кара. Әгәр туган җирләрендә төпләнеп калучылар бар икән, күпмесе калган – һәммәсен исәпкә ал.

Шуннан соң ул беразга тынып торды һәм әйтергәме-әйтмәскәме дигән караш илә тирә-юньгә күз йөгертеп алды, чит-ятлар берүк ишетмәсен диптерме, ул Нахсынның колагына пышылдады:

– Эшләр без теләгәнчә бармаса, икебезнең дә баш очачак. Ясак ул бер сәбәп кенә. Төп эш башкада. Әгәр алар диңгез буенда калмаган булсалар, буш биләмәләрен император биләмәләренә кушарбыз. Менә шул чакта бурут-кыргызлар торлаксыз, туган җирсез калачак. Без алардан мәңгегә котылачакбыз… Бу серне хәзер икәү генә беләбез, аңладыңмы?!

Аның әлеге сүзләреннән шул аңлашыла иде ки, әгәр Нахсын кемгә дә булса серне чишсә, үлемнән ул һич котылып кала алмаячак.

Нинди яшерен сер турында сүз бара соң? Мөгаен, кыргыз биләмәсен Кытай карамагына тапшырып, Сыбан Доржун дошманыннан шулай үч алып, алардан мәңгегә котылмакчы булгандыр. Әмма мөмкин эшме бу? Әгәр шундый хәл килеп туса, бер төркем бурут кырмыска кебек мыжлап торган кытайлардан үз җирләрен кабат кайтарып ала алырмы? Бурутларны океан юып алып киткән кебек булмасмы? Ул чагында кыргызлар кыпчаклар, көрдләр, дунхулар шикелле ватансыз калмасмы яисә җир йөзеннән бөтенләй юкка чыкмасмы? Кыскасы, алар «ватансыз халык – халык түгел» хәлендә калырлар сыман. Бәлкем, бу хәйләкәр императорның, ерактан фәрман биреп кенә, калмык һәм кыргызны үзара бәрелештерергә һәм тәмам юк итәргә дигән бер астыртын күрсәтмәседер?! Яз башында гына аның ярдәмчесе, артык купшы кыланып, көязләнеп, яраннары белән бергә килеп киткән иде, бәлкем, шул чакта ул ханга яшертен генә нидер пышылдагандыр… Әйе, моның шулай булуы бик ихтимал.

Ни генә әйтмә, Нахсынның үзара дошманлашып яшәгән ике әзмәвер арасында кысылып калуы хак. Хәер, өч әзмәвер арасында, дисәк, дөреслеккә күбрәк туры килер кебек. Котылып кала алырмы ул? Әллә дөяләр үзара ышкылганда, алар арасына кысылып һәлак булган чебен хәлендә калырмы?

Борын-борыннан шулай килә – нишли дә алмыйсың. Бары тик байлык, дәрәҗә һәм хакимият турында гына уйлаган зәгыйфь, чирләшкә хакимнәр аркасында күпме кан коелды, күпме гөнаһсыз бәндәнең башы җилкәсеннән очып төште. Әйе, мәнсез хакимнәрнең канлы орышларыннан гади халык кына зыян күрә, интегә, газап чигә. Сөекле ирләрен, газиз балаларын югалткан кешеләр ирексездән чит-ят җирдә каңгырып, качып яшәп ятарга мәҗбүр. Аларның бик авырлык белән генә кулга ияләштерелгән мал-туарлары, озак еллар тупланган байлыклары талануга дучар...

Тарлавыктан чыгуга, баһадир башын югары күтәрде. Аз санлы яугирләре белән бергә куркыныч тау кочагыннан котылуына шат иде ул. Шуңа карамастан, ике тау арасыннан тарлавыкка төшеп барганда, ул мәкерле дошманның сиздермичә генә читтән күзәтеп баруын бөтен җаны-тәне белән тойды. Хәзер дә дошман, яугирләрдән һич калышмыйча, уктай үткен карашын текәп, күзәтүен дәвам итә. Тау буйлап барган чакта, тау сыртында әле аю, әле кеше шикелле хәрәкәтләнгән шәүләләрне ике-өч мәртәбә шәйләп өлгергән иде инде Нахсын. Алар – бурутларның тиешле урыннарга алдан махсус куелган күзәтчеләре булды, ахры.

Менә җайдаклар, бөтенесе берьюлы дигәндәй, кытайлар элек-электән Кызыл Үзән дип йөрткән Ыссык Күл үзәнлегенең алгы өлешенә килеп чыкты. Җилкәләреннән авыр йөкне алып ташлагандай хис итте алар үзләрен. Бердәм җиңел сулыш алдылар. Кычкырып сөйләшә башладылар. Үзендә көч-куәт артуын сизепме, аеруча Койкот төртмәле сүзләрен сибәргә тотынды.

Киң җәелгән күлнең тигез, каракучкыл өстен учакны хәтерләткән кызыл төскә буяп, кояш офык артына төшеп кунаклады... Очлы башларын бозлыклар каплаган таулар да, тонык күлне ялтыравык белән каймалап алгандай, янып торган кызыл күмер төсле, күзләрне камаштыра иде. Әйе, яз үзенекен итә – инде яшел үләннәр пәйда була башлады. Кинәт тау башларында уңнан да, сулдан да, ерактан да, якыннан да, бер-бер артлы борма-борма булып сузылып, һавага чуар төтеннәр күтәрелергә тотынды. Дошман якынлашуын хәбәр иткән билге иде бу. Күчмә халыкларда бу гадәт күптәннән килә. Димәк, үзәнлектә кешеләр бар. Күрәсең, халык бөтенләе белән качып китмәгән. Бурутлар үзләренең изге күлләрен беркайчан да ташлап китми, диләр. Хак, ахрысы.

Нахсын, үзәнлеккә һәм тау буйларына күпме генә караса да, элекке шикелле җәелеп яткан, каплап куелган пыяла чынаякларны хәтерләткән аклы-каралы тирмәләрне күрмәде. Димәк, кешеләр тауларга күтәрелгән.

Ашыгып кына үзәнлектән чыгып барган яугирләр атларны сикертеп чаба башлады. Атлар да, нидер сизенгәндәй, уяу. Еракта ике таучык төсмерләнде. Моннан өч мең ел элек Аксак Тимер сугышчылары калдырган җанисәп таучыклар иде болар. Таучыкларның олырагы – Каркырга гына түгел, Кытайдан да ары таба чигенгән бурутларны эзәрлекләп китүче сугышчылар тарафыннан ташлап калдырылган ташлардан гыйбарәт. Ә тегесе, кеше буе чамасындагысы, орышлардан исән-сау кайткан яугирләр калдырган ташлардан хасил булган. Кыю, елгыр кыргызлар белән орыштан күпме сугышчысы исән калганын шундый ысул белән белергә теләгән, ахрысы, баш илбасар. Азиянең яртысын үзенә буйсындырган Аксак Тимер үзенә буйсынмаган дошманын – үҗәт һәм шөһрәт яратучы халыкны тар-мар итәргә, җир йөзеннән себереп түгәргә теләгән, әмма чынлыкта ул үзенең исәпсез-хисапсыз яугирен югалткан. Моның шаһитләре – әлеге ике таучык. Кыргызларга килсәк,

чигенгән чакта алар, дошманга әсир төшмәс өчен, ыру-ыру булып, тауларга, үзәннәргә сибелгән... Шул ук вакытта алар дошманга һәрдаим һөҗүм итәргә, аларны көчсезләндерергә тырышкан. Еш кына теләкләренә ирешкәннәр дә... Көтмәгәндә һөҗүм иткәннәр дә, кабат тауларга, далаларга таралганнар... Аксак баскын берни дә майтара алмагач, үз ягына – Сәмаркандка кайтып киткән. Кыргызлар исә, уйсулыктан аккан инешләр шикелле бер урынга коеп, яңадан берләшкән һәм торлак хасил иткән. Бурутларда ыру-кабилә элемтәләре, шулай ук кан-кардәшлек бик көчле. Алар башка халыклар шикелле теләсә кая качып китми, киресенчә, күчмә тормыш алып барсалар да, дошманнан куркыныч янаган вакытта, шундук бер-берсенә сугышчан оран салып, тиз арада берләшәләр. Бурутларның җиңелмәс булуларының бер сере шушыдыр. Дошман һөҗүм итә башлауга, әниләре ягыннан кан-кардәш булганнар, туган-тумачалар, ыру-кабиләдәшләр, көтмәгәндә бер йодрыкка әйләнеп, кичекмәстән дошман явына ташланган. Зур тәвәккәллек белән, әлбәттә! Муеннарына кылыч куйсалар да, алар берсен-берсе сатмаган. Әгәр элекке заманнардагы шикелле бер хан тирәсенә туплана алсалар, аларны беркем дә җиңә алмас иде. Кыргызлар һичкайчан беркемгә буйсынмаган, хәтта үз ханнарына да! Үз дигәненчә генә яши торган, һичкем алдында баш имәс халык. Үзләрен кирәгеннән артык иркен тотучылар. Менә шул сыйфатлары бердәнбер кимчелекләредер әле, мөгаен. Хәер, кем белә, бәлкем, бу аларның өстенлекләредер...

Шундый озын-озак уйга талган Нахсын кинәт үзенең балачагын, йөзьяшәр бабасын исенә төшерде. Әлеге урыннан – Санташтан Кызыл Үзәнгә чыккан чакта, алан уртасыннан көнчыгышка таба тизлекне арттыра төшеп барганда, ике-өч сәгать үтүгә, ул вакытта әле исән-сау булган, күл ахырындагы култыкта урнашкан Чига каласына килеп чыгасың. Кайсыдыр гасырда, кыргызлар өстенә көтмәгәндә яу килеп, Кытай императоры шәһәрне басып ала. Оҗмахка тиң әлеге үзәнне ул кыргызларга кире кайтарырга һич уйламаган, әлбәттә. Шәһәр чәчәк ату хәленә үсеп җиткән, күпсанлы гаскәр туплаган, иркеле, иркен тормыш белән яши башлаган. Императорда алдан күрүчәнлек сыйфаты булмаган, картая төшкәч, инде хәлсезләнү чигенә җиткәч, кыргызлар баш күтәргән һәм дошманны дөнья читенә куып җибәргән. Киләчәк буын түбәнсетелүне, мыскыл ителүне белмәсен өчен, кыргызлар үзләре үк, шәһәрне җимереп, җир йөзеннән юк иткән. Саф акыл, изге уйлар белән яшәүче менә шундый халык инде ул! Бу бер үк вакытта тирән сер дә, бөек гамәл дә. Күпмедер вакыт үтүгә, күл үзе каланы су астында калдырды. Шәһәр читендәге кайбер хәрабәләр вакыт-вакыт әле дә күренгәләп ала, дип сөйлиләр...

Нахсын артыннан, күләгә булып, сөңге буе ара калдырып барган Дорбу, бар кыюлыгын туплап, сәфәр башлыгына якынлашты. Дорбу – унбаш, Нахсынның уң кулы санала. Шуңадырмы, юл буе аны батырлык кылу, тәвәккәллек күрсәтү хисе биләп килде.

– Баһадир, атларны күлнең төньягына таба борабызмы, әллә көньягы... – Дорбу сүзен әйтеп бетермичә туктап калды. Әле генә иң алда барган бер баһадир, атын кирегә борып, кулы белән алга таба ишарәләп, болар янына таба килә-килә кычкырды:

– Ых!

Ул карашын алдагы тау өстенә таба төбәде. Дорбу да карашын җәһәт кенә шул тарафка юнәлтеп алды. Кичке эңгер-меңгер булуга карамастан, якындагы тау башында мәһабәт гәүдәле җайдак басып торганы күренде. Бер хәрәкәтсез, торташ булып басып тора.

Күзгә күренми торган өрәк, диярсең. Шундый куркыныч!

Баеп баручы кояшның кызыл нурлары төшкән көбәсе һәм кызыл ялкынны хәтерләткән очлы баш киеме аны уттан яралгандай итеп күрсәтә иде. Чын сугышчы! Көтелмәгән бу күренештән Дорбуны курку хисе биләп алды. Аты да, җайдак үзе дә таулар шикелле бер-берсенә тәңгәл килеп тора. Кодрәтле кеше! Үзе генә булса да, һич курыкмыйча, карашын текәп, дошманын көтеп тора!

Нахсын, үзенең гайрәтле кыяфәте белән, теге пәһлеванга юкка чыгарга ишарә ясагандай итте. Шулвакыт аның башына көтелмәгән уй килде. Бәй, шушында яшәүчеләр һәм йөзбашлар өстеннән идарә итәргә өч йөз калмык белән калдырылган Торгул би торлагы нәкъ менә шул пәһлеван басып торган тау артында түгелме соң? Аның исәпләвенчә, алар торлакка төн уртасында килеп җитәргә тиеш. Шуңа күрә булдыра алган кадәр ашыгырга тырыштылар. Хәзер нәрсә була инде, әлеге әзмәвер аркасында алар Торгул бигә барып җитә алмаячакмыни?! Кем белә, әле аның үзе кебек тагы күпме әзмәвере бардыр?.. Шик юк, бу хәйләкәр бәндәнең тау артында яшеренеп торган яугирләре аларны түземсезләнеп көтеп тора булыр. Әгәр бу чынлап та шулай икән, сугышчылар саны буенча тегеләр күпкә артыграк һәм, шул сәбәпле, Нахсынныкына караганда тагы да көчлерәк-куәтлерәк булырга тиеш. Дошман оясына атылып бару хәзер куркыныч. Ике тәүлеккә сузылган юл газабыннан соң, Нахсын яугирләре һәм аларның атлары тәмам йончыган иде. Бу хәлдә сугышка кермәвең хәерлерәк. Ул артында басып торган Дорбуга карт агач янына тирмәләр корырга һәм тирмәне хәтерләткән хәйран зур, йомры таш тирәсенә казан асарга фәрман бирде. Шушында төн чыгасы булыр дигән нияткә килде Нахсын. Аның уенча дошман алай-болай кинәт һөҗүм итеп, йөзгә-йөз бәрелешергә туры килсә, әлеге йомры таш аларны арттан ышыклап торачак иде. Ул һаман карашын ат өстендә гаярь кыяфәт белән утырган әзмәвер җайдактан алмады. Әгәр хәйләкәр кыргызлар, атлары белән атылып чыгып, көтмәгәндә һөҗүм итә калса, аларның юлына каршы төшәргә туры киләчәк. Ятакта үлүең – хурлык, яуда үлүең – мактауга лаек, дигәндәй... Ул берүзе берничә дошманны юк итә алачак анысы. Әгәр көчләр тигез икән, орышка барачак. Кимрәк икән, тагы да яхшырак.

Нахсын атына атланган килеш, тау башындагы пәһлеванга сынаулы карашын төбәде. Нишләргә соң? Җиңүче буларак, аның янына барырга һәм хакимнәрчә сораулар яудырыргамы, әллә бернигә игътибар итмәстән, төн куну хәстәренә керешергәме? Бу юл белән беркемнән дә курыкмаганлыкны күрсәтергә кирәк. Алар һөҗүм итмәскә тиеш.

Әйтерсең лә, ике өрәк, тынлык аша бер-берсен сыный, сихер-михер ярдәмендә көч алыша. Нахсын да хәрәкәтсез тора. Үзен кырыс кеше итеп күрсәтеп, ул бу җирдә кем хуҗа икәнен аңлатырга тели. Сугышчылар, атларыннан төшеп, кайсы-кая урын әзерләп йөргән бер мәлдә, ниндидер бер малайның үзәккә үтәрлек еламсак тавышы ишетелде. Нәрсә бу?! Нахсын шул тарафка борылып карады. Дорбу, кемнеңдер якасыннан эләктереп, бар көченә өстерәп, аны Нахсынга таба алып килә иде. Унбаш, авыз эченнән мыгырданып, үзе өстерәп килгән малайны Нахсынның аты алдына ыргытты.

– Безне сагалап, көтеп торган, көчек! Таш ярыгына посып, бүре баласы шикелле җиргә сыенган иде...

Җиде-сигез яшьләрдәге малай тәгәрәп китте дә җитез генә торып басты. Борынын тарта-тарта, кул аркасы белән күз яшьләрен сөртеп алды. Бирчәйгән, теткәләнгән толып астыннан, малайның шәрә тәне күренеп тора иде.

– Әйт, көчек! Син безне сагалап

тордыңмы? Сиңа нәрсә кирәк? Кайда синең тирмәң? Ата-анаң кайда? Әйт дөресен! – Дорбу малайның аркасын камчысы белән кыздырып алды.

– А-а-а! Мин… мин… болай гына… Тамыр казыдым һәм ашадым… – Аркасы кызышудан, малай отыры катырак кычкырды. – Әти-әнием юк минем… Үлделәр алар… чуалыш вакытында…

Нахсын камчысы белән кабат сугарга җыенган Дорбуны туктатырга өлгермәде, кинәт котны алырдай усал тавыш яңгырады:

– Ә-һә-һә-әй!

Ошбу тавыштан мәгърур кара таулар да калтыранган кебек булды. Барысы да, сискәнеп, куркулы карашларын тавыш килгән тарафка төбәде. Аларның юлына аркылы басып торган җайдак таудан түбәнгә төшә башлады. Вак ташлар, ат тояклары астыннан очып чыгып, аска коелды. Яугирләрнең барысы да, фәрман көтеп тормастан, кылычларын кыныларыннан җәһәт кенә тартып чыгарды. Койкот, җәя керешенә укны куеп, атарга әзерләнде. Биш-алты яугир, кыргызлар һөҗүмгә күчте дип уйлап, кабаланып атларына атланды. Юк, таудан төшеп килүче әзмәвер үзе генә иде. Ул тузан туздырып килде дә ук барып җитәрлек урында туктап калды.

– Әй, сез нәрсә эшлисез? Малайны кыйнап, батырлык күрсәтмәкче буласызмы?! Җибәрегез аны! – диде ул, үзен хуҗаларча тотып. Аның тавышы барабаннан да катырак яңгырады.

Беркем дә дәшмәде. Чынлап та, тау артыннан сыңар сугышчы да күренмәде. Ялгыз җайдак никадәр мәгърур, усал булмасын, ул барыбер берүзе генә иде. Яугирләр, үзләре дә сизмәстән, бердәм җиңел сулыш алды. Үзен яклаучы якын кешесе булгангадырмы, малай, бәргәләнеп, читкә тайпылырга омтылды, әмма аны Дорбу, бөркет кебек, җилкәсеннән каты эләктергән иде.

– Әй! Җибәрегез малайны! – Бу юлы җайдак үз дигәнендә нык торучан икәнлеген искәртеп кычкырды.

Берәү дә эндәшмәгәнлектән һәм аның таләбен үтәүче булмаганлыктан, җайдак, атын бик каты типкеләп, боларга таба якынлашты. Бермәлгә югалып калган Нахсын нишләргә белмичә торды. Уйларының очы-кырые юк. Әгәр җайдак әйткәнчә эшләсә, куркак булып саналачак. Моңа һич кенә дә барырга ярамый, чөнки ул баскын, басып алучы хәлендә. Соңыннан халык бу хакта гасырлар буе искә алачак. Әгәр җайдак таләбен үтәмәсәң, ул чакта ахыры ни белән бетәчәк?!. Ул уйланып торган арада, җайдак, тагы да якынрак килеп, биш-алты адым ара калдырып, аның каршында туктады. Чынлап та, җайдак – пәһлеванның да пәһлеваны! Хәтта атланган атыннан да олпатрак күренә. Ике иңсәсенә ике кеше рәхәтләнеп, иркенләп утыра ала. Күкрәге әйләндерелгән казанны хәтерләтә.

– Кем монда баш кеше? Нишләп барыгыз да авызыгызга су капкандай торасыз? Әллә кыргыз телен берегез дә белмиме? – дип сорады ул, боеручан тавыш белән. – Бу баланың нинди гаебе бар? Сезгә нинди зыян салды бу зәгыйфь, көчсез бала?

Дорбуның каушап калуыннан файдаланып, малай яугирнең кулыннан ычкынды да, җайдак янына йөгереп килеп, аның аркасына сыенды.

– Яшәсен пәһлеван! – Нахсын әле генә аңына килде. Әзмәвернең үзе генә булуына тәмам инанганлыктан, ул, фикерләрен бераз туплаганнан соң, бурутны сөйләштереп карарга булды. Икенче яктан караганда, янау янаудан аерыла. Ул әсир төшкән кыргыз балалары белән кечкенә чактан бергә уйнап үсте. Шуңа күрә кыргыз телен бик камил дәрәҗәдә белә иде.

– Төшегез атыгыздан, әйдәгез, юлчыларның тыйнак табынындагы сыйнигъмәттән авыз итегез. Ашыкмыйча гына сөйләшеп утырыйк, танышыйк. –

Нахсын үз яннарына курыкмыйча килгән кыю-батыр кыргыз сугышчысына үзенчә шулай хөрмәт күрсәтергә теләде.

Әзмәвер шундук лаеклы җавап кайтарды:

– Һм, кем белән, минем халкымны кырган дошман беләнме? – Күчмә тормыш алып барган халыкларда кан дошман белән бер табын янында утыру – егет кеше өчен халкын сатуга бәрабәр. Мондый эш борын заманнардан бирле ят нәрсә. Пәһлеван сүзләренең асылында, күралмаучанлык белән бергә, шуңа да башыгыз эшләмимени дигән сорау-мәгънә ята иде. – Үз ризыгыгызны үзегез ашагыз, баһадир.

Нахсынга ниһаять барып җитте: бер ялгызы булуга карамастан, әйтәсен дошманына һич куркусыз әйтүе белән, пәһлеванның алар белән беркайчан да килешүгә бармаячагы көн кебек ачык иде. Күренеп тора, җайдак – кыю йөрәкле, зирәк акыллы, чын пәһлеван. Нахсынның аңа хөрмәте тагы да арта төште. Көндәшен хөрмәт итмәгән баһадир – баһадир түгел. Әгәр дә моны эшли алмый икән, димәк, ул түбән җанлы кеше. Бер үк дәрәҗәдәге кеше икенчесен тиң күрми, хөрмәт итми икән, тиңдәшлекнең мәгънәсе нәрсәдә соң алайса? Әйе, башны кисәләр, ә телне – юк! Ул җанында кайнаганны ачыктан-ачык әйтеп бирде. Баһадирның башы теләсә кайсы вакытта бүкәнгә ятарга мөмкин.

– Шулай да сөйләшеп карыйк, шунда үзебезнең сорауларга да җавап табарбыз. – Нахсын үзенең дә төшеп калганнардан түгеллеген, үз сүзендә тора белүен сиздерде. Әзмәвернең фикере аңа кызык иде. Гадәттә, мондый кешеләр күп белүчән. Әгәр дә сөйләшеп китсәләр, аның максаты ачыкланыр иде. Атын кирегә борып китмәгән икән, димәк, аның сөйләшергә исәбе бар дип уйлады Нахсын. Ул, әзмәвергә караганда яшьрәк булганга күрә, гореф-гадәт буенча, атыннан бик тиз генә төшеп, йөгән-тезгенен кулына кысып тотты да:

– Безне чынлап та дошман санныйсыз һәм сыебызны авыз итәргә теләмисез икән, әйдәгез, ул чагында менә монда утырыйк, – дип, ул якындагы ташка ишарәләде.

Кыргыз калмыклар башлыгының төпле тәкъдименә каршы килә алмады, аның күңеле йомшарып китте хәтта. Изге максат еланны да оясыннан чыгарга мәҗбүр итә, диләр. Атыннан сүлпән генә төште дә әзмәвер тезләнгән дөягә охшаган ташка барып утырды.

Ул киң яңаклы, мускуллары калкып торган йөзле, чөйсыман чал сакаллы, киң сөякле, чынлап та, таза гәүдәле кыргыз булып чыкты. Күзләре керфекләре астыннан очкын чәчеп тора. Яңа туган колын койрыгын хәтерләткән мыегы авыз чите буйлап асылынып төшкән – шыксызлыгы чиктән ашкан. Нахсын никадәр зур, олпат булуына карамастан, әлеге кыргыз янында малай-шалай гына булып күренә. Аюга охшаган бу әзмәвер Нахсынга кинәт һөҗүм итә-нитә калса, һичьюгы кыргызның игътибарын читкә юнәтеп булса да хуҗамны саклап калырмын, дип алар янында сакта басып торган Дорбу, әңгәмәдәшләрнең тыныч кына гәпләшүенә инангач, бер читтә ут тергезеп, казан асып әвәрә килүче юлдашлары янына китте. Яугирләрнең кайберләре, сөңгеләрнең очлы башына тирмәләр өчен алдан махсус әзерләнгән ыргакларны эләктереп маташа иде.

– Җә, баһадир, Сезне нинди йомыш китерде? Нәрсә югалттыгыз? Нинди дәгъвагыз бар безгә? – диде кыргыз пәһлеваны, Нахсынга сынаулы караш ташлап. Аңа калмыклар башлыгы ошады булса кирәк. Бу юлы аның тавышы уртача яңгырады. Шуңа карамастан, аның: «Сезне нинди йомыш китерде?» – дип әйтүендә хәйләкәр төсмер дә ята иде.

Ахыры киләсе санда ■

Урысчадан ***Ләбиб Лерон*** *тәрҗемәсе*

Безнең мирас №10 октябрь 2020

Соңгы йөз ел эчендәге мәшһүр татарларның үлем вакытлары күбесенчә утызынчы, утыз җиденче яки сугыш елларына туры килә. Шушы елларда вафат булганнар яки сугышта һәлак булган, яки аларны зинданнарда җәзалап үтергәннәр. Яисә аларның гомере, искәрмә буларак, башка фаҗигаләр аша узган.

«Безнең мирас» журналы укучыларына шул ачы язмышлар турында кыскача мәгълүмат биреп, хәтер яңартып үтәсем килә.

Батулла

КАРА ТӘКЪДИР

(Ачы язмышлы шәхесләр)

АБДЕНАНОВА АЛИМА (1924-1944)

Кырымтатар кызы. Кырым АССРдагы Керич (Керчь) каласында туган. Партизан кыз. Советлар Союзы Герое. Немецлар тылында – Кырымда яшерен разведкада эшли.

Ул гестапочылар тарафыннан кулга алына һәм коточкыч җәзаларга дучар ителә. Фашистлар 20 яшьлек татар кызын яндырып үтерәләр. Шул ук елның май аенда аның гаиләсен Себергә сөрәләр. Рухы шат, урыны җәннәттә булсын!

АИТОВА ФАТЫЙХА (1866-1942)

Мәгърифәтче. Җаек каласында Беренче гильдия сәүдәгәр Габделвәли Аитов гаиләсендә туган.

Фатыйха Аитова 1897 елда үз акчасына татар кызларын укытыр өчен махсус мәктәп ача. Бу мәктәптә уку-укыту эшләре бик югары сыйфатлы була.

Ләкин Фатыйха ханымның бу гамәле жандармериянең сәяси эшләр бүлеген бик бимазалый һәм мәктәп Оренбург губернаторының махсус фәрманы белән юкка чыгарыла. Бу Фатыйха ханым өчен генә түгел, бөтен татар милләте өчен дә олы фаҗига була.

АИТОВ АИТЗАК (1908-1941)

Татар шагыйре. Саратов өлкәсенең Дергач төбәгендәге Алтата авылында туган.

Смоленск өлкәсендәге Демидов шәһәре өчен барган сугышта һәлак була. Шәһид буларак, җәннәт насыйп булсын!

АКМУЛЛАЕВА ФАТЫЙМА (1928-1945)

Шәфкать туташы. Судин өязендә яшәүче татар сәүдәгәре Рәхимҗан Акмуллаев гаиләсендә туган (Кытай). Мөгаллимә. Кытайдагы Колҗа шәһәрендә татар мәктәбен тәмамлый.

Дунган кешесе Мансур Ломпев җитәкчелегендәге партизаннар төркеме Көнчыгыш Төркестан Республикасы өчен барган сугышларда катнаша. Алар арасында курку белмәс татар Рәхимҗан Акмуллаев та була. Ләкин батыр сугышчы Рәхимҗан дошман ядрәсеннән һәлак була. Рәхимҗанның һәлак булганын ишетеп, аның анасы партизан төркеме командиры Мансур Ломпев янына килә һәм: «Минем улым изге көрәштә һәлак булды, ләкин аның изге эшен кызым Фатыйма дәвам итәчәк, алыгыз аны үз арагызга», – ди ана.

Фатыйма партизаннар төркеме белән бик күп бәрелешләрдә катнаша.

1945 елда Колҗа шәһәре янындагы каты сугышларда 17 яшьлек кыз бала, җәрәхәтләнгән сугышчыларны коткарганда, үзе дә һәлак була. Урыны җәннәттә булсын!

АКЫШ ГАЛИ (1918-2011)

Күренекле татар җәмәгать эшлеклесе, публицисит, Бөтендөнья татарлары лигасының шәрәфле рәисе. Гомере буе татар халкының хокукларын яклап, татарны дәүләтле итү теләге белән яшәде. Төньяк Манчжуриядәге Хайлар шәһәрендә гомер иткән татар зыялылары гаиләсендә туган.

Ул 93 яшендә чит илдә (Төркиядә) вафат булды. Кыямәт көнендә җәннәт фәрештәләре каршы алсын!

АКЧУРА ЙОСЫФ (1876-1935)

Мәшһүр татар тарихчысы, журналист, иганәче һәм сәясәтче. Сембер шәһәрендә бай татар сәүдәгәре гаиләсендә туган.

Төркия Президенты Мостафа Ататөрекнең ярдәмчесе, профессор, Төркия Милли Мәҗлесе депутаты (1923-1935).

Ватанынннан читтә – Истанбулда вафат була. Җәннәт әһеле булырга язсын!

АЛИМ АМДИ (1908-1942)

Кырымтатар шагыйре. Кырымдагы Адым-Чокрак авылында туган.

Илен саклаганда, 1942 елда һәлак була. Ә Совет хакимияте аның гаиләсен сөргенгә сөрә.

АЛИ ХӘМИТ (1919-?)

Гаскәри. Көнчыгыш Төркестан Республикасы гаскәренең албае (полковнигы). Казахстанның Лепсы пүчинкәсендә татар зыялылары гаиләсендә туган.

1943 елда хакимияткә каршы яшерен тәшкиләт оештыруда гаепләнеп, зинданга ябыла. Язмышы турында башка мәгълүмат юк. Рухы шат, урыны оҗмахта булсын!

АЛИМОВ ЭННАН (1912-1941)

Кырымтатар рәссамы, язучы. Карасу Базар янындагы Күперлек (хәзерге Черемисовка) авылында туган.

Донбассны саклау өчен барган сугышларда батырларча һәлак була. Ә Совет хакимияте шушы каһарманның гаиләсен сөргенгә җибәрә. Җәннәт әһеле булырга язсын!

АЛКИН ҖИҺАНГИР (1897-1919)

Болак арты Республикасын оештыручыларның берсе, милли азатлык хәрәкәтенең күренекле вәкиле. Казанда борынгы зыялы нәсел – Алкиннар гаиләсендә туган.

ГПУ тарафыннан кулга алына. Язмышы да, кабере дә билгесез. Рухы шат, урыны оҗмахта булсын!

АЛКИН ИЛЬЯС (1895-1937)

Икътисадчы, профессор, сәясәтче. Борынгы зыялы токым – Алкиннар гаиләсендә Казанда туган. Хәрби Шура рәисе, Болак арты Республикасы җитәкчеләреннән берсе.

1920 елда Ильяс Алкинны, Зәки Вәлидинең ярдәмчесе булган, дип, кулга алалар, Бутырка зинданына ябалар. Озак кына утырганнан соң, күренекле хәрби эшлеклене, гаебен исбатлый алмагач, иреккә чыгаралар.

1937 елда, нахакка гаепләп, Алкинны тагын кулга алалар һәм атып үтерәләр. Кабеленең кайдалыгы мәгълүм түгел. 1955 елда аклана.

Җәннәт әһеле булырга язсын!

АЛКИН СӘЕТГӘРӘЙ (1867-1919)

Хокукчы, титульный советник. Казан губернасының Мамадыш өязендәге Алкино авылында морза гаиләсендә туган.

Болгавыр 1919 елда юкка чыга.

АГИЕВ ФӘХРЕЛИСЛАМ (1887-1938)

Татар язучысы. Тамбов губернасының Тимникәү өязендәге Тениш авылында мулла гаиләсендә туган.

1937 елда гаепсезгә кулга алына һәм зинданда атып үтерелә. Урыны җәннәттә булсын!

АЛИШ АБДУЛЛА (1908-1944)

Татар язучысы. Казан губернасының Спас өязендәге Көек авылында урта хәлле игенче гаиләсендә туган.

Камалышта калып, фашистларга әсирлеккә эләгә. Муса Җәлил оештырган яшерен оешма эшендә катнаша. Яшерен оешманың эзенә төшкәч, фашистлар унбер татарны, шул хисаптан Абдулла Алишны да үлем җәзасына тарталар. Кабе∙ренең кайдалыгы билгесез. Җәннәт әһеле булырга язсын!

АМЕТ ҖӘҮДӘТ (1917-1995)

Кырымтатар язучысы. Кырымның Лимен авылында туган.

Бөек Ватан сугышында катнашкан. Җанын да, тәнен дә кызганмыйча, Советлар берлеген саклаган каһарман шәхес. Сугыштан исән-аман чыгып, туган авылына кайта.

Әмма кайту сөенечен кара кайгы алыштыра: Җәүдәт авылын танымый. Авылда һичкем юк, бары тик кыргыйлашкан ач этләр генә каңгырап йөри. Җаны-тәне белән саклаган Советлар иле аның гаиләсен, халкын, «сатлыкҗаннар», дип, Кырымнан сөргенгә куа. Батыр сугышчы, СССРны әллә ничә тапкыр әйләнеп чыгып, югалган гаиләсен эзли. Ачтан үләр дәрәҗәгә җиткән гаиләсен ул Урта Азиядә эзләп таба. Шулай итеп, батыр сугышчы Җәүдәт Ватаныннан сөрелгән гаиләсе янында калырга мәҗбүр була. Кырым татарларына туган җиргә кайтырга рөхсәт бирелми. Кабере дә чит-ят җирдә. Гүре нурлы булсын!

АМИТ ОСМАН (1910-1942)

Кырымтатар шагыйре. Кырым ярыматавында – Таврия губернасының Кизләү (Евпатория) янындагы Дениз Байа авылында туган.

Кырым фашистлар кулында калгач, ул яшерен оешмага керә һәм алман баскынчыларына каршы көрәшә башлый.

Гестапочылар яшерен оешманың эзенә төшәләр һәм Амит Османны атып үтерәләр. Ул Советлар иле өчен һәлак була, ә Совет хакимияте аның гаиләсен ач үлемгә – сөрген газабына дучар итә. Урыны җәннәттә булсын!

Безнең мирас №10 октябрь 2020

АПАНАЙ ГАБДУЛЛА (1862-1919)

Җәмәгать эшлеклесе, дин галиме, нашир һәм сәүдәгәр. Вятка губернасының Малмыж өязендәге Сасна авылында эре сәүдәгәр гаиләсендә туган.

Большевиклар аны 1919 елда кулга ала һәм атып үтерә. Кабере билгесез. Җәннәт әһеле булырга язсын!

АТЛАСИ҆ ҺАДИ (1876-1938)

Мәшһүр татар тарихчысы, сәясәтче һәм җәмәгать эшлеклесе.

1937 елда большевиклар, аңа яла ягып, советларга каршы яшерен оешма төзүдә гаепләп кулга алалар һәм атып үтерәләр. Кабере билгесез. Урыны җәннәттә булсын!

АТНАШ ӘХӘТ (1912-1944)

Казахстандагы Кызылъяр шәһәрендә татар гаиләсендә туган.

Ватан сугышында чолганышта калып, әсирлеккә эләгә. Фашистларга каршы көрәшүче яшерен оешмага керә һәм ул фаш ителгәч, гитлерчылар тарафыннан үтерелә. Җәннәткә ирешергә язсын!

ӘБЛИЕВ МӨХӘММӘТ (1900-1941)

Татар язучысы, драматург, хәрби комиссар. Татарстанның Кама Тамагы төбәгендәге Даныш авылында ярлы игенче гаиләсендә туган.

Мөхәммәт Әблиев сугышның беренче көннәреннән үк алгы сызыкта сугыша һәм шунда һәлак була. Урыны җәннәттә булсын!

ӘДҺӘМОВА СӘРВӘР (1901-1978)

Татар язучысы. Чиләбе өлкәсенең Җаек шәһәрендә мөгаллимнәр гаиләсендә туган.

Сәрвәр ханым, татар язучысы Кави Нәҗминең хатыны буларак, төрмәгә ябыла. Бер елдан соң азат ителә.

ӘМИНЕВ ӘХТӘМ (1918-1942)

Татар шагыйре. Башкортстанның Миякә төбәгендәге Әнәч авылында игенче гаиләсендә туган.

Ул Калуга өлкәсенең Мещовск шәһәре янында барган сугышларда каты яралана һәм сугыш кырында вафат була. Урыны җәннәттә булсын!

ӘЛМӨХӘММӘТОВ ГАЗИЗ (1895-1938)

Опера җырчысы. Газиз Әлмөхәммәтовны кулга алу өчен Мәскәүдән Г.Маленков үзе килә. Бу турыда Галия Кайбицкаяга Салих Батыев сөйләгән.

ӘМИРХАН ФАТИХ (1886-1926)

Казан шәһәрендә зыялылар гаиләсендә туган. Драматург, тәнкыйтьче.

1923 елда большевиклар иң беренче Фатих Әмирханга ябырыла: ул «череп таркалган буржуа» дип игълан ителә. Кабере Казан зиратында. Җәннәт әһелләреннән булырга язсын!

ӘМИР МИРСӘЙ (1907-1980)

Татар әдибе, драматургы. Башкортстанның Эстәрлетамак өязендәге Җиргән авылында игенче гаиләсендә туган.

Мирсәй Әмир дә совет төрмәсенең баландасын татый. Аны да, кулга алып, гаепсезгә бер ел утыртып чыгаралар.

ӘХМӘТГАЛИЕВ МӨХӘММӘТ (1920-1943)

Татар язучысы. Казан шәһәрендә эшче гаиләсендә туган.

Смоленск шәһәре тирәсендә барган каты сугыш вакытында һәлак була. Урыны җәннәттә булсын!

*Текстны басмага **Рабит Батулла** әзерләде.*

Безнең мирас №10 октябрь 2020

Зөлфәт

Роза Туфитуллова

Яшьлек, студент елларын искә төшерә башласам, һәрчак күз алдыма шагыйрь дусларым – Зөлфәт белән Мөдәррис Әгъләмов килеп баса. Ул чакта университет даирәләрендә һәр төркемнең потенциалы андагы шагыйрь, язучы яки сәләтле җаннарның саны белән исәпләнә торган иде. Зөлфәт белән Мөдәррис – беренче курста, без – икенчедә. «Без сезнең группаны талантлар хәзинәсе дип уйлаган идек. Үкчәгезгә бастылар, – диде укытучыларның берсе. – Быелгы группа иҗади шәхесләргә тагы да баерак». Әйе, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмов, Рафаэль Хуҗин, Фәрит Гыйльми, Нур Әхмәдиев... Тагы әллә кемнәр. «Мин – шагыйрь!» – дип, күкрәк киереп йөри торган егетләр. Барысы да яшь, горур! Һәр икенчесе – Байрон! Алар арасында үзенең ярсу холкы белән аерылып торучы Зөлфәт бигрәк тә күзгә ташлана. Нечкә муен, маңгай тулы бөдрәләр. Ябык бит урталарында, ут чәчеп, ике зәңгәр күз янып тора. Ә тавышы, йөреше?!. Юк, йөреше түгел, очышы. Әйтерсең, аңа ике канат куелган. Әмма ул үзен шулкадәр гади итеп тота ки, син инде аны бер йөз еллап беләм дип уйлыйсың.

Зөлфәт – Мөслим ягы егете. Ул үги ана кул астында тәрбияләнгән, ләкин ялгыш кына да үги анасына тел тидерми. «Безнең әти кебек авыр холыклы кешегә ничә бала өстенә кияүгә чыгарга ничек җөрьәт иткәндер», – дип гаҗәпләнә. Ул, мөгаен, тумыштан ук шагыйрь булып тугандыр. Әгәр шулай булмаса, бу чаклы шигъри ялкын кайлардан килсен икән?!. Зөлфәтнең данлыклы Тукай клубында ярсый-ярсый, бөдрәләрен селки-селки шигырь сөйләүләре бүгенгедәй хәтеремдә. Көчле тавыш! Күкрәк тулы соло. Янәшәсендә аңа мөкиббән китеп йөрүче – университетның журналистика бүлеге студенткасы, авар кызы Римма. Ул ничек Казанга килеп эләккәндер, монысы бер Ходайга гына мәгълүм. Әйтүләренә караганда, кыз атаклы Дагстан шагыйре Расул Гамзатовның туган тиешлесе (?) икән. Үзе дә шигырьләр яза, ди. Кызның, Зөлфәттән бер

адым да калмыйча, аңа тагылып йөрүе, әлбәттә, күпләрне гаҗәпләндерә: шундый сөйкемле, карап туйгысыз яшь шагыйрь янәшәсендә ничек инде чит-ят җирдән килгән ниндидер кыз йөрергә тиеш?! Күркәм кыяфәтле, төскә-биткә чибәрлеге булса, бер хәл иде.

– Аптырама. Ул кыз шагыйрьнең күңелен яулый белә, – диделәр миңа Зөлфәтнең сабакташ кызлары. – Син, бер вакыт табып, тулай торакның беренче каттагы кухнясына кагылып кит. Зөлфәт өчен анда махсус Кавказ ашлары әзерләнә.

Кагылдым. Авар кызы мине шундый эчкерсез бер елмаю белән каршы алды ки, миңа хәтта уңайсыз булып китте. Чынлап та, авар кызы пешергән ашлардан тулай торакка таралган хуш исләрне берни белән дә чагыштырырлык түгел иде. Бу ашларны авыз итмәү гөнаһ булыр иде. Юк, шулай да хикмәт монда аш-суда гына түгел. Хикмәт кызның шагыйранә җанында. Ул Зөлфәтнең шагыйрьлегенә гашыйк. Алар без белмәгән телдә – күкләр телендә сөйләшәләр. Мондый саф хисләр алдында баш ими калу мөмкинме соң?! Шушы көннән без экзотик авар кызы белән дустанә мөнәсәбәттә йөри башладык. Ләкин ул Казанда озак тоткарланмады. Икенче курсны тәмамлагач, бөтенләйгә Кавказына кайтып китте. Дөресрәге, үз халкының йолаларын үтәп, туганнары аны кемгәдер кияүгә биргән.

Зөлфәт исә соңрак чын мәхәббәтен, үзенә насыйп ярын – Казан кызы Фираяны очратты. Ул шагыйрьнең эчкерсез җандашы, тормышында зур таянычы булды. Зөлфәтнең «Сөю мәңгелек» дигән үлемсез шигъри юллары аңа багышланган.

Студент елларының онытылмас вакыйгаларыннан тагын берсен искә төшерми кала алмыйм. Узган гасырның 60 нчы еллары ахыры. Язучыларның чираттагы съездында безнең университет егетләре, яшьләр өчен махсус журнал булдыруны таләп итеп, Г.Камал театрының балкон һәм бельэтажларыннан залга листовкалар яудырды. Егетләрне минуты-секунды белән тотып алып, «Черек Күл»гә алып киттеләр. Алар арасында Зөлфәт тә бар иде. Бу вакыйга безнең барыбызны да борчуга салды. Һәрчак гөрләп торган тулай торагыбыз шомланып, моңсуланып калды.

Ул чакта төнлә горур кыяфәт белән тулай торакка кайтып кергән егетләрне каршылау әйтеп бетергесез сөенеч булган иде. Әйе, безнең буынга да эләкте әле ул иҗат кешеләрен эзәрлекләү.

Зөлфәткә дә шактый вакытлар әлеге билгеле оешма күзәтүе астында яшәп иҗат итәргә туры килде. Мәскәүдә югары әдәбият курсларын тәмамлап, Казанга әйләнеп кайткач, аның озак кына эш таба алмый йөрүен шуның белән аңлатып буладыр. Нәкъ шул елны (1977) мине татар балалары өчен нәшер ителә торган «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газетасының баш редакторы итеп билгеләп куйдылар. Зөлфәтнең эшсез йөрүен ишеткәч, мин аны, вакытлыча булса да, үзебезнең редакциягә эшкә чакырырга булдым. Редакциядә аның эшкә алынуы турында приказ бирелгәннең икенче көнендә үк әлеге билгеле оешманың вәкиле килеп тә җитте.

– Приказыгызны үзгәртергә туры килер! – диде ул миңа, катгый итеп.

Күреп торам: мин китергән дәлилләр аны бөтенләй кызыксындырмый. Зөлфәт шикелле үк бөдрә чәчле, ачык

«

Зөлфәт исә соңрак чын мәхәббәтен, үзенә насыйп ярын – Казан кызы Фираяны очратты. Ул шагыйрьнең эчкерсез җандашы, тормышында зур таянычы булды. Зөлфәтнең «Сөю мәңгелек» дигән үлемсез шигъри юллары аңа багышланган.

Рәсемдә (беренче рәттә сулдан уңга): Николай Седов, Саимә Ибраһимова, Хәсән Туфан, Мөнҗия апа, артта уртада – Х.Туфан туганнары, Зөлфәт, Роза Туфитуллова. «Яшь ленинчы». 10 декабрь, 1980 ел. *Н.Седов фотосы*

йөзле татар кешесе югыйсә. Партия өлкә комитетының матбугат секторы җитәкчесе Мөхәммәт ага Мозаффаров ярдәмгә килмәсә, әлеге вакыйга ни белән тәмамланган булыр иде, әйтүе кыен... Аның үтемле сүзе, зур абруе барысын да хәл итте. Шулай итеп, Зөлфәт безнең редакциядә эшләп калды. Гомумән, ул чорда безнең бәләкәй генә газета тирәсендә гаҗәеп бер иҗади мохит барлыкка килде. Романтик рухлы Зөлфәт, үзенә хас бер кайнарлык белән, газетабыз битләрендә фантазиягә, әкият һәм юморга юл ачып җибәрде. Әкият дигәннән, хәтердә тагын бер истәлекле вакыйга җанлана. 1979 елның җәй азагы. Мин «Комсомольская Правда» газетасында басылган кечкенә генә бер хәбәргә юлыгам. Мәскәүдәге «Планета» нәшриятына Италиянең атаклы балалар язучысы Джанни Родари киләсе икән. Күрә торып мондый мөмкинлекне кулдан ычкындырырга ярыймы соң?! Кичекмәстән Зөлфәтне Мәскәүгә җибәрергә карар кылам. «Планета» нәшрияты җитәкчеләренә ялына-ялвара торгач, рөхсәт алына.

> **«Гомумән, ул чорда безнең бәләкәй генә газета тирәсендә гаҗәеп бер иҗади мохит барлыкка килде. Романтик рухлы Зөлфәт, үзенә хас бер кайнарлык белән, газетабыз битләрендә фантазиягә, әкият һәм юморга юл ачып җибәрде.**

Ике талант иясе, күптәнге танышлар сыман, «Космос» кунакханәсендә очраша.

– Әкиятченең тәрҗемәчесе килеп җиткәнче, ул – итальянча, мин татарча сөйләдем. Ни гаҗәп, ул бик тиз минем шагыйрь булуымны ачыклый алды, – дип сөйләгән иде Зөлфәт, очрашудан кайткач. Әйе, әлеге очрашу газета укучыларыбыз өчен дә онытырлык булмады. «Йөрәкләрдә үлмәс дастан» поэмасын Зөлфәт берничә көн эчендә иҗат итте:

Әкияти хисең саумы, кешем, җанда?
Җуймадыңмы Җирдән күчкән тылсым көчең?
Әкиятне җую — кешелекне җую.
Әфсен-төфсен!

Ничаклы сер, тылсым бу сүзләрдә! Нинди аһәң! Ә бит җирдә кешелекнең үзенә дә ничәмә-ничә кат җил-давылларга каршы торырга туры килде. Зөлфәт шигъриятнең төп эчтәлеге ватанпәрвәрлек, илне сөю, аның мәнфәгате өчен үзеңне аямау, югарылык, эрелек, сафлык иде. Шуңа сөенәм: без, аның хезмәттәшләре, фикердәшләре, шагыйрьнең кабатланмас иҗатына үз бәябезне бирә килдек. Аның һәрбер уңышына сөендек. Комсомол Үзәк Комитеты газетабызны Балтыйк буе республикалары һәм Польша буйлап сәяхәт итүче «Дуслык» поездына юллама белән бүләкләгәч, әлеге сәяхәткә сөенә-сөенә Зөлфәтне җибәрдек. Бу сәяхәт аның тормышында Европага бердәнбер сәяхәт булып кереп калды.

Шагыйрьнең кандидатурасы Татарстан комсомолының М.Җәлил бүләгенә тәкъдим ителгәч исә, үзебезнең катгый сүзебезне әйтә алдык. (Комсомол Өлкә комитетында аның кандидатурасын төшереп калдыру турында сүз барды.)

Зөлфәт белән дуслыгыбыз «Яшь ленинчы» газетасыннан киткәч тә дәвам итте. Без аның белән күрше редакцияләрдә эшли башладык. Ул – «Чаян»да, ә мин – «Азат хатын» (хәзерге «Сөембикә») редакциясендә. Бер генә көн дә күрешмичә, хәл-әхвәл сорашмыйча калмый идек. Сүзебез әдәбият, күбрәк шигърият тирәсендә бара. Дөнья поэзиясе яңалыкларын миңа һәрчак ул җиткерә иде. Күпме гомер бер даирәдә эшләп, Зөлфәттән берәү турында да яман сүз, хәтта гайбәткә охшашлысын да ишеткәнем булмады. Гаять дәрәҗәдә намуслы, саф йөрәкле кеше иде ул. Аның бик иртә сүнеп баруын күрү йөрәкне нык теткәләде.

Шагыйрь җанының илаһи югарылыктагы халәтен тотып кала алмасмы дип, мин Санкт-Петербургтан килгән танышым, талантлы рәссам Рәшит Гыйләҗевтән Зөлфәтнең портретын ясавын үтендем. Ул инде нык авырый иде, шуңа бу эшкә озак кына ризалашмый торды. Әмма рәссам аны, ничектер, күндерә алды. Зөлфәтнең нечкә җанын ачып бирердәй төсләрен дә тиз тапты ул. Бу ике талант иясен очраштыра алуыма әле дә сөенеп туя алмыйм. Портреттагы ялкынлы шагыйрь образы нәкъ без белгән, без яраткан, без горурланган Зөлфәт иде. ■

Редакциядән: *Хөрмәтле каләмдәшебез һәм авторыбыз Роза Рәхмәтулла кызы Туфитуллованың 17 октябрьдә гомер бәйрәме. Аны шушы истәлекле көн белән ихластан котлап, сәламәтлек, иминлек һәм иҗат уңышлары теләп калабыз!*

Безнең мирас №10 октябрь 2020

Батулла музее

Ләбиб Лерон

Туймазыдан – Ык буе авылларына нисбәтле фәнни-гамәли конференциядән кайтып килгән чакта, тарихчы, галим, төбәкче Нурулла Гарифның сүзләре мине сагайткан иде:

– Киләчәктә музейлар шәхси кулларга калыр дип уйлыйм!

Август ахырында Биектау районындагы Чыршылы авылына баргач, җәйләрен шундагы йортында яшәүче Рабит абый Батулланың шәхси музее белән танышып йөргән вакытта, туган авылында – Балык Бистәсе районындагы Яңа Салада үз көче белән музей оештырган Нурулла Гарифның сүзләре кабат исемә төште дә, янә шөбһәле уйларга бирелдем...

Элекке хуҗасыннан сатып алган сигез почмаклы йортта гаиләсе белән ундүрт ел чамасы яшәгәч, Рабит ага шул йорт янәшәсендә яңа йорт җиткезә дә искесен музейга әверелдерә. Аксакал әдип туплаган экспонатлар арасында ниләр генә юк: иске гармуннар, төрледән-төрле бихисап тастымаллар һәм сөлгеләр, алсузмалар, түрләмәләр, кубызлар, курайлар, сыбызгылар, эш кораллары, көнкүреш кирәк-яраклары...

Музыка уен коралларының барысы да тәртиптә: музей «мөдире», ягъни музейның чын мәгънәсендәге хуҗасы Рабит ага аларның һәммәсендә дә уйнап күрсәтә. Барысының да үз тарихы бар. Менә бу – саратский гармун, аның янәшәсендә могтабәр язучыбызның әтисе Мөхлисулланың хромкасы, шунда

ук вараксин (аның иясе – яудан ике аяксыз кайткан фронтовик-мөгаллим Мөхәммәтмирза Ибраһимов (шагыйрь Мөхәммәт Мирзаның, ягъни Илфак Ибраһимовның әтисе))...

Кыскасы, халкыбызның яшәеше хәлкадәри чагылдырылган әлеге музейда хәйран-вәйран булып йөрдем һәм... Нурулла Гариф сүзләрен тагы искә төшердем:

– Киләчәктә музейлар шәхси кулларга калыр дип уйлыйм!

Шулай булуы бик мөмкин бит, җәмәгать!

Кайбер җитәкчеләребез үткәнебезгә, тарихыбызга битараф караш, мирасыбызга тискәре мөнәсәбәт күрсәткәндә, нәкъ шулай булачак та.

Рабит аганың әлеге шәхси музеенда Биектау районының хакиме дә булып киткән икән. Шактый янтайган, җиргә иңә төшкән музей-йортны карагач, ул яраннарына авыл уртасындагы бер таш бинаны яңартып, Батулла ага җыйган-туплаган ядкяр-истәлекләрне шунда күчерергә дигән күрсәтмә дә биргән, имеш!

Мәсьәлә уңай хәл ителсә, бик шәп булыр иде дә бит, ләкин бездә кайвакыт «эт – эткә, эт – койрыкка» принцибы белән яшәгәнгә күрә, бу эшнең барып чыкмавы да ихтимал...

Вәләкин Батулла ага өметен өзми: Биектауда булмаса, бәлки, туган ягы Зәйдә аның музее язмышын уңай хәл итәрдәй җитәкче шәхес табылыр?!. Кем белә, шагыйрь әйтмешли, дөнья бит бу!

P.S. Киләчәктә шәхси музейлар булыр, иншәАлла. Эшләр шуңа таба бара. Әмма дәүләт, минемчә, үз карамагындагылар белән бергә, андый музейларга да ярдәм итәргә тиеш.

2020 елның 24 сентябре ■

Халык иҗаты хәзинәләре

«Сәйдәш» мәдәният үзәгендә «Халык иҗаты хәзинәләре» исемле күргәзмә эшли. *Анда Татарстан халыкларының традицион һөнәрләре, музыка уен кораллары, милли киемнәре белән танышырга мөмкин. Проектны РФ Мәдәният министрлыгы ярдәме белән Казан шәһәре башкарма комитетының мәдәният идарәсе, «Сафьян» һөнәрчелекне үстерү һәм фольклорны өйрәнү үзәге (җитәкчесе –* ***Фәнзилә Хәкимулла кызы Җәүһәрова****) оештырды.*

Илдар Шакиров һәм Ләйлә Лерон фотолары

Безнең мирас №10 октябрь 2020

Истә, һаман да истә!

Җырчы
Рәхилә Мифтахованың
тууына 80 ел

Опера җырчысы, РСФСРның атказанган (1981), Татарстан Республикасының халык артисты (1993) Рәхилә Хәйдәр кызы Мифтахова 1940 елның 7 октябрендә Каракалпак АССРның Хуҗайлы каласында туган. 1946 елда аларның гаиләсе Пермь шәһәренә күчеп килә. Рәхилә мәктәпне шунда тәмамлый.

Операда җырлаудан тыш, Р.Мифтахова С.Сәйдәшев, М.Мозаффаров, А.Вәлиуллин, Н.Җиһанов, Р.Яхин романсларын һәм Г.Тукай сүзләренә язылган җырларны югары кимәлдә башкарды.

Җырчы 2000 (кайбер чыганакларда – 1999) елның 8 гыйнварында вафат булды.

Әдип
Җәүдәт Дәрзаманның
тууына 75 ел

Балалар язучысы, шагыйрь һәм прозаик, 1982 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Язучылар берлегенең А.Алиш исемендәге әдәби премиясе лауреаты Җәүдәт Харис улы Дәрзаманов (Җәүдәт Дәрзаман) 1945 елның 13 октябрендә ТАССРның Лениногорск районындагы Сугышлы авылында туган.

Җәүдәт Дәрзаманның беренче шигырьләре әүвәл Лениногорск район газетасында дөнья күрә. 1961 елда язучы Җәвад Тәрҗемановның сүз башы белән «Яшь ленинчы» газетасында шигырьләр циклы басылып чыга. Әдипнең кайбер китаплары: «Ирбатыр» (1975), «Солдат булдым» (1977), «Төнге маҗара» (1980), «Гөлназ мәктәпкә бара» (1983), «Безнең әлифба»(1985) һ.б.

Җ.Дәрзаман 2019 елның 25 февралендә вафат булды.

Тарихчы
Әгъдәс Борһановның
тууына 100 ел

Тарихчы, тарих фәннәре докторы, Татарстан Фәннәр академиясенең шәрәфле әгъзасы, профессор Әгъдәс Хөсәен улы Борһанов 1920 елның 17 октябрендә Бөгелмә өязендәге Сарабиккол (хәзер Лениногорск районына керә) авылында туган.

Хезмәтләре Россиядә 20 нче йөз башы буржуаз юнәлешле сәяси партияләр эшчәнлегенә, 1917 елгы Октябрь революциясе тарихына, философиягә, хәзерге заман милли мөнәсәбәтләргә һәм милли-мәдәни автономия мәсьәләсенә карый.

Ә.Борһановның татарларның милли бәйсезлек хәрәкәтенә багышланган мәкаләләре бар. Татар иҗтимагый үзәгенең I корылтаенда (1989 ел), 2002 елда III Бөтендөнья татар конгрессында ул Мәскәү татарларыннан делегат буларак катнашты.

Ә.Борһанов 2018 елның 8 ноябрендә вафат булды.

Шагыйрә
Заһидә Бурнашеваның
тууына 125 ел

Шагыйрә һәм җәмәгать эшлеклесе Заһидә Хөсәен кызы Бурнашева (әдәби псевдонимы – Гыйффәт туташ) 1895 елның 19 октябрендә Рязань губернасындагы Әҗе авылында туган.

1913-1914 нче елларда Гаяз Исхакый нәшерендә чыккан «Ил» газетасында беренче шигырьләре басыла башлый, ә «Гыйффәт туташ шигырьләре» дигән беренче җыентыгы 1915 елда дөнья күрә. 1919 елда шагыйрәнең «Балалар күңеле» дигән китабы нәшер ителә.

Октябрь инкыйлабыннан соң З.Бурнашева Сәмәркандта яши. Берничә ел партиянең Төркестан Үзәк Комитетында, аннан соң Үзбәкстан китап нәшриятында эшләп ала. 1951 елдан соңгы көненәчә Казанда гомер итә.

Шагыйрә Казанда 1977 елның 5 ноябрендә 82 яшендә вафат булды.

Язучы
Вахит Юнысовның
тууына 90 ел

Язучы һәм публицист, Халыкара ПЕН-клубның Татар ПЕН-үзәге әгъзасы, 1992 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Вахит Закир улы Юнысов (күренекле әдип Миргазиян Юнысның (1927-2014) бертуган энесе, Россия эстрадасы җырчысы Тиматиның бабасы) 1930 елның 20 октябрендә Баулы районының Исергәп авылында туган.

1953 елда В.Юныс – СССР Тышкы эшләр министрлыгының Мәскәү дәүләт Халыкара мөнәсәбәтләр институтына укырга керә. Аны тәмамлагач, озак еллар Гыйрак, Мисыр, Әфганстан, Сүрия кебек шәркый илләрдәге СССР илчелекләрендә хезмәт итә.

2001 елда Татарстан китап нәшриятында аның «6000 көн чит илләрдә» дигән китабы басылып чыга.

Язучы 2006 елның 15 октябрендә Мәскәүдә вафат булды һәм туган авылы Исергәп зиратында җирләнде.

Актриса
Роза Җиһаншинаның
тууына 90 ел

Актриса, ТАССРның атказанган артисты Роза Мөхәммәтулла кызы Җиһаншина 1930 елның 27 октябрендә Пермь өлкәсенең Шучье Озеро районындагы Урәзмәт авылында укытучы гаиләсендә туган.

1947 елда ул Казан театр училищесына укырга керә. 1951 елда аны тәмамлап, Минзәлә театрында эшли башлый.

Үзенең озын иҗат гомерендә татар, рус һәм чит ил классик драматурглары әсәрләреннән уңышлы образлар галереясын иҗат итә. Шулар арасында: Аннушка (А.Островский, «Гаепсездән гаеплеләр»), Малай (К.Тинчурин, «Зәңгәр шәл»), Аннуш (Н.Арбан, «Кара бүре»), Зорька (Б.Нушич, «Иң гади кеше»), Сара (Ә.Гаффар, «Язлар моңы»), Хәерниса (Р.Ишморат, «Хикмәтле Сәйфи») һ.б.

Актриса 2014 елның 23 сентябрендә вафат булды. ■

Сәхифәне ***Ләбиб Лерон*** *әзерләде.*

Борынгы татар милли музыка уен кораллары

Ринат Гыйләҗев, «Сорнай» фольклор ансамбленең сәнгать җитәкчесе

«Сорнай» фольклор ансамбле

1990 нчы елларга кадәр татар фольклор коллективлары аулак өй, кич утыру, төрле өмә, туй күренешләренә күбрәк игътибар итәләр иде. Хәзерлекле ансамбль җитәкчеләренең булмавы сәбәплеме, тарих белән бәйле тематика – Болгар чоры, Алтын Урда гел читтә калып килде. Аннан соң без ул елларда инде бөтенләй онытылып беткән җәя-кубыз, шаман бубены, сугыш быргысы, аучы быргысы, таш сыбызгы, давылбаз кебек тагын да борынгырак чорларга караган уен коралларын таптык. Һәм аларны, ниндидер бер тарихи мизгелгә туры китереп, сәхнәдән ничектер күрсәтергә кирәк иде. Эзләнә торгач, «Сорнай» ансамбле халкыбызның шушы риваятенә тукталды.

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2019) санында.

Гүзәл болан кызы һәм аучы Мәргән риваяте

Сәхнә караңгы. Ут арткы пәрдәне генә яктырта. Пәрдә ачылганда, еракта дөңгер (шаман бубены) тавышы ишетелә. 7-8 кешедән торган ансамбль сәхнәдә тезелеп баскан.

1. Мәңгелек күк

Алып баручы шушы фонда текст укый. Текст барышында аучы яки шул чорның сугыш киемнәрен кигән музыкантлар, бер-бер артлы сугыш быргысында хәбәр биреп, бубеннарда тарихи ритмнар, көпшә курайда, таш сыбызгыда төрле кош сайраулары, бүре улаган тавышлар чыгаралар. Шушы урында без беренче тапкыр, озак еллар онытылып торганнан соң, яңадан өйрәнеп, үзләү (тамак белән җырлау) алымын кулландык. Музыка текст беткәнче дәвам итә.

Текст. (Аларны сәхнә артыннан микрофонга укырга яисә сәхнә түренә куелган экранга язарга мөмкин.) Иксез-чиксез бөек Туран илендә минем әби-бабаларым яшәгән. Алардан безгә мирас булып җыр-бию, гореф-гадәтләребез, уен коралларыбыз калган. Гүзәл болан кыз һәм аучы Мәргән риваяте дә, тарих пәрдәсен ертып, безнең көннәргә кадәр килеп җиткән.

1 нче егет. Чал тарих, ишетәсеңме?

2 нче егет. Бабаларым, тыңлыйсызмы?

Бергә. Без сезне онытмадык!

Кыз. Әй, киң Туран дәрьясы!

Егет. Идел-Урал арасы!

Кыз. Алтай-Болгар баласы!

Бергә. Без исә-ә-ән!

Аз гына пауза. Ритм алышына. Дәртле музыка башлана. Марс Макаровның «Туй бию»е көе. Бер куплет курайда һәм думбрада уйнаганнан соң, егетләр тиз генә кулларына җәя алалар. Ике егет, бер аякта тезләнеп, җәяләрдә ритм уйный башлый. Өченче егет, садагыннан ук алып, ату хәрәкәтләре ясый һәм шулай ук тезләнеп, җәя-кубызда сызып уйный башлый. Биредә скрипканың сызгычын ук итеп ясасаң, отышлырак була. Бу урында безнең максат җәя-кубызларның уйнау мөмкинлекләрен күрсәтү иде.

Сәхнәдә ут караңгылана. Тиз генә декорация алышына. Урман аланы. Кошлар сайрый. Ут урман аланында утырган болан кызын яктырта.

2. Вокализ

Вокализ барышында болан кызлар, аларны аулаучы аучылар ара-тирә сәхнә аша йөгерешеп узалар. Вокализга музыкаль озатылышны таш сыбызгы (окарина) белән ике тавышка башкардык. Бик сихри музыка килеп чыкты. Акрынлап болан кызы янына башка болан кызлары да җыйнала.

Текст. Борын-борын заманда яшәгән, ди, бер аучы. Ул киек җәнлекләрнең, кошларның телләрен аңлаган, алар белән сөйләшә белгән. Көннәрдән беркөнне аучы Мәргән, сукмаксыз җирдән сукмак салып, кыядан-кыяга сикереп ауга чыга.

3. Болан кызларының биюе

Бию бетүгә, аучы егетләр болан кызларын чолгап алалар. Боланнар качарга тели.

4. Аучылар һәм болан кызлары биюе

Бию беткәндә, боланнар хәйләләп качалар. Аучылар аларны куып китә. Җик-Мәргән сәхнәдә кала.

Җик. Күпме ауга йөреп, мондый матур һәм хәйләкәр боланны күргәнем юк иде.

Ямансулап, сумкасыннан аучы быргысын ала һәм болан тавышына охшатып кычкыртып җибәрә.

5. Хәбәр

Ике-өч тапкыр хәбәр музыкасын уйнагач, экранда кыяда басып торган болан рәсеме күренә.

Җик. Әй, син, болан баласы,
Тау-кыялар күрке син,
Әй, син, җиһан баласы,
Алиһәдәй гүзәл син.

Кураен ала: ямансулап уйнап, җырлап җибәрә.

Яшәү өчен рәхимсез көрәш барышында туган ир-егет җыры шулай ук әллә ни күп түгел. Эзләнә торгач, татар шагыйре С.Рәмиевнең бик мәгънәле шушы сүзләренә тукталдык. Аны беренче тапкыр татар эстрадасының талантлы җырчысы Илшат Вәлиев башкарды.

6. Сызла, күң(е)лем

Сызлыйдыр ла күң(е)лем, әй, сызлыйдыр,
Сызлый бертуктамыйча.
Сызлый айлар, сызлый еллар,
Сызлый төн йокламыйча.
Сызлыйдыр ла күң(е)лем, әй, мәхәббәт,
Ялкыннан гөлләр яса.
Мәңге хәсрәт һәм кара төн
Елларын ямьле яса.

Ул җырлап бетергәндә, сәхнә артыннан бер кыз чыга һәм акрын гына көлә. Җик кыз янына килә.

Җик. Нигә көләсең, чибәр кыз?

Кыз. Шатлыгымнан.

Җик. Нинди шатлыгың бар синең, гүзәл кыз?

Кыз. Бала вакытымда явыз хан илебезне басып алгач, мин урман-таулар арасына качып котылдым. Боланнар белән үсеп, үзем дә боланга әйләнгәнмен. Мине дәвалап та, өшкереп тә карадылар. Әмма файдасы тимәде. Тик илебезнең бер карты: «Бу кыз бала яңадан адәм сыйфатына кайтсын өчен, үзе яраткан батыр егет болан телендә хикмәтле сүз әйтергә тиеш», – дигән иде. Мин синнән бүген шул сүзне ишеттем, батыр егет, батыр егет, батыр еге-е-ет (гасырлардан яңгырап ишетелә). Аннан соң инде егет белән кыз арасында җырлап сөйләшү башлана.

7. «Тау кызы» (дуэт)

– Тау кызы, аччы йөзең, бән керәем,
Йөзләреңнең ниндилеген бер күрәем.
– Йөзләремнең ниндилеген белмисеңме,
Аяз төндә тулган айны күрмисеңме?
– Тау кызы, аччы йөзең, бән керәем,
Күзләреңнең ниндилеген бер күрәем.
– Күзләремнең ниндилеген белмисеңме,
Ай янында рушан йолдыз күрмисеңме?

– Тау кызы, аччы йөзең, бән керәем,
Керфекләрең ниндилеген бер күрәем.
– Керфекләрем ниндилеген белмисеңме,
Җәяләргә салган укны күрмисеңме?
– Тау кызы, аччы йөзең, бән керәем,
Мине сөйсәң, мине дисәң, бер үбәем.
– Сине генә сөюемне сизмисеңме,
Гомер юлын бергә үтик, димисеңме?
Сине генә сөюемне белмисеңме?

Әлеге күренеш өчен җыр сайлаганда, иң беренче халкыбызның искиткеч шаян, тапкыр «Хан кызы» җырының сюжеты күз алдына килде. Егет белән кызның бер-берсен олылап, яратышып җырлана торган әлеге җыр – мәхәббәткә мәдхия ул.

Сәхнәгә, йөгерешеп, кыз-егетләр керә. Күмәк җырлы-биюле уен башлана. М.Нигъмәтҗанов һәм В.Исхакова хезмәтләрендә әлеге уенның берничә искиткеч гүзәл үрнәге бар.

8. Җөмбә буе Җөмбикә

Егетләр. Җөмбә буе Җөмбикә,
Җөмбикәгә ни кирәк?
Ярма-ярма бүз кирәк,
Инә белән җеп кирәк.
Ул инәне тотарга
Оста куллы кыз кирәк.

Кызлар. Вак-вак кына тәлинкә,
Җиргә төшсә уала.
Сезнең ише вак-төяккә
Кыз бирсәң дә, югала.

Егетләр. Ярма-ярма яр кирәк,
Яр булырлык кыз кирәк.
Кул-аягы төз кирәк,
Бир, әбекәй, кызыңны.

Кызлар. Күк ачарга ачкыч юк,
Ашка салыр тозым юк.
Иргә бирер кызым юк,
Кайтыгыз да китегез.

Егетләр. Күккә менәр баскыч бар,
Ашка салыр тозың бар.
Иргә бирер кызың бар,
Бир, әбекәй, кызыңны.

Кызлар. Күккә менәр баскыч бар,
Ашка салыр тозым бар.
Иргә бирер кызым бар,
Алыгыз да китегез.

Егетләр. Алабыз да китәбез!

Текст. Утыз көн уен, кырык көн туен ясап, хәзер дә бик бәхетле яшәп яталар, ди, болар.

Баш иргә чыгабыз. Исемнәрен әйткәч, һәр төркем уен коралларында уйнап күрсәтә һәм баш ия.

Ахыры киләсе санда ■

Татар дәүләт филармониясе 100 еллык ТАССР тарихында

Филармония солистлары

Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Георгий Ибушев

■ Татарстанның Мамадыш районындагы Владимир авылында туган;

■ Казан дәүләт консерваториясендә РСФСРның атказанган, ТАССРның халык артисты Әлфия Заһидуллина классын тәмамлый;

■ Тавышы – тенор-альтино;

■ 1985 елда Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең әдәби- музыкаль лекторий бүлегенә эшкә алына;

■ 1985 елда халык җырларын башкаручыларның Бөтенроссия бәйгесендә дипломант була;

■ 1986 елда Мәскәүнең Колонналы залында Г.Тукайның тууына 100 ел тулу уңаеннан узган тантаналы концертта СССРның халык артистлары И.Козловский, А.Соловьяненко һәм З.Соткилава белән чыгыш ясый;

■ 1990 елда С.Сайдәшев исемендәге вокалистлар бәйгесе лауреаты исемен яулый;

■ 1991 елда җырчыга «Татарстанның атказанган артисты» исеме бирелә;

■ 2000 елда ул «Татарстанның халык артисты» исеменә лаек була;

■ 2007 елда – Г.Ибушев шигырьләре тупланган «Рәхмәт сиңа, җыр», 2019 елда балачак истәлекләре тупланган «Балачакны сагынып...» җыентыклары чыга;

■ Георгий Ибушев репертуарында татар композиторлары С.Сәйдәшев, Р.Яхин, М.Мозаффаров, Җ.Фәйзи, Ә.Бакиров, Ф.Әхмәтов һәм Р.Еникеев әсәрләре, опералардан арияләр, романслар, чит ил композиторларының әсәрләре бар;

■ 2019 елда җырчы «Россиянең атказанган артисты» исеменә лаек була.

Казан консерваториясе янында: Георгий Ибушев, Әлфия Заһидуллина, Валентина Архипова. 1985 ел

Илһам Шакировның туган көн кичәсендә: Илһам Шакиров, Рөстәм Маликов, Георгий Ибушев. 2011 ел

Георгий Ибушев һәм концертмейстер Роман Чуйнов зур Концерт залы сәхнәсендә чыгыш ясый. 2001 ел

Журналга ***Зимфира Гыйльметдинова*** *әзерләде.* ■

Милләт

Раил Садриев

Ераграк киткән саен, вакыйгалардан тарих язарга җиңелрәк: анализларга, бәя бирергә һәм нәтиҗә ясарга... Ә бүгенге вакыйгаларга, аларның эчендә кайнаганда, анализ ясавы бик авыр.

Татарның соңгы үзгәрешләре узган гасырның 90 нчы елларында булды: Суверенитет турында декларация кабул итү, Президент сайлау, Дәүләт телләре турындагы канун, үз телебездә яңа газета-журналлар чыгара башлау... 90 нчы еллардагы үзгәрешләр булмаса, без тизрәк урыслашып беткән булыр идек. Ул чор күп мөмкинлекләр тудырды. Ә без алардан тулысынча файдалана алдыкмы – анысы башка мәсьәлә... Моңа тарих бәя бирәчәк. Барыбер шактый нәрсәләр эшләнелде. Алар бит инде Мәскәү күзәтеп торган чорда кылынган гамәлләр...

Моннан чыгып шуны әйтәсем килә: татарның язмышы соңгы 100-120 ел эчендә Россиядә һәм дөньяда булган кризисларга бәйле.

Боларга таянып, бер нәрсәне искәртеп үтәргә кирәк: XX гасыр башындагы татарны уятып җибәргән 1905-1906 нчы еллардагы буржуаз революциядән килеп чыккан ренессанс та шулай ук илдә булган кризиска нисбәтле. Тукайлар, Әмирханнар, беренче театр, газета-журналлар, китаплар бастыру, бер шаукым булып, иҗат белән шөгыльләнүче татар яшьләренең мәйданга чыгуы – болар барысы да халык

күңелендә өмет чаткылары уята. Моңа өстәп икенче кризисны – 1917 елгы Октябрь инкыйлабы турында да әйтәсе килә. Хәзерге чорның кайбер тәнкыйтьчеләре ду китереп сүксәләр дә, 70 еллап яшәгән Совет дәүләте татарга гына түгел, гомумән, Россия территориясендә яшәгән барлык халыкларның язмышына да зур этәргеч ясый. Әлбәттә, Ибсен әйтүе буенча, бер чорга 25-30 еллап вакыт кирә, бу милләтләрнең яшәешендә дә шулай: 1905, 1917 нче еллардагы кризис нәтиҗәсендә күтәрелеп киткән милләт (1941-1945 нче еллардагы Бөек Ватан сугышы аны тагын беразга кичектерә) узган гасырның 70-80 нче елларында кабат үзен югалту дәрәҗәсенә диярлек килеп җитә. (Казан мәктәпләрендә, вузларда, траспортта, кибетләрдә урамда, татарча сөйләшүләр оятка әйләнә башлый.) Шушы вакытта янә яңа кризис туа – илдә үзгәртеп корулар башлана: СССР дәүләте юкка чыга, илдә суверенитетлар парады башлана.

Хәзер тагын шундый кризис (ул инде дөньякүләм). Россиядәге атмосфера үзгәрешләр белән сугарылган. Ленин сүзләре белән әйтсәк, шундый ситуация туды: өстәгеләр элеккечә идарә итә, ә астагылар элеккечә яши алмый… Ельцин чорын үткән кеше буларак, инде андый кискен үзгәрешләрне күрәсе килми. Ул бик авыр чор. Революция – җәмгыятьнең астын-өскә китереп, идеалларны югалтып, бер дә уйламаган бөтенләй башка кешеләрне дөньякүләм сәхнәгә чыгара торган, кан коюга корылган зур бер кризис ул. Бу шул ук вакытта бүтән төрле мөмкинлекләр килеп чыгуын да искәртә.

Революцияләрсез, кан коюларсыз гына үзгәрешләр булып (ә алар, һичшиксез, барлыкка киләчәк), милләтнең язмышында яңа бер шанс-мөмкинлек туачак. Һәм татар бу форсаттан файдаланып калырга тиеш, чөнки моның Аллаһ биргән мөмкинлекләрнең соңгысы булуы ихтимал.

Россиянең киләчәге минем өчен бик өметле. Дөньядагы кризисларның, катаклизмнарның нинди тирән һәм озак баруына карамастан, бу Россиянең үзе өчен дә файдалы булачак. Дөньякүләм кыйммәтләрнең күбесе илебездә сакланып калачак. Мәсәлән, рухи байлык. Бу байлыкны бизмәннәргә салып үлчәп булмый. Минем фикеремчә, киләчәктә (10-15 ел эчендә) дөнья илләре Россия тирәсендә берләшәчәк. Алдагы 4-5 ел эчендә безнең буын югалта башлаган кыйммәтләр янәдән кире кайтачак. Шушы биш елда (аның ике-өч елы, әлбәттә, бик тә авыр булачак) Татарстан үзенең акыллы ул һәм кызларын, әдәбиятын һәм сәнгатен, телен, дәүләтен, гомумән, үзен саклап калырдай бөтен кыйммәтләрен мәйданга чыгарырга тиеш булачак.

Тарихның агышы шулай. Һәм шул мөмкинлекләрдән файдаланып калырга кирәк. Шушындый шартларда гына милләтнең иммунитеты ныгый, үзбилгеләнүе арта һәм шул рәвешле яшәеш алга китә башлый.

Безнең милләт тарих көзгесе алдында басып тора. Әлеге көзге артында көтеп торган чүкеч, аны айнытып җибәреп, йоклаган милли аңын уятып, киләсе йөз елга яшәеш куәтен арттырырга тиеш. Бу, әлбәттә, шанс һәм аннан файдаланып калырга кирәк.

Бүген татарны, телне саклап килгән нәрсәләр күп түгел: ул – аның әдәбияты, матбугаты, театры һәм эстрадасы. Иң мөһиме – тел. Тел сакланган урын ул, беренче чиратта, – театр, эстрада. Алар – авыр чорда телне, сәнгатьне саклап калган нәрсәләр. Ә сәхнәгә чыгарлык яшьләребез бүген бар. Алар, шушы вакыйгаларны кичәр өчен күпер булып, милләтебезнең киләчәккә юнәлешен билгеләүче, татарны саклауга зур өлеш кертүче шәхесләргә әверелергә тиешләр. Ул яшьләрнең кайберләре хәзергә пәрдә артында тора. Әлеге пәрдә ачылырга күп калмады… ■

Көлке куа килә...

Ф.Вахитов шаржы

Роберт Миңнуллин (1948-2020)

Татар һәм башкорт хоккейчылары

Салават Фәтхетдинов Уфада концертлар куйган вакытта «Салават Юлаев» белән «Ак барс» командаларының да чираттагы уены була. «Ак барс»ның фанаты Салават та җанатар булып катнаша. Икенче көнне дус-ишләре сорый икән:

– Салават, ничек уйнадылар, кемнәр җиңде?

– Татарларның финнары башкортларның чехларын җиңде! – дип җавап кайтара Салават, ике дә уйлап тормыйча.

Гамил Афзал (1921-2003)

Агай белән малай

Агай белән малайның кибеттән кайтып килеше. Малай ак калач күтәргән, агайның сумкасыннан төргәкләр һәм балык койрыгы күренеп тора. Малай бертуктаусыз тәтелди, агай теләр-теләмәс кенә бер-ике сүз әйтеп куя.

– Әти, нигә ул луна да ай, месяц та ай?

Агай җавап бирә:

– Луна ул, улым, күктәгесе, ул бик ерак, ул бик зур, ә месяцта утыз гына көн була.

– Әти, Альбертның әтисе гүләйт итә икән, ничек була ул гүләйт итү?

– Ярар инде, күп сөйләшмә!

– Әти, әйдә, без дә гүләйт итәбез!

– Житәр, димен сиңа!

– Әти, Маратның әтисе жулик.

– Кем әйтә аны?

– Малайлар әйтә.

– Хм...

– Әти, син жуликмы?

– Житәр, димен сиңа!

Агай белән малай кайтып бара. Малай ак күмәч күтәргән, агайның сумкасыннан балык койрыгы күренеп кайта.

Тәлгат Нәҗмиев (1950-2014)

Тукаймы әллә?

Сабадагы бер танышым узган Яңа елны танышларында алданрак «каршылаган». Уянып китсә, таң беленеп килә икән. Киенгән дә өенә чапкан. Менә ул икенче катка күтәрелә. Ишек шакый. Ачучы юк. Көтә. Шул арада хатыны шыпырт кына килә дә «глазок»тан карый һәм ишекне ачып китә. Шаулаган баш белән дустым моны сизми. Яман ачуы чыга моның, ирлеген күрсәтәсе килә. Шуннан соң ул... барлык көчен җыеп, бөтен гәүдәсе белән ишеккә китереп бәрә, ул ачылып китә, күршем коридор идәненә очып барып төшә. Хәле авыр була, әлбәттә. Шулай да телен көчкә әйләндереп: «Ишек төбендә күпме тотарга була ирне, Габдулла Тукаймы әллә мин сиңа...» – дип әйтеп куя.

Шамил Маннапов (1938-2012)

Бергә йоклаган хатын

Заманында Югары Совет рәисе Батыев кабинетына чибәр генә бер ханым килеп керә. Бик мөһим бер документка кул куйдырасы бар икән.

– Сез кем буласыз соң? – дип сорый Батыев.

Хатын энҗе тешләрен елтыратып елмая:

– Әллә оныттыгыз дамы?! Күптән түгел бергә йокладык ласа!

Батыев хатынның йөзенә җентекләбрәк карый. Юк, хәтерли алмый бу чәчби белән чуалганын. «Бәлки, булып та онытылган хәлдер, бәласеннән башаяк...» – дип уйлап чыгып барганда, туктатып сорыйсы итә:

– Шулай да әйтегез әле, без кайда, кайчан э-э-э... бергә... йокладык икән, ә?

Хатын көлеп җавап бирә:

– Шәһәр партактивы җыелышында ич. Сез президиумда йоклап утырдыгыз, ә мин – залда...

Фаил Шәфигуллин (1939-1982)

Кышкы иртәдә

– Әбәтегез тәмле булсын, Бәдернисаттәй!

– Бергә булсын... И... кара... танымый да торам, Фәгыйлә малае икән... Нихәл, нишләп йөрисең?

– Әни, оеткыга бер-ике кашык катык бирсен әле, дигән ие.

– Катыгым юк шул, акыллым...

– ?!

– Кар һаман явамы?

– Төшкәли.

– Анаң эшкә бармадымыни?

– Юк... Мунча ягабыз.

– Җизнәңнәр кайтмыйдыр ич?

– Юк.

– Атаң терелдеме инде?

– Терелде.

– Эшләмидер әле?

– Юк.

– Һе, һе, шулай диген... Катыгым юк шул, акыллым... Ашарга утыр, дисәм инде...

– Сал, булмаса, Бәдернисаттәй. Бик кыстагач, берәр тәлинкә ашармын. ■

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.*

СЕНТЯБРЬ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● Сентябрьдә тарихчы-галим Фәйзелхак Ислаевның Чирмешән районына нисбәтле «Югары Чагадай тарихы» дигән күләмле китабы «Яз» нәшриятында дөнья күрде.

● 1 сентябрьдә Казанда «Адымнар» күптелле белем бирү комплексы ачылды. Әлеге тантаналы чарада Татарстан Республикасының Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, ТР премьер-министры Алексей Песошин, ТР мәгариф һәм фән министры Рафис Борһанов, Казан мэры Илсур Метшин катнашты.

● 8 сентябрьдә танылган журналист Гөлнара Зиннәтуллина вафат булды. Мәрхүмәнең җәсәде туган авылында – Лаеш районының Хәерби авылы зиратында җирләнде.



● Сентябрьдә Илһам Шакировка багышланган китап (баш мөхәррире – Разил Вәлиев, төзүчесе – Гәрәй Рәхим) басылып чыкты.

● 9 сентябрьдә Тукай районының Яңа Бүләк авылында мәшһүребез Илһам Шакировка бюст (скульпторы – Венера Абдуллина, Санкт-Петербург) ачылды. Тукай районы башлыгы Фаил

Камаев алып барган чарада Милли Шура рәисе, Татарстан премьер-министры урынбасары Васил Шәйхразиев, язучылар һәм сәнгать әһелләре Р.Вәлиев, Д.Салихов, Ф.Сафин, Л.Лерон, А.Фәйзрахманов, Х.Тимергалиева, Ф.Сәлахов, Р.Маликов, К.Нуруллин, И.Биктаһиров, Ф.Вәлиәхмәтов, Ф.Галимов, И.Закиров, И.Шакировның туганнары Флүр Шакиров, Руфия Абдуллина һәм башкалар катнашты.

● 9 сентябрьдә Кукмарада «Мәчкәрә укулары» үтте. Чарада «Ислам динен кабул итүгә 1000 ел» исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон катнашты һәм чыгыш ясады.

● 14 сентябрьдә Татарстанның халык артисты Хәмдүнә Тимергалиева вафат булды. Мәрхүмәнең җәсәде 15 сентябрь көнне «Курган» зиратында җирләнде.

● 15 сентябрьдә бер төркем зыялылар (М.Галиев, Г.Рәхим, З.Мансуров, Д.Салихов, Л.Лерон, М.Закир, М.Хәбетдинова, Н.Исәнбәтнең кызы Йолдыз ханым, Т.Гыйззәтнең оныклары Гүзәл һәм Гөлназ) Яңа Татар бистәсе зиратында мәшһүр драматурглар Таҗи Гыйззәт һәм Нәкый Исәнбәт каберләренә чәчәкләр салды.

● 19 сентябрьдә Арчада Татарстанның халык язучысы Гариф Ахуновны искә алу чаралары булып узды. Казаннан килгән бер төркем язучылар (М.Әмирханов, В.Нуриев, Л.Лерон, Р.Аймәт, әдипнең кызы Н.Ахунова, О.Левадная, А.Ахунов, Ә.Галимуллина) Г.Ахуновның каберен зиярәт кылды, аның рухына дога багышлады. Алар Казанбаш авылы мәктәбендә, Кечкенә Өчиле авылындагы «Ахун» чишмәсендә, соңыннан Гариф Ахунов исемендәге әдәби премияне тапшыру тантанасында булды.

● 21-22 сентябрьдә Мөслимдә Әдәбият көннәре үтте. Чарада язучылар, галимнәр һәм дин әһелләре (Д.Салихов, Т.Галиуллин, Х.Миңнегулов, Ф.Садриев, З.Мансуров, Җәлил хәзрәт Фазлыев, Ильяс хәзрәт Җиһаншин, Нияз хәзрәт Сабиров, Ф.Сафин, Ш.Җиһангирова, Ф.Солтан, Ф.Мөслимова, Л.Лерон, Р.Рахман, М.Хәбетдинова, М.Әхмәтшина, Р.Шаһиев, М.Закир, Р.Сәгъди, Л.Шәех, Л.Гобәйдуллин, Л.Садриева һ.б.) катнашты.



● 24 сентябрьдә Г.Тукай музеенда филология фәннәре докторы Зөфәр Рәмиевнең «Миргазиз Укмасый: әсәрләр, мәкаләләр, истәлекләр» дигән китабы тәкъдим ителде.

● 24 сентябрьдә ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Язучылар берлегенең Г.Исхакый исемендәге премиясе лауреаты, күренекле шагыйрь, журналист һәм публицист Әхмәт Рәшит (Әхмәт Әхәт улы Рәшитов) вафат булды. Әдипнең җәсәде туган авылында – Яңа Чәчкап (Буа) зиратында җирләнде.

● 25 сентябрьдә «Пирамида» мәдәни-күңел ачу комплексында «Яңарыш» Татарстан Республикасы тарихи һәм мәдәни истәлекләрен торгызу Республика фонды төзелүгә 10 ел тулуга багышланган тантаналы чара булып узды. ■

Безнең мирас №10 октябрь 2020

МИРАСВОРД



Кырымда һәм Литвада яшәүче төрки халык

Абруйлы, ихтирамга лаек карт

Грек хәрефе

Селенга елгасының уң кушылдыгы

Язучы Мәхмүд ...

Шагыйрь Госман ...

һәвәс, оста, маһир (иск.)

Дедал улы

Язучының иҗат җимеше

Рәшә (диал.)

Очучы-сынаучы, Советлар Союзы Герое

Электр каршылыгы берәмлеге

Татар халкының этник төркеме

... Гарипов (башкорт шагыйре)

Хуҗа Әхмәд ...

Кылыч савыты

Уй-план, теләк

Наип ... (татар галиме, тәнкыйтьче)

Ел (иск.)

Ил башлыгы, ил хуҗасы

Икейөз-лелек, ясалма-лылык

Диалект, җирле сөйләш (иск.)

Төньяк халык-ларының күчмә торагы

Борынгы Идел

XVIII гасыр немец дәүләт-ләрендә коелган көмеш тәңкә

«Миркәй белән ...» (Нәкый Исәнбәт)

Җәяр өчен әзерләнгән түгәрәк камыр

Игътибар, әһәмият (иск.)

... Юзиев

Монголиядә феодал

Мишәр абзые

Шагыйрь Дифгат ...

Мирсәй ...

Африкадагы елга

... Ошанин (рус шагыйре)

... Байҗиев (кыргыз әдибе)

Уен коралы да, акча да

Кәрим Тинчурин драмасы

Язучы Ибраһим ...

Нәсел җебе

Җырчылар ... Мостафин, Сәлимов

Рәис Габдулла *төзеде.*

9 нчы санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: Камай, гөбе, нәкыс, фәза, «Китап», мәргән, лорд, Риони, Сәрвәр, исәр, Әхмәт, аршын, Адан, Ян, ал, Илион, Ерикәй, Әнвәр, тугра, Вера, Бикә, Даян.
Өстән аска: күнәк, сәрдар, мөкатдәс, Али, Арриан, Ван, Йосыпов, тәте, ләкшә, абруй, гаид, әр, «Әниләр», Гафури, инабәт, Госманов, бизмән, янә, Уткин.

«Безнең мирас»
елъязмасы / октябрь

Атлы трамвай. Казан, XIX гасыр

765 ел элек (1255)

Чыңгыз ханның оныгы Батый (Бату) хан (1209-1255) вафат була.

465 ел элек (1555)

Татарларны Казаннан куып чыгару һәм аларны калага кертмәү белән бергә, урыс хакимияте «бөтен мәчетләрне җимерү, юкка чыгару» турында да фәрман бирә. Арча даругасын талап-туздырып ташлагач, урыслар Казанда ныклап төпләнә башлый. Митрополит Макарий яраннары яулап алынган җирләрне дин ягыннан да урыс дәүләтенә кушу эшенә керешә: халыкны христианлыкка кертәкүндерә башлауны күздә тотып, Казанга архиепископ җибәрелә...

165 ел элек (1855)

Шагыйрь Әхмәт Кормаши (1855-1883) дөньяга килә.

145 ел элек (1875)

2 октябрьдә Казанда атлы трамвайлар йөри башлый.

65 ел элек (1955)

«Совет әдәбияты» журналында Илдар Юзеевның «Таныш моңнар» поэмасы дөнья күрә.

20 ел элек (2000)

30 октябрьдә Гариф Ахунов (1925-2000) яшәгән йортка истәлек тактасы куелды.

*Журналга **Марат Закир** әзерләде.* ■

Содержание. Октябрь 2020

И останется в мире слово моё...: Гаяз Исхаки.

Историческое наследие: «Зулейха» и миссионер Малов». Л.Гайнанова; «Султангалиев кто он?» И.Тагиров; «Шакур из Туймазы». А.Сафуанов; «Газета «Чулпан». Л.Губайдуллин, Р.Шарафиева.

Татарский мир: Фанир Галимов: «Несомненно, деревни будут жить!»

Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов.

Литературное наследие: «Стихи Гаухар Туганай».

И вырвалось из мирской суеты...: «Смерть Мударриса Аглямa». Л.Лерон.

В глубинах памяти: «Легенда о каменном богатыре». А.Сарманбетов; «Зульфат». Р.Туфитуллова; «В памяти, до сих пор в памяти!»

Художественное наследие: «Древние национальные музыкальные инструменты». Р.Гилязев; «Татарская государственная филармония в истории 100-летней ТАССР». З.Гильмутдинова.

Океан воззрений: «Нация». Р.Садриев.

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

Алхәбәр:

Хәй Хисмәтуллин хатыны Мәһруйбикә һәм кызы Ләйлә белән. 1932 ел

- **Фатих Кәрими.** **Хәй Хисмәтуллин**
- **Әдәби калейдоскоп.** **Тәлгат Галиуллин**
- **Зәй-Каратай авылы тарихы**
- **Язучы Җәмит Рәхимов мирасы**
- **Мирхәйдәр Фәйзи көндәлегеннән**

ТАССР
Празднование 100-летия Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүнең 100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020

Әдип авылы — фотоларда

Яуширмә мәктәбе

Гаяз Исхакыйның туган авылы Яуширмә (Чистай районы) күренешләре

Яуширмәдә Гаяз Исхакый музее





СӨЕМБИКӘ МАНАРАСЫ

Фотолар А.Дубин тупланмасыннан

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – П2343
РОССИЯДӘ – П7074
beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
журналына башкача язылу:
- *uslugi.tatarstan.ru* сайты ярдәмендә
- редакциядә
- *podpiska.pochta.ru* сайты ярдәмендә электрон версия

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 29/11), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.